Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 14 (1430) 14 апрель 2023 ел

Татарстанда язылу индексы – П2355.

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga

5

Г. Тукай әдәби музеенда узган искә алу кичәсе Камил Мотыйгый кебек күп шәхесләребезнең әле һаман да тиешенчә өйрәнелмәвен, бәяләнмәвен раслады.

8

Шәрыкнең олуг галиме Әбүгалисина язган фәнни хезмәтләрнең төрлелеге дә, аларның күләме дә гаҗәпкә калырлык.

12

Башкортстанга яңа сәфәребез барышында Бәләбәйдәге атаклы татар гимназиясендә булдык, якташларны барладык.

Сәнгатьтә дә, хәяттә дә анын Дон Кихотлык булды кальбендә!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов 85 яшьлек юбилейлары уңаеннан Россиянең һәм Татарстанның халык артистлары Равил Шәрәфиев һәм Ринат Тажетдинов белән очрашты һәм дәүләт бүләкләре тапшырды.

- «Казан» гаилә үзәгендә Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис тормыш иптәше Лилия белән бриллиант туйларын билгеләп үтте.

- Иртәгә, 15 апрельдә, «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәге мәйданчыгында XI Республикакүләм ифтар узачак.

- Лениногорск Мәдәният сараенда Татарстан гимны авторы Рамазан Байтимеровның 100 еллыгын билгеләп үттеләр.

- «Татарстанның мәдәни башкаласы» конкурсы кысаларында, Казанның Чулпан мәдәният үзәгендә Нурлат һәм Сарман районнары үз программаларын тәкъдим итте.

- «Идел-йорт» фестиваль-конкурсы кысаларында Әлмәт драма театры үзешчән театр коллективлары өчен «Режиссура, актерлык осталыгы, грим, пластика» дип исемләнгән иҗат лабораториясе оештырды.

- Рамазан аенда теләге булган һәркем «Lisan.Tatar» сайтында теркәлеп, иске татар телен бушлай өйрәнә ала.

- Уфада композитор Ильяс Камалның Илһам Шакировка багышланган «Кара урман аша» дип аталган симфоник поэмасының премьерасы булды.

- Мәскәү Татар мәдәнияте үзәгенең «Тальян» татар җыр театры татар хор музыкасы фестиваль-бәйгесе һәм вокал-хор коллективлары фестиваль-конкурсы лауреаты булды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Ләбиб ЛЕРОН, язучы, шагыйрь:

«Кичәләргә сценарийлар эшләгән кеше буларак та, мин моны тоям. Әгәр берәр шагыйрьнең исемен кичәдә шигырь укый дип, сметага кертмәкче булам икән, Мәдәният министрлыгындагы түрәләр: «Сез нәрсә аларга түлисез, алар бушка сөйләргә тиеш», – дип, миңа каршы чыга иде. Минәйтәм, нишләп шул ук сәхнәдә артист чыгыш ясый – аңа түлибез, ә шагыйрьгә түләмибез?»

СЫНАМЫШЛАР

Искечә 1 апрельдә (хәзер 14 апрельдә) боз катса, унбиш көнлек юлга чана белән чыгарга ярый ● 14 апрельдә язгы ташу башланса, печән яхшы була ● 15 апрельгә сулыклардагы боз, агып китмичә, төпкә батса, авыр ел көтелә ● Искечә 6 апрельдә (хәзер 20 апрельдә) аяз булса, җәй коры килер, болытлы булса – ашлык уңар; бу көнне торна кычкырса, яхшы ел фаразлана.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **4 сәгать 43 минутта** чыкты, һәм ул **18 сәгать 46 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **14 сәгать 03 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **31 минутка озыначак** һәм киләсе җомгада, ягъни **21 апрельдә 14 сәгать 34 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

15 апрель – шагыйрь, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мөхмүт Хафиз улы Хөсәеннең (Хөсәеновның) тууына 100 ел (1923–1993);

– театр белгече, библиограф Һәнүз Котдус улы Мәхмүтовның тууына 90 ел (1933–1996);

– журналист, тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Ислам Галиәхмәт улы Әхмәтҗановка 75 яшь (1948).

17 апрель – композитор, Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Бату Гатаулла улы Мулюковның тууына 95 ел (1928–1999);

– җырчы, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Лариса Георгий кызы Башкированың тууына 85 ел (1938–2019).

18 апрель – язучы, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче, профессор, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Ибраһим Зиннәт улы Нуруллинның тууына 100 ел (1923–1995).

20 апрель – тарихчы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Гомәр Салих улы Сабирҗановка 90 яшь (1933).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Апрельнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 16, 18, 20 апрель.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(13-20 апрель)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген рамазан аеның 23 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Габделхак МИНГАРИПОВ

УРАМНАРГА – үз исемнәребез!

Безнең Күгәрчен авылы урамнарына исемнәрне узган гасырның җитмешенче елларында гына бирделәр. Аңа хәтле авылны өлешләргә бүлеп, Югары оч, Түбән оч, Арьяк һ.б. дип кенә йөрттеләр. Сала кешесе бер-берсен нык таный, күпләрне нәселе белән атый, кемнеңдер йортын табышуда хәтта кушаматлар эшкә җигелә иде. Чөнки безнең Күгәрчен шикелле «мең җанлы» авылда (ә аңа нигез 1367 елда салынган дип йөртелә; 1907 елда бирелә 2381 кеше көн итүе билгеле, 1989 елда бу күрсәткеч 1742 кеше тәшкил итте) кушаматсыз нәсел юк. Почтальоннар да һәр гаиләнә биш бармаклары кебек белеп, хатларны, газета-журналларны бернинди ялгыш-хатасыз таратты. Шулай да, совет хөкүмәте шәһәр белән авыл арасындагы аерманы бетерүгә йөз тотып, авыл урамнарына исемнәр, өйләргә номерлар бирүне тормышка ашырды. Бу вакытта инде авыл кешесенә дә паспорт алу хокукы бирелде, колхозлар акчалата хезмәт хакына күчте, аз күләмдә булса да, әби-бабайларга пенсия бирелә башлаган иде. Шушы вакыйгалар ташкынында Күгәрчен урамнарына да Совет, Татарстан, Дуслык, Җәлил, Такташ, Горький, Гагарин, Чкалов, Фрунзе, Жданов, Ворошилов исемнәре беркетелде. Әлбәттә, мондый исемнәр кушуны авылның бер кешесе дә сорап йөрмәде, барысы да өстән кушу буенча яисә җирле җитәкчеләр ихтыярлы белән хәл ителде. «Гадәти бер авыл урамына Горький, Чкалов, Фрунзе, Жданов, Ворошиловларның ни катнашы бар?» – диган уй бер җитәкченең дә уена килеп карамады. Хәер, алай дисәң, Фрунзе, Жданов, Ворошилов исемнәре авыл колхозлары өчен күптән таныш иде. 1930 елда авылыбызга Мәскәүнең «Урак һәм чүкеч» заводыннан 25 меңче итеп кумәк алдынгы эшчеләрнең берсе – чыгышы белән Апас районыннан булган милләттәшебез Самат Абдуллин килгән булган һәм шул кеше беренче колхозга, райком кушуы буенча, Фрунзе исемен ябыштырып куйган. 1959 елга чаклы кумәк хуҗалык шул исем белән яшәде, аннары «Россия»гә үзгәртелде. Ә 1944 елда, авылны шартлы рәвештә өч өлешкә бүлеп (Югары оч, Түбән оч, Арьяк (Сушаның теге ягы), өч аерым колхоз ясыйлар да, нәкъ менә шуларга янә Фрунзе, Жданов, Ворошилов исемен беркетәләр. 1950 елда ул өч өлеш янәдән бер колхозга – «Фрунзе»га берләште. Мәгәр Жданов та бөтенләй югалмады, 1970 елда аның исемен авылның буеннан-буена сузылган, 92 йортлы урамга чәпәп куйдылар. 1980 еллар ахырында демократия дигән дулкын купкач, Ждановның да байтак мәдәният әһелләрен төрмә вә каторгаларга озатуда катнашкан булуы ачыклана. Ул җитәкчелек иткән елларда (1935-1944 еллар) Ленинград өлкә партия оешмасы 1935 елның 1 гыйнварыннан тарихи 1937 нче ел ахырына сан ягыннан 300 меңнән 120 меңгә кала. Мондый хәлдә инде һичничек тә Ждановны гаепсез җитәкче, дип санап булмый...

1980 елларда, Үзәк Комитет кушуы буенча, Чаллы каласына да Брежнев исемен дегет чиләге урынына тагып куйганнар иде, Аллаһның кодрәте белән каланың тәүге исеме тиз арада яңадан кайтарылды. Демократия, хәбәрдарлык елларында кичә Ворошилов исемен йөрткән Луганск, Жданов исеме тагылган Мариуполь калаларының асыл исемнәре дә кабат үз урынына кайтты. Казандагы Жданов урамының исемен «Эсперанто»га әвереллдергәннәр иде, нинди хилаф хикмәт беләндер, әлеге урамга янә карак Назарбаев атын чәпәделәр, димәк, якын арада аңа да яңа ат, яңа исем эзлисе була инде. Никадәрле чыгым, җилгә очкан акча!..

Ә Күгәрчен авылында Жданов исеме бер урамда һаман да саклана, җитәкчеләр арасында акылга килүче юк. Гәрчә Күгәрчен урта гомуми белем бирү мәктәбе коллективын һәм авыл активларын җыеп, без 2005 елда ук авыл урамыннан Жданов исемен алып ташлау турында район җитәкчелегенә мөрәҗәгать юллаган идек. 2009 елда педагоглар коллективы янә бер җыелыш уздырды һәм нәкъ Күгәрчен мәктәбендә узган Төбәкне өйрәнүчеләр конференциясе исеменнән югарыга үтенеч-тәкъдим юллады. Безнең мәктәптә 1949 елдан бирле, соңыннан һәммәбезнең остазына әвереләчәк мәртәбәле педагог Гомәр Әгъзәмов эшләде. Нәкъ шул Гомәр ага башлангычы белән 1980 елларда авылыбызның бер урамына тарихчы Зәетов, икенче урамга Әфганстан сугышында һәлак булган авылдашыбыз Равил Гыйниятуллин исемнәре бирелде. Шушы Гомәр ага мәктәптә Туган як музее булдырды. Авыл зиратын койма белән әйләндереп алу, Суша һәм Кечесу елгалары ярын чүп-чардан арындыру, чишмәләрен төзекләндерү мәшәкатьләрен дә шушы ук шәхес башлап йөрде. Гомәр ага мәктәп директоры булып эшләгән чорда уку йорты урта мәктәп статусын алды. Шушы шәхес авыл тарихын да язып бирде, хәтта ул әле – популяр җырлар авторы (көйләрен С.Садыйкова, Ф.Мортазин, В.Мироваев һ.б. тудырган) һәм җирле шагыйрь дә!

Без «туган телгә, туган җиргә мәхәббәт тәрбиялик», дип туктаусыз сөйләнәбез, «Бергә булыйк, бердәм булыйк!» дип шигарьләр кычкырырга да нык остардык. Ләкин туган җир, туган кавем урынына һаман Жданов, Ворошилов, Брежневлар алдында тез чүгәбез, ә үзебезнең газиз Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Һади Атласиларны читкә тибәрәбез икән, милләт арасында берчакта да бердәмлек вә аңлашу булмаячак. Күгәрчен авылы мисаллары да шуңа дәлил.

Төбәкчеләр конференциясе исеменнән без авылдагы Жданов урамын Гомәр ага Әгъзәмов исеменә алыштыруларын сорап мөрәҗәгать юлладык. Бар гомерен туган ягын данлауга, яшь буын тәрбияләүгә багышлаган Гомәр ага моңа лаек иде. Мәктәп коллективы исеменнән, үтенечне хуплап, директор М.Мингарипов, аның урынбасары С.Сәгыйрова, профком рәисе Р.Гыйлемханова кул куйды.

Үтенечнамәдә бәян ителгәннәргә шуны да өстәү урынлы: Гомәр ага белән хатыны Мәрьям апа районыбызга ике табиб үстереп бирде: Госманы – Котлы Бөкәш участок хастаханәсендә, Рәфгать – район үзәк хастаханәсендә терапевт, Татарстанның мактаулы исемнәренә һәм РФ билгеләренә лаек белгечләр.

Әмма безнең үтенечне җирле үзидарәнең ул еллардагы җитәкчелеге дә, район комитетлары да җавапсыз калдырды. Шуның белән авылыбыз тарихына, мөхтәрәм авылдашыбыз, сугыш һәм хезмәт ветераны, мөгаллимнәр остазы Гомәр Әгъзәм улы Әгъзәмовка карата да ихтирамсызлык, илтифатсызлык күрсәтелде. Ләкин коллектив бәлки, быел игълан ителгән Педагог һәм остазлар елын күз уңында тотып, күтәрелгән мәсьәләгә бөтен җитдилеге белән карап хәл итүгә алыныр һәм чишелешен дә табар дигән өмет яши.

Балык Бистәсе районы.

ИСКЕ НИГЕЗЛЕ ЯҢА КОНЦЕПЦИЯ

РФ Президенты В.Путин 31 март көнне, үзенең указы белән, Россия тышкы сәясәтенең яңа концепциясен раслады. Ул моны, дөнья аренасында җитди үзгәрешләр килеп чыгуы сәбәпле, иң мөһим стратегик документларга төзәтмәләр кертергә туры килүе белән аңлатты. Аныңча, яңартылган концепция илнең якындагы һәм урта сроклы перспективадагы гамәли эшчәнлегенең нигезенә салыначак, шулай ук халыкара мөнәсәбәтләрдә алдагы эшчәнлек өчен яхшы доктриналь нигез булып хезмәт итәчәк. Рәсми хәбәрләрдә бу документның илдә халыкара эшчәнлек максатлары вә бурычларының өстенлекле юнәлешләрен билгеләве, РФ тышкы эшләр министрлыгы (ТЭМ) һ.б. министрлык һәм ведомстволар өчен дә юл картасы булачагы хакында әйтелә. Документның үзендә исә Россиянең үзенчәлекле цивилизациягә ия ил һәм Урыс дөньясының таянычы, шулай ук дөнья үсешенең суверен үзәкләреннән берсе булуы, ә Көнбатышның дустанә булмаган гамәлләре дәвам иткәндә, ирекле үсешкә хокукын саклап калу өчен үзе ия булган барлык чараларны кулланып көрәшәчәге турында әйтелә.

Инде яңартылган концепциянең төп тезисларын да кыскача гына тәгаенләп чыгыйк: Россия үзен Көнбатышның дошманы дип санамый һәм аннан изоляцияләнергә җыенмый, аңа дошман ниятләрдә дә тормый; ул нибары Көнбатышның конфронтация юлы перспективасыз икәнлеген аңлавына һәм тигез хокуклы мөнәсәбәтләргә кире әйләнеп кайтуына исәп тота; Мәскәү АКШның бүген тоткан курсына аның үз иминлеге һәм халыкара тынычлык өчен төп куркыныч чыганагы итеп карый; төп игътибар АКШның дөньяда өстенлек итү рудиментын юкка чыгаруга бирелачәк; Мәскәү, үзара аңлашу принциплары нигезендә, барлык илләрнең дә тигез дәрәҗәдәге куркынычсызлыгын тәэмин итәргә омтыла; Кытай һәм Һиндстан белән гомумколачлы элемтәләрне ныгыту һәм эш-гамәлләрне дә координацияләү аеруча зур әһәмияткә ия; якын чит илләрдә төп максат – төбәкне тынычлык, яхшы күршелек һәм гөрләп алга бару зонасына әверелдерү. Президент әйтүенчә, бу документны бүгенге чынбарлыкка туры килерлек итеп эшләүдә ТЭМ һәм башка ведомстволар нык тырышкан һәм концепцияне гамәлгә ашыруда да координацияләүче ролен нәкъ менә ТЭМ башкарачак.

Бер караганда, санап үтелгән бу тезисларда тел-теш тидерерлек нәрсәләр юк та кебек. Ләкин яңа концепциянең иске (геосәяси) карашларга нигезләнеп корылуы да ярылып ята. Тик глобаль кризис шартларында яшәешне алга таба инде геосәяси ысул яки алымнар белән генә җайлап булмаслыгы да хак (узган язмабызда бу мәсьәләгә тәфсиллерәк тә тукталган идек). Ә бүгенге вакыйгалар сөреше моны тагын бер кат раслый. Димәк, каршы торучы якларда берсе икенчесен сугыш кырында гына җиңәргә тиеш була, чөнки геосәяси максатлары капма-каршы һәм алар тыныч юл белән чынга ашырыла алмый. Мондый хәл чорның төп геосәяси каршылыгына да кагыла. Ә цивилизацион яктан бүген төп каршылык – Көнбатыш белән Көнчыгыш арасында. Геосәяси планда ул, АКШ белән Кытай арасында дөнья гегемонлыгы өчен көрәш рәвешендә, яшәешнең бөтен өлкәләрендә дә бара. Кытай, әйтик, әлеге проблеманы тыныч юл белән хәл итү яклы (аның 12 пункттан торган «тынычлык планы» глобаль максатларны да күздә тота). Кушма Штатлар исә өстенлекне аны хәрби юл белән хәл итүгә бирә (НАТО, АНЗЮС, AUKUS кебек хәрби блоклар төзелгән, дөнья буйлап йөзләрчә хәрби база урнаштырылган һ.б.). АКШ белән Кытай арасында хәрби низаг Тайвань проблемасы аша туарга һәм аның геосәяси чишелеше, ахыр чиктә, бу очракта да сугыш кырында гына хәл ителергә мөмкин. Ә атом-төш коралына ия ике иң көчле дәүләт арасында урын алган мондый акылсызлык бөтен дөнья өчен дә зур фаҗигага булыр иде.

Хактыр ки, геосәяси кризис шартларында барлык проблемаларның да уртак чишелеше була алмый. Моның өчен кешелек дөньясының абсолют кыйммәтләр системасына күчеп яши башлавы лязем. Ә бу инде ул киң мәгънәдә илаһият кануннары буенча яшәүгә күчкәндә генә мөмкин. Чөнки Аллаһ кануннары барлык халыклар һәм аларның диннәре өчен дә (хәтта бар тереклек дөньясы өчен дә!) уртак. Ни кызганыч, бүген әле бер генә дәүләт тә үзенең эчке һәм тышкы сәясәтендә андый изге максатлар куймый. Ә илаһи борылыш метасәяси яктан да, тәкъдирдә язылган буенча да, бары тик Урталык җирләреннән генә башлана ала. Ләкин анда урнашкан дәүләтләр зур сәясәттә бүген дә, әүвәлгечә үк, геосәясәт коралы итеп кулланыла. Тышкы сәясәтенең Россиядә кабул ителгән әлеге яңа концепциясе – шуның ачык бер мисалы. Мондый шартларда илаһият кануннары буенча яшәүгә күчүнең метасәяси механизмнарын булдыру мәсьәләсе, әлбәттә, бик җиңелләрдән түгел. Әмма, иртәме-соңмы, ул хәл ителергә тиеш.

Фоат УРАЗАЙ.

Татарча телеграм-бот



Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Гамәли семиотика институты Телеграмда «Татар чаты» дигән татарча бот эшләгән. Ботка @tatar_chat_gpt_bot нигы белән кушылырга мөмкин.

«Бу бот татар кулланучыларын бөтен дөньядан берләштерү һәм аларга туган телдә аралашырга мөмкинлек бирү өчен булдырылды. Бу эш татар мәдәнияте һәм теле белән кызыксынучылар өчен бушлай һәм ачык. Максаты – ChatGPT нейрон челтәренә татар телендә сорау бирү өчен уңайлы интерфейс булдыру», – дип аңлата оештыручылар.

«Татар чаты»нда сораулар һәм җаваплар Татсофт тәрҗемәчесе ярдәмендә тәрҗемә ителә. Тәүлегенә 4000 символга кадәр күләмдә язышырга була.

Татар ботының меңнән артык кулланучысы бар, алар төрле темаларга – Татарстанның мәдәниятеннән һәм тарихыннан алып, һава торышы һәм яңалыкларына кадәр аралаша, шулай ук республикада барган яңалыкларга, вакыйгаларга язышырга мөмкинлек бирә.

Проектка нигез салучы Айдар, «татар боты» булдыру идеясе татар мәдәниятен һәм телен саклап калу, алга этәрү теләгеннән туган, дип билгеләп үтә. Ул шулай ук татар кешеләренә яңа дуслар табарга һәм туган телләрендә аралашу күнекмәләрен үстерергә ярдәм итәр дип өметләнә.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Вакытлыча – Камал театрына

Казан Яшь тамашачы театры (ТЮЗ) бинасын реконструкцияләү проектының өченче өлешенә экспертиза этабы тәгәлләнеп килә. Бу хакта матбугат конференциясендә Казан Яшь тамашачы театры директоры Айгөл Горнышева сөйләде.

«Без милли театр булган Камал театры өчен яңа бинаны мөмкин кадәр тизрәк төзеп бетерсеннәр дип телибез. Алар бушаткан бинага без күчәбез. Тамашачыга ерак булмасын өчен, элеккечә шәһәр үзәгендә булган килеш тыныч кына эшлибез. Эшләр төгәлләнгәч, үз сәхнәбезгә кайтачакбыз», – диде А.Горнышева.

Реконструкцияләү проекты өч өлешкә бүленгән, дип аңлатты. Ул булган янкормаларны, шул исәптән, театрның эчке файдалы мәйданнарын арттырып, торгызырга кирәк булганын исәпкә ала. «Бу театр өчен махсус төзелгән бина түгел. Ул үзгәртелеп торды, ә инженерлык челтәрләре элеккечә калды, аларның куәте җитми. Шуңа күрә, театрның эчендә капиталь ремонт эше алып бару, инженер системаларын алыштыру өчен бинаны тулысынча бушатырга кирәк», – диде театр директоры.

«Шәрык базары» офыкларны киңәйтә

Р. Ваһапов фонды оештыра торган «Шәрык базары» беренче тапкыр 2021 елда Халыкара төрки халыклар эстрада фестивале буларак узган, анда нигездә, якын төрки халыкларның иҗатына зуррак игътибар бирелгән иде. Әмма «Шәрык базары» беренче елда ук зур кызыксыну уятты, ул төрле төрки илләрдән, төбәкләрдән килгән эстрада артистларының бердәм мәйданына әверелде. Быелтыр фестивальдә «Ялла» төркеме катнашуы да зур вакыйга булды. Быел, «Туган авылым» комплексында Ваһапов фонды оештырган ифтар барышында хәбәр ителгәнчә, «Шәрык базары» халыкара милли мәдәниятләр фестивале октябрь аенда узачак. Анда 25 ил вәкиле катнашыр дип көтелә. Ваһапов фонды директоры Рифат фестивальнең бер көн генә түгел, ә бер атна дәвамында барачагын да искәртте. «Без фестивальгә 18 ил катнашыр дип планлаштырган идек, әмма ул тагын да киңәйде, проектка 25 ил кушылды, бу – бик зур эш», – диде ул.

Очрашуда Россиянең төрле төбәкләреннән кунаклар, Мисыр, Һиндстан, Әфганстан, Йәмән, Казахстан, Кыргызстан, Кытай, Палестина, Согыд Гарәбстаны, Төркмәнстан, Төркия, Үзбәкстан, Сурия, Таҗикстан илләренең вәкилләре һәм шулай ук Казахстан, Кытай, Төркия, Үзбәкстан, Төркмәнстанның Казандагы генераль консуллары да чакырылган иде.

Татарстан Республикасының Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе, Татарстан Премьер-министр урынбасары Васил Шәйхразыев Рифат Фәттаховның күпкырлы эшчәнлеген ассызыклады. Төркиядә булган җир тетрәү мисалында халыкларның үзара дус, ярдәмчел булуын да искә алып үтте.

Төркиянең Казандагы консулы Исмет Эрикан былтыргы фестивальнең гаять уңышлы узуын әйтте. «Фестиваль тагын да киңәер, дип ышанам. Төрки дөнья көчәя бара. Кайда гына яшәсәк тә, без бердәм», – диде ул. Ул Төркиядә булган җир тетрәүдән соң ярдәм күрсәткәне өчен, Рифат Фәттаховка рәхмәт хаты тапшырды. Ваһапов фонды җир тетрәү нәтиҗәсендә зыян күрүчеләргә 100 мең сум күчергән иде.

Сөембикә КАШАПОВА.

Казанны татарча сурәтлә!

Татарстан башкаласында рәссамнардан «Саумы, Казан!» иҗади бәйгесенә гаризалар кабул ителә башлады. Җиңүчеләрнең эшләре шәһәр көненә багышланган күргәзмәдә тәкъдим ителәчәк. Моннан тыш, Казанда татар телен өйрәнү буенча иң яхшы проектка икенче конкурс үткәрелә.

«Конкурсларның максаты – иҗади яшьләргә үз амбицияләрен белдерү генә түгел, ә идеяләрне тормышка ашыру мөмкинлеге бирү. Татар телен алга этәрүгә юнәлдерелгән мондый проектларның үз адресатларын табуы һәм туган телдә яшәргә генә түгел, үсеш алырга да ярдәм итүе мөһим», – дип билгеләп үтте Казан мэры Илсур Метшин.

«Саумы, Казан!» бәйгесе катнашучыларына Татарстан башкаласының сәнгати образын булдырырга кирәк булачак. Гаризалар 18 яшьтән өлкәнрәк авторлардан кабул ителә, гражданлыклары мөһим түгел. Жюри эшләрне ике яшь категориясендә – 35 яшькә кадәр һәм 35 яшьтән өлкәнрәк, ике юнәлешрәсем һәм графика буенча бәяләячәк.

ТАШЛАМА БЕЛӘН ЯЗЫЛЫГЫЗ!

Дуслар! 20 апрельгә кадәр **«Мәдәни җомга»** газетасына ташлама белән язылып була. Әбүнәче декадасы көннәрендә Татарстанда язылу бәясе **670 сум 32 тиен**. **«Мәдәни җомга»** газетасына Татарстанда язылу индексы **– П2355.**

1 нче биттә – Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Равил Шәрәфиев Г. Камал театрында узган иҗат кичәсендә. Р. Гали фотосы. «Татар-информ».

Татарның яраткан Әҗәле

Гомерне алырга килгән Әҗәлне яратып буламы? Була! Әгәр дә аны сәхнәдә Равил Шәрәфиев уйнаса...

Г.Камал театрында Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Равил Шәрәфиевне 85 яшьлек юбилее белән котладылар. Кичә барышында бер Әҗәлне генә искә алып калмадылар, Илгиз Зәйниев әсәре буенча куелган «Бабайлар чуагы», Таҗи Гыйззәтнең «Чаткылар»ы буенча сәхнәләштерелгән спектакльдән өзекләр башкарылды, З.Хәким әсәре буенча куелган «Чапты атым Казанга» спектакленең видеоязмасыннан өзек күрсәтелде. Хәтта Равил ага бик хыялланып та уйнамый калган геройны – Дон Кихотны күрергә мөмкин иде. Юк, атаклы испан язучысы Сервантесның герое юбилей кичендә сәхнәдә терелмәде ул. Ә шулай да Дон Кихотны күрдек, чөнки Равил ага – үзе коеп куйган Сервантес герое – шундый ук кыю, туры сүзле, гадел, самими һәм авантюрист холыклы.

Авантюрист артистның иҗат кичәсе дә бик үзенчәлекле үтте. Тагын кайсы артистның юбилей кичендә Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиевнең, котлау сүзе алып, «Эх, алмагачлары...» җырын сузганы бар?! Республикабыз Рәисе үзе юбилярны котларга килмәсә дә, аны да күргән сыман булдык. Илбаш Рөстәм Миңнехановны яшь, талантлы артистыбыз Эмиль Талипов гәүдәләндерде. Бүтән чараларда мондый пародияләр ярамаса да, авантюрист холыклы Шәрәфи кичәсенә килешә. Бары тик Равил ага кичәсендә генә балет белән мультфильм янәшә килеп, бер берсен тулыландыра ала. М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының Аманда Гомес һәм Михаил Темаевнең «Дон Кихот» балетыннан адажиосы һәм «Татармультфильм»да төшерелгән моңге исән Әлмәндәребез турында мультфильмнан өзек кичәдә әнә шулай бик килешле тоелды. «Казан» бию ансамбле Шәрәфи кичәсендә нинди бию башкара ала? Әлбәттә, Кавказ халыклары биюен! Туры сүзле, гадел, кыю, самими Равил аганың холкын шул бию белән генә сурәтләп бирергә мөмкин. Юбилярга бирелгән бүләкләрнең исемнәре кыска булса да, күп мәгънәне үз эченә ала. Хөкүмәттән «Халыклар дуслыгы» ордены, җырчы Салават Фәтхетдиновның «Хөрмәт» медале турында әйтүебез. Нинди иҗат кичәсе җырсыз узсын? Бигрәк тә Равил ага Шәрәфиевнең юбилее музыкасыз уза алмый иде. Чөнки үзенең дә күңеле моңлы, моңлы күңелдә генә Әҗәлне дә яраттыра алган талант яши. Җырчылар Венера Ганиева, Марсель Вәгыйзов, Руслан Баһадур, Илназ Минвәлиев болай да матур кичәне тагын да ямьләндереп җибәрде.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Балет йолдызына истәлек тактасы

Приморье төбәгенең Раздольное бистәсендәге тимер юл станциясе фасадына да балет короле Рудольф Нуриевка багышланган истәлек тактасы куелды. Барлык театраль башкалаларны, планетаны үзенең чиксез таланты, энергетикасы, эшчәнлек дәрәҗәсе белән яулаган Р.Нуриев сәхнә костюмыннан сурәтләнгән. Истәлек тактасындагы аңлатма татар, рус, француз, инглиз һәм япон телләрендә язылган.

Надеждинский районының Раздольное бистәсе Россиядәге иң озын бистә булып та санала, аның озынлыгы – 14 км. Кечкенә Рудольф биредә берничә ай яшәгән. Аның әтисе, Кызыл Армия политругы Хәмит Нуриев нәкъ менә шушында хезмәт иткән.

Раздольноеда мемориаль такта ачу уе күптән туган, аны танылган скульптор Юрий Фирсов иҗат иткән. Ю.Фирсов моңа кадәр дә татар биючесенең сынын ясаган булган. Хәзерге көндә әлеге сын А.Я.Ваганова исемендәге рус балеты академиясе музеенда саклана.

Әлеге проект өчен акчаны Рудольф Нуриев фонды күптән бүлеп биргән. Әлеге фондның Россиядәге вәкиле – биюченең студент елларындагы якын дусты Любовь Мясникова. Барельефны Любовь Петровна ачып җибәрде. Бирегә шулай ук Л.Мясникованың игезәк туганы, җәмәгать эшлеклесе Леонид Романков та килгән иде. Чарада шулай ук Приморье төбәге хакимияте, Санкт-Петербург, Казан, Уфа, Мария театрының Приморье сәхнәсе вәкилләре дә катнашты. Бу көнне биюче иҗатына багышланган фотокүргәзмә эшләде. Ә кичен халык Мария театрының Приморье сәхнәсендә «Щелкунчик»ны тамаша кылды.

Быел даһи биюченең тууына 85 ел тулу уңаеннан, күп кенә искә алу чаралары уза. Әйтик, дирижер Ф.Мозер: «Рудольф биюдә революция ясады, ул 1970-1980 елллардагы бөтендөнья күләмендәге мегайолдыз иде», – дигән. Ә балет артисты М.Барышников исә: «Нуриев биюгә нык гашыйк һәм биюгә карата физик ачыгу халәтен кичерә иде. Аның бар тормышы да шушы ачлыкны канәгатьләндерү булды», – дип раслый. Әлеге генә ачылган мемориаль тактаның иң аскы өлешендә татар телендә шундый җөмлә уелган: «Рус һәм бөтендөнья балетының танылган, данлыклы легендар артисты Рудольф Нуриев үзенең тормыш юлын 1938 елның 17 мартында «Раздолье» станциясендә башлаган».

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Бүләк дәгъвалау – бер мөмкинлек ул

Г.Тукай әдәби музеенда шагыйрь исемендәге дәүләт премиясе оешуга 65 ел тулуга һәм 2023 елгы кандидатларны тәкъдим итүгә багышланган кичә булды.

«Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясенә 65 ел эчендә 244 шәхес һәм бер ансамбль лаек булган. Хәзерге көндә исәннәр арасында 111 кеше бар. Кичәгә артист, шагыйрь, язучы, фән эшлеклеләре, рәссам һәм татар мәдәнияте, сәнгатен алга күтәргән башка өлкәдә хезмәт итүче замандашларыбызны чакырдык», – диде алып баручы, әдәби музей мөдире Гүзәл Төхвәтова.

Кичәдә премиягә лаек булган иң беренче эшләрнең берсе – Фәрит Яруллинның «Шүрәле балеты» видеоязмасы күрсәтелде. Очрашуда 1967 елда лауреат исеменә лаек булган артист – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Наилә Гәрәева, Тукай образын гәүдәләндергән Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Илдус Әхмәтҗанов та бар иде. Кичәдә Тукай премиясенә лаек булган Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең солисты Фәрит Гафиятуллин баянчы Марсель Вахитовка кушылып «Әллүки» җырын башкарды.

Премиягә лаек булган иң өлкән кеше – Бөек Ватан сугышы ветераны, дин эшлеклесе, Тукай премиясе лауреаты Харис хәзрәт Салихҗанов иде. Аңа 96 яшь. «Шундый матур кичәгә килү минем өчен зур куаныч», – дип, ул Тукай һәм Пушкинга багышлап язылган шигырен укыды.

Актерлар Альбина Шаһалиева һәм Дилүс Хуҗиәхмәтов Тукай премиясенә дәгъва кылу «Әкият» татар дәүләт курчак театры өчен зур вакыйга булуын әйтте. «Бу премия турында хыялланмадык та. Сөенечле хәбәр барыбызны да шатландырды. Кандидат булып басып тору да үзе бер бәхет», – диде алар.

Себердән татар шагыйре Шәүкәт Гаделша (Сибгатуллин) «Аучы җыры», «Чоңгыл», «Иман капка ачканда», «Себерем – үз җирем» шигырь җыентыклары өчен Тукай премиясенә дәгъва кыла. Ул Себер татар телен татар теленең диалекты дип түгел, ә тел дип аерып чыгару турындагы күренекле борчылуын әйтте. ТР Мәдәният министрлыгының массакүләм мәгълүмат чаралары һәм иҗтимагый оешмалар белән арадашлык бүлеге мөдире Айрат Фәйзрахманов фикеренчә, Тукай премиясен алырга кандидатларның иҗаты бай эчтәлекле һәм шул ук вакытта аларның дәгъва итүләре символик мәгънәгә ия. «Бай мәдәниятебезне күрсәтергә менә дигән мөмкинлек», – диде ул.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Бәйрәм көнне – «Гает моңы»

21 апрельдә – Ураза гаете көнне – Казанның «Чулпан» мәдәният үзәгендә «Гает моңы» бәйрәме узачак. Ул «Рухи моң» татар рухи мәдәниятне үстерү фестиваль-бәйгесенең гала-концерты да булып, анда бәйгегә нәтиҗәләр чыгарылачак.

Быел фестиваль Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысаларында «Рухи моң» иҗат берләшмәсе, Татарстан мөфтияте, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә тарафыннан дүртенче тапкыр оештырылды.

Бәйге татар мәкаме һәм традицион мелодика калыпларын кайтаруны, татар халкының нигез кыйммәтләрен үз эченә алган рухи җыр жанрын баетуны, татар мәкаме белән азан әйтү культурасын булдыруны, татар теленең кулланылыш даирәсен арттыруны максат итеп куя.

Быелның февраль башында игълан ителгән конкурс «Дини җыр», «Мөнәҗәт», «Милли мәкам белән азан әйтү», «Вәгазь сөйләү» номинацияләрендә читтән торып үткәрелде. Пермь крае, Самара, Башкортстан, Курган, Төмән, Мәскәү, Чувашия, Омск һәм Татарстаннан 200 гә якын видеоязма кабул ителде. Аларның күпчелеге «Мөнәҗәт» номинациясенә юлланган.

«Рухи моң» иҗат берләшмәсе җитәкчесе Марсель Әхмәдуллин хәбәр иткәнчә, гала-концертның төп максаты – кешеләргә бәйрәм рухы бүләк итү. Бәйрәмнең концепциясе режиссер Марсель Мәхмүтов тарафыннан эшләнгән. Ул миллилек белән бәйле булачак, ягъни милләтебезне саклап калуга диннең керткән өлешенә – әби-бабаларыбызның динне ничек яратулары, хөрмәтләүләре, безнең буынга нинди тырышлыклар белән алып килеп җиткерүенә багышлана. Шулай ук дини җыр, мөнәҗәт юнәлешендә иҗат итүче башкаручылар М.Вәгыйзов, В.Фазлыйәхмәтов, А.Бариева, М.Галимов, Р.Динәхмәтов, И.Халиков, Д.Шәймәрданов чыгышлары каралган. Тамашада вәгазьләргә дә иҗади төсмер бирергә телиләр. Ул гадәти вәгазь генә түгел, ә символик образлар аша бирелә торган бер күренеш булыр дип көтелә.

Чарага ир-атларга – түбәтәйдән, хатын-кызларга яулыктан килергә киңәш ителә. Милли образда килгән тамашачылар арасында бүләк уйнатылачак.

Эльмира СИРАҖИ.

●Планетабыздагы тормыш сыйфаты турындагы глобаль Numbeo мәгълүмат базасы еллык Current Crime Index – «Шәһәрләр буенча җинаятьчелек индексы»н бастырган. Рейтингка кертелгән 416 шәһәргә криминаль куркынычлык дәрәҗәсенә карап 11 дән 83 кә кадәр балл бирелгән.

●Иң имин шәһәрләр исә – Әбү-Даби (11,7 балл) һәм Аҗман (15,1 балл) (БГӘ), шулай ук Доха (14,1 балл) (Катар). Рейтингка Россиядәге биш мегаполис та эләккән – Новосибирск (188 нче урын, 47,8 балл), Екатеринбург (200 нче урын, 46,4 балл), Санкт-Петербург (262 нче урын, 39,7 балл), Мәскәү (289 нчы урын, 36,7 балл) һәм Түбән Новгород (353 нче урын, 28,6 балл).

●Индонезия башкаласы Җакартадан 18 чакрым ераклыкта Көньяк-Көнчыгыш Азиядәге иң зур чүплек – Бантар Гебанг урнашкан. Полигонга көн саен 9 мең тонна чүп-чар китерелә. Шул гаять зур чүплектә күбесе күп балалы 3 мең гаилә яши.

Халкым диеп янган йөрәк...

Габдулла Тукай тормышында якты эз калдырган күренекле татар журналисты, нашир һәм җырчы Камил Мотыйгыйның тууына 140 ел тулу уңаеннан Г.Тукай әдәби музеенда «Халкым диеп янган йөрәк…» дигән әдәби-музыкаль кичә узды.

● К.Мотыйгый туганнары кичәдән канәгать калды.

Ул К.Мотыйгый башкаруында язылган «Сәлим бабай» җырын яңгырату белән башланып китте. Әлбәттә, моның үз сере бар иде. Җыр татар халкының гимнына әверелгән «Туган тел» көенә башкарыла. Кичәне алып баручы, әдәби музейның өлкән фәнни хезмәткәре Лена Тябина бу бәйләнешне гади генә аңлатып узды. Бәлки, Габдулла Тукай «Сәлим бабай»ны остазыннан беренче тапкыр ишеткәндер һәм җырга моңга битараф булмаган шагыйрь «Туган тел»не нәкъ шушы көйне җырлый-җырлый язгандыр...

К.Мотыйгыйның гаять киң кырлы шәхес булуы мәгълүм. Филология фәннәре докторы, тәнкыйтьче Фоат ага Галимуллин – К.Мотыйгыйның иҗатын, тормышын тирәнтен өйрәнгән, аның бертуган сеңлесе Галия Кайбицкая белән дә аралашып, аңардан күп истәлекләрне ишетеп, ул язып калдырган хатирәләрне бөртекләп өйрәнгән галимебез. Ул Габдулла Тукайның матбугатта басылган тәүге шигырьләренең берсендә XX йөзне «Мәгърифәт гасыры» дип атавын искә төшерде. «Чорны мәгърифәт гасыры итүчеләрнең берсе – Камил Мотыйгый. Ул мәгърифәт гасырын тудыра, шуны үстереп җибәрә, чөнки анда белем, мәгълүмат күп», – диде ул.

К.Мотыйгый Җаек (Уральск) шәһәрендә зыялы, гыйлемле Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллин гаиләсендә дөньяга килгән. Әтисендә – «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә, рус классында да белем алган егетнең алга таба укуын Казандагы «Касыймия» мәдрәсәсендә дәвам итәргә омтылышы була. Әмма ул анда укытуның шактый түбән дәрәҗәдә икәнлеген аңлап ала. Камил, Мисырга барып, Каһирә шәһәрендәге данлыклы «Әл-Әзһәр» университетында ике ел белем эстәп кайта. Ул аннары әтисе мәдрәсәсендә гарәп теле һәм әдәбияты, мантыйк, Коръән тәфсире һ.б. буенча дәресләр бирә. Бу вакытта аңа Г.Тукайның мөгаллиме дә булырга туры килгән.

Ул, рәсми органнардан рөхсәт сорап тормыйча, Җаекта «Мәгариф» журналын чыгара башлый. Бу хакта белеп алып, тыйлар. «Әлгасрелҗәдид» кулъязма журналына да табу салына. «Чөнки ул елларда Россиядә милли телләрдә көндәлек матбугат булдыру, спектакльләр уйнау рәсми рәвештә тыелган», – диде галим. Ниһаять, 1905 елгы революциядән соң башка халыкларга да газета чыгару мөмкинлеге ачыла. К.Мотыйгыйга да «Әлгасрелҗәдид» журналын ачарга рөхсәт бирелә. «Басманы таныту ниятеннән «Игълан» дигән 20 битлек брошюра чыгаралар. Анда К.Мотыйгый булачак журналның программасын бирә. Басмада күренекле кешеләрнең фикерләре урын ала. Тукай да «Игълан»га ике шигырен тәкъдим иткән һәм, Габдулла Тукай дип, имзасын куйган. Бу – шагыйрь иҗатының рәсми журналда беренче чыгуы», – дип ачыклап үтте Фоат ага. К.Мотыйгый журнал чыгарудан шактый авырлыклар да күрә. Ул заманда матбага хуҗасы булу өчен 25 яшь тулуы кирәк була. Ә Камилгә – 22 яшь. Мотыйгулла хәзрәтнең метрикәсе үз кулында, ул улына 25 яшь, дип белешмә бирә. Шуңа нигезләнеп, Камил Мотыйгый типографияне ача. Әмма дуслар белән бергә дошманнар да бар. Аларның шикаяте нәтиҗәсендә әлеге изге ният белән эшләнгән хилафлык ачыла, Камилне дә, әтисен дә судка бирәләр, Мотыйгулла хәзрәтнең үзен ярты елга, улын 1,5 елга хөкем итү турында карар чыгарыла. Саратов адвокатларының берсе хөкем карарын юкка чыгаруга ирешә. Җаек халкыннан җиде мең кеше, Төхфәтуллиннарның гаепле түгеллеген раслап, кул куя. Шул рәвешле бередә газета-журналлар эшләп китә. Алга таба «Уклар» журналы, «Фикер», «Уралец», «Яңа тормыш» газеталары да укучылар кулына барып ирешә, Г.Тукайның да шигырьләре басылып тора.

Фоат ага Галимуллин К.Мотыйгыйның хәтта Санкт-Петербургта В.Ленин эшләгән бүлмәдә «Ярлы халык» дип аталган татарча газета чыгаруы турында да сөйләде. Санкт-Петербургта В.Ленин җитәкчелегендәге хөкүмәт 81 нче кабинетта утыра. Редакцияләргә киңрәк урын кирәклеген искә алып, бәлки 67 нче бүлмә юлбашчы өчен уңайлырак та булгандыр, алыштыралар. «Ярлы халык» газетасының нашире – Милләтләр эшләре комиссариаты, мөхәррире Камил Мотыйгый була. Беренче саны 1918 елның 6 гыйнварында басыла, әмма аның нибары 2 генә саны чыга. Газета нәшер ителүдән туктагач, аның базасында «Чулпан» газетасын чыгара башлыйлар.

«Соңрак К.Мотыйгый Мәскәүдә Тышкы эшләр министрлыгының көнчыгыш телләре буенча хөкүмәт составында тәрҗемәче булып эшли. Аннары Җаекка кайта, «Яңа фикер» газетасын нигезли. Кайда гына булуына карамастан, газета чыгара. Аның бу вакыттагы эшчәнлеген исәпкә алып, Казахстан үзәк башкарма комитеты әгъзасы итеп сайлыйлар», – диде Фоат Галимуллин.

Мәгълүм булганча, 1934 елда Мәскәү консерваториясе каршында татар опера студиясе оеша. Шушы студиянең директоры итеп К.Мотыйгыйның улы Хәмит Төхфәтуллинны билгелиләр. Ләкин 1937 елда аны нахакка гаепләп, партиядән чыгаралар, төрмәгә ябалар. Шуннан соң Камил Мотыйгыйның да эшләре кирегә китә. Аны Казахстанда партиядән чыгарып кайтаралар, яңадан алмыйлар, һәм ике дистә елдан артык ел дәвамында җыр сәнгатен күтәргәне өчен билгеләнгән персональ пенсиясеннән дә мәхрүм итәләр. Улы гаепләнгәннән соң, Камил Мотыйгыйны кайбер әдәбият-сәнгать әһелләре дә әсәрләрендә тәнкыйтьләп телгә ала. Нечкә хисле, гомере буе халкым, дип яшәгән кешегә бу хәл бик авыр тәэсир итә. Шунан соң байтак еллар аның исеме дә телгә алынмый. Фоат ага 1975 елның 25 февралендә – К.Мотыйгыйның вафатыннан соң 35 елга якын вакыт узгач – Дәүләт музеенда беренче тапкыр Камил Мотыйгыйның 90 еллыгына багышлап, аны искә алу кичәсе уздырылуы турында сөйләде. Анда тарих фәннәре докторы Рәфикъ Нәфыйгов Камил Мотыйгый турында бик тәфсилләп бәян кыла. «Бу кичә минем туган абыемны шулкадәр зурлау кичәсенә әверелде. Мин бәхетле», – дип шатлыгын Фоат ага Галимуллин белән уртаклаша наширнең сеңлесе Галия Кайбицкая. Шуннан соң ул Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры, тарих фәннәре докторы М.Мөхәррәмовка күп кенә хезмәтләрдә Камил Мотыйгыйны каралтып язуларын, моның алай түгеллеген әйтеп, мәсьәләне өйрәнүне, абыйсының исеме аклануын сорап хат яза.

М.Мөхәррәмов Г.Тукайның дүрт томлыгы чыгачагын, анда күп нәрсәне дөреслеккә туры китерәчәкләрен белдерә. Бу томнарны төзүче Рашат Гайнанов һ.б. чыннан да хилафлыкларны төзәтә. Галия Кайбицкая, китапны өстәлгә куеп, Фоат агага шул аңлатмаларны укып күрсәтә. «Бу көн дә җитәр икән» дип сөенгәне хәтердә» – диде Ф.Галимуллин. Аның әйтүенчә, халкыбызның яраткан җыры «Ай былбылым»ны да Урта Азиядән Камил Мотыйгый алып кайта, ә шигырен Нәкый Исәнбәт яза.

Язучы, тәрҗемәче Лирон Хәмидуллин 1963 елда консерватория залында К.Мотыйгыйның улы Хәмит ага белән очрашуны искә алды. Х.Төхфәтуллин бу очрашуда үзе турында сөйләми, әтисенә багышланган истәлекләр белән чыгыш ясый. «Бу вакыйгадан соң Төхфәтуллиннар белән шактый кызыксындым, берникадәр материаллар да тупладым. Миңа шулай ук озак кына Хәмит абыйның кызы, консерватория тәмамлаган Наҗия ханым Хәмитова белән дә аралашырга туры килде», – диде Лирон ага. Ул шуннан соң Мотыйгыйларга багышланган мәкаләләрен яза. «Камил Мотыйгый – Тукайның беренче остазы» дигәне «Казан утлары» журналында чыга, мәкаләләр китапларга да керә. Хәмит абый кызы Наҗия ханымның фатирында җан тәслим кыла. Аңарда әтисеннән калган архив – журналларның басма һәм кулъязма вариантлары да була әле. «Тумбочкасы Камил Мотыйгый чыгарган матбугат белән тулы иде», – дип искә алды Лирон ага. «Моны бер музей да миннән алырга тырышмый. Тукайның шигырьләре, язмалары булган саннарны гына алдылар», – ди Наҗия ханым.

Лирон ага 1903 елда Санкт-Петербургта К.Мотыйгыйның «Бәхетле Мәрьям» дигән беренче романы басылып чыгуын, әмма безнең әдәбиятта әсәрнең беркайда да телгә алынмавы турында да борчылып сөйләде. «Бәлки ул Татарстанга килеп җитә алмагандыр. Шул ук типографиядә Камил Мотыйгыйның бер пьесасы да басылып чыга. Ул да бездә искә алынмый», – диде. Лаеклы ялга чыкканнан соң, К.Мотыйгыйның тагын өч пьеса язуы турында мәгълүмат бар, алар турында да ишетелми. «Киләчәктә яшьләребез бу әсәрләрне табарга, өйрәнергә, К.Мотыйгый һәм аның улы Хәмит Төхфәтуллин турында яшь язучыларыбыз, галимнәребез яңадан-яңа ачышлар ясарга тиештер», – диде Лирон ага. Кичәгә Кайбыч районы хакимияте рәисенең урынбасары Рәмис Хаялиев, Галия Кайбицкая музее директоры Чулпан ханым Камалиева да килгән иде. «Камил Мотыйгый шәхесен аңа якын килгән саен тирәнрәк аңлыйлар. Әмма таудай олуг шәхесне бәяләп бетермибез», – диде Рәмис әфәнде. Ул язучы Нияз Акмалның, вафаты алдыннан, «Камил Мотыйгый» поэмасын яза башлавын искә төшерде. Әсәр «Мәдәни җомга» газетасында басылып чыга. Нияз Акмал да поэмада, бөек якташыгыз бар, ник аны күтәреп чыкмыйсыз, дип мөрәҗәгать итә. «Без хәлебездән килгәнчә күтәрергә тырышып карыйбыз. Җәмәгатьчелек, мәдәният әһелләре, әдипләребез, галимнәребез бу теманы бергәләп күтәреп, бәлки К.Мотыйгыйны, аның тууына 145, 150 ел булган чакта тиешле дәрәҗәдә зурлый алырбыз», – диде Р.Хаялиев.

Филология фәннәре докторы, текстолог Зөфәр Рәмиев «Тукай» энциклопедиясендә Камил Мотыйгый, Галия Кайбицкая, Мотыйгулла Төхфәтуллин турында да мәкаләләр булуын искәртте. Галим «Җыен» фонды бик әһәмиятле җыентыклар чыгаруын әйтеп, бер китапның Камил Мотыйгыйга багышлап чыгарылачагына өмет белдерде.

Кичәдә Камил Мотыйгыйның туганнары да катнашты һәм чыгыш ясады. Ә Галия Кайбицкаяның оныгы, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, танылган рәссам Ильяс Айдаров музейга күп кенә картиналарын бүләк иткән. Ул бу юлы да «Габдулла Тукай һәм Камил Төхфәтуллин», «Галия Кайбицкая Нәҗип Җиһанов белән» дигән картиналарын Г.Тукай әдәби музеена тапшырды.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотосы.

«БЕЗ – БЕР ТАТАР ХАЛКЫ»

Быелгы мөгаллимнәрнең «Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы» исеменә төбәкләр арасында беренче урынга Төмән шәһәренең 52 нче урта мәктәбе укытучысы Халидә Кирамова лаек булды. Җомга иртәсендә очрашканда, Халидә ханымның беренче урын алуы әле билгеле түгел иде. Беренче өчлеккә керүе генә тәгаен иде.

– Халидә Хәлидулловна, үзегез турында сөйләгез әле.

– Мин Төмән өлкәсе Яркәү районы Сәет дигән татар авылында тудым. Әнием – Бурбар авылыннан. 2002 елдан Төмән шәһәренең бердәнбер этномәдәни компонентлы мәктәбендә эшлим.

– Авылның сигезьеллык мәктәбен тәмамлагач, Төмән педагогия училищесына укырга кердем. Аннан соң шул ук Сәет мәктәбендә башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшләдем. Мин – укытучылар династиясеннән, мәктәптә әнием белән бергә эшләдек. Бер елдан соң Тубыл педагогика институтына укырга кердем. Читтән торып укырмын, дигән идем, ә анда рус-татар бүлеге ачылган икән. Шунда керергә тәкъдим иттеләр. Укуны тәмамлагач, институтта кафедрада эшләп алдым. Аннан соң 52 нче мәктәпкә килдем. Халыклар әдәбияты буенча аспирантураны тәмамладым. Татар әдәбияты буенча күренекле язучы, педагог Якуб Зәнкиевнең публицистик әсәрләрен өйрәндем, шулай кандидат дәрәҗәсенә җиттем.

3 ел элек безнең мәктәп яңа бинага күчте. Аңа кадәр мәчет бинасында укыган идек. Былтыр беренче тапкыр 11 нче сыйныф укучыларын чыгардык, аңа кадәр тугызъеллык мәктәп идек.

Мәктәптә 4 татар теле һәм әдәбияты укытучысы бар. Дипломым буенча мин – татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты укытучысы. Былтыр 11нче сыйныф укучыларын рус теленнән имтиханга әзерләдем. Мәктәптә рус телен дә, татар телен дә укыту бик уңайлы, дип саныйм. Балаларга чагыштырып аңлата алам.

– Бәйгегә ничек килдегез?

– Өлкәдә ел саен «Мәдәниятләр диалогы» дигән фәнни-практик конференция уза. Конференция кысаларында «Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы» бәйгесе уза. Татарстанның Фән һәм мәгариф министрлыгыннан белгечләр килә. Анда беренче урын алганнар монда килә.

Бәйге өчен портфолио ясадык, документлар җыйдык, дәресне видеога төшердек. Министрлык безгә тема бирә. Миңа Фаил Шәфигуллинның «Акмөгез» әсәре эләкте, аның буенча дәрес әзерләдем. Укытучылар өчен гаҗәпләнү педагогикасына багышланган осталык дәресе үткәрдем. Төрле программалар куллану буенча тәҗрибә белән уртаклаштым. Методик остаханәмдә уку грамоталылыгы турында сөйләдем. Тәрбия сәгатен «Кунакчыллык» темасына багышладым.

– Сез кечкенәдән «укытучы кызы» дигән горур исемне йөрткәнсез.

– Мин мәктәптә үстем. Хәзер үземнең балалар да мәктәп мохитендә. Улым физика укытучысы булып эшли, кызым 2 нче курста укый, математика укытучысы булырга әзерләнә. Бик яратып, татар теле олимпиадаларында катнаша.

– Укытучы булмасагыз, кем булыр идегез?

– (Пауза) Укытучы булыр идем.

– Башка өлкәне сайлау турында уйлар булган идеме?

– Балалар да: «Халидә Хәлидулловна, ник сез укытучы булдыгыз?» – дип сорый. Мәктәпне тәмамлагач, икенче төрле уй булмады да. Мәсәлән, мин җырларга яратам. Әмма җыр буенча бару уйда да булмаган. Педучилищега китәбез! Ул вакытта конкурс та зур иде.

– Авырлыклар булдымы?

– Һәр чорның авырлыгы булгандыр. Мин дистә ел өлкән сыйныфлар белән эшләдем. Быелдан 5 нче сыйныфларның класс җитәкчесе булдым. Анда 39 бала. Аларны җыярга, утыртырга башта авыррак булды. Рус теле белән бергә татар телен яраттырырга, кызыксыну уятырга җиңел түгел. Кызыксынып, яратып эшләсәң, ул да авырлык тудырмый.

Хәзер укытучы булып эшләргә бик җайлы. Яңа технологияләр, алымнар, электрон әсбаплар, кушымталар – барысы да бар. Программаларда үзем дәресләр төзим. Аудио, видеоуеннар кертергә була. Әлбәттә, вакыт кирәк. Мәктәптә үз эшенең фанатлары гына кала.

– Ә ничек яраттырырга, балада телгә мәхәббәт уятырга, кызыксындырырга?

– Беләсезме, бу – бүген үк, хәзер үк мәхәббәт уятам, дигән сүз түгел. Бала мәктәптә татар телен укыса да, бәлки, «яратам» дип әйтмәс. Үскәч исенә төшерер: татар китабын укый башлар яки балалары белән татарча сөйләшер. Ә без яңа технологияләр, иҗади биремнәр аша мотивация бирергә тырышабыз. Олимпиадаларга, бәйгеләргә әзерлибез. Татарстан лагерьларына юлламалар да бирелә.

– Дәрестә татарча сөйләшкән бала тәнәфестә, дәрестән тыш татарча сөйләшәме?

– Сирәк. Шулай да, ата-аналар татар телен белүнең файдасын күрә. Бала кайсы өлкәгә барып керсә дә, татар теленең зыяны булмый. Өйдә татар телендә сөйләшүче гаиләләр бар. 30 мартта бездә шигърият бәйгесе уза. Анда балалар рус, татар телендә шигырьләр сөйли. «Вакытыгыз тыгыз булса, мин татар шигырьләрен эзли торыйммы?» – дип язган бер әни. Ата-анада кызыксыну бар.

3 ел элек мәктәптә 370 бала иде, аларның 80 проценты татар булгандыр. Яңа мәктәптә 1,5 меңгә якын бала укый, аларның 60 проценты татар. Гомумән, 8-9 милләт баласы укыйдыр бездә. Һәр кеше үзенең туган телен белергә тиеш, дип аңлатам.

– Матбугат очрашуында, татар теле дәресеннән могҗиза ясарга кирәк, дигән фикер әйткән идегез. Ничек ясарга?

– Могҗиза ук булмаса да, һәр дәрес ачыш булырга тиеш, бала гаҗәпләнерлек мәгълүмат алып чыгарга тиеш. Татар теле дәресенә бер дәреслек кенә күтәреп керү – җинаять. Балалар, халкың алдында җинаять. Туган тел – бөтен фәннәрнең нигезе.

– Сезгә алмашка килергә татар теле укытучылары бармы?

– Бу – авыр сорау. Бездә Төмән дәүләт университетында факультет бар иде, ул ябылды. Тубыл педагогия институтында ябылды. Яшьләр Казан федераль университетына килеп укый. Бер укучым татар теле укытучысына укырга керергә җыена. Квалификацияне үзгәртеп килүчеләр бар.

– Казан белгечләрне үзендә калдырырга тырыша бит.

– Әйләнеп кайтырлар әле...

– Ата-аналар арасында «татар теле белән бала кая барыр» дип фикер йөртүчеләр бар.

– Андыйлар бардыр, әмма миңа очраганнары юк. Әлбәттә, бу хакта ишетеп торам. Ата-аналарга татар телен укуның мөһимлеген аңлатырга кирәк. Бәлки, хәзер кирәкми кебек, соңыннан ул бала, нигә укымадым икән, дияр. Татарча әсәрләр укыганда, аңламаган балаларны бераз җәллим. Тәрҗемә итеп төшендерәбез, тик татар телендә – ул бит бөтенләй башка...

– Күптән түгел, Себер татарлары диалектын татар әдәби теленнән аерырга, дигән фикерләр яңгырады. Бу мәсьәләгә ничек карыйсыз?

– Мин 90 нчы елларда институтта укыдым. Ул вакытта татар теленең тарихын да өйрәндек, заманча тел буенча да дәрес бар иде. Безне Хәнисә Алишина, Равил Вафиев укытты. Аларның лекцияләре әле дә исемдә. Алар бит фәнгә нигезләнеп аңлаткан. Алар «бу – диалект» дип өйрәтте. Диалектның үзенчәлекләре турында сөйләделәр. Без «тубыл-иртыш диалекты», дип өйрәндек.

– Сезне әдәби телдә укыттылармы?

– Әйе, укыту әдәби телдә иде, диалект үзенчәлекләрен безгә аңлаттылар. Мин аны үзем дә диалект дип уйлыйм. Төмән өлкәсендә бу диалектта китаплар бастырыла. Авылларда сөйләм үзенчәлекләре бар. Без барысын да аңлыйбыз. Үзенең диалект телен дә белмәгән кешегә әдәби телне аңларга авыр, дип уйлыйм. Бу мәсьәләгә карашлар төрле, әмма без барыбер бер халык – татар халкы. Бердәм булырга кирәк.

– Бу процесс мәктәпләргә кагылмасмы?

– Бала «кишер» дисен, «сәртәк» дисен – ничек булса да, татар телендә әйтсен. Без шуңа шатланабыз.

– Үзегез дәресләрне әдәби телдә алып барасызмы?

– Әдәби телдә! Без дә диалект үзенчәлекләрен аңлатабыз. Бәлки, баланың өендә шырпыны «серәнкә» дип йөртәләрдер. Дәрестә барлык нечкәлекләрне аңлатабыз.

– Себер татар телендә дәреслекләр чыгамы?

– Укытучы булып эшләгән Галия Абайдуллина, язучы Клара Кучковская үз китапларын бастыра. Без аларны класстан тыш чарада, төбәкләр әдәбиятын өйрәнгәндә, эзләнү-тикшеренү эшләрен башкарганда кулланабыз.

– Телне аеруга халыкның мөнәсәбәте ничек?

– Мин төпкә керә алмыйм, әмма укытучылар минем фикердә, дип уйлыйм.

– Ирегез кем булып эшли?

– Ул – автокранчы. Тормыш иптәшем – Актаныш районы Әнәк авылыннан. Ул безнең авылга кунакка килгән иде, шунда таныштык. Хәзер инде 30 елга якын бергә.

– Нинди хыяллар белән яшисез?

– 5нче сыйныф укучылары белән бирелеп эшлим. Алар татар бию түгәрәгенә йөри башлады. 11 нче сыйныфка кадәр, бераз гына булса да, татарлык сеңдерәсе иде аларга.

Гөлүзә ИБРАҺИМОВА

intertat.tatar

Сания ӘХМӘТҖАНОВА

ХӘТЕР БАГЫНДА

ТЕТРӘНҮ

Бар дөньяның асты-өскә килде,
Уянгандай булды җир гафләттән[1].
Күк ярылды, тау ишелде өскә
Качып котылмак юк бу афәттән.

Тынычлык һәм хозур таба иде,
Кайтып һәркем тыныч куышына.
Бүген шаһит булды үз оясы
Күпме җанның соңгы сулышына.

Үз җаена барган бу гомерне
Рәхәт кенә кичү иде өмет.
Яшәү белән баглап тора икән
Бер йотым су, бер кабарлык симит[2].

Күкрәгенә баскач гүр газабы,
Кыскач таш эскәнҗә[3] арасына.
Исән чыгу уе «Аллаһ» сүзен,
Хәтерләтте Адәм баласына.

Төркиянең чиксез корбаннарын
Кайтарырга мөмкин түгел кире...
Йөрәк кубарыла, җан тетрәнә,
Бер тарафым – үле, берсе тере...

«Каһраманмараш» дип тибә йөрәк,
«Хатай», «Шанлыурфа», «Адыяман»...
Белеп булмый: бүген монда – хәвеф,
Ә иртәгә кемгә – нәрсә язган...

Чайкалганда, җирем тотып кала,
Баш түбәмне тери имин күгем.
Якыннарым кул сузымы гына,
Һәр сулышым бәхет икән бүген!

Акыл җитмәс гасыр фаҗигасен
Күтәрешсәк кенә бергә-бергә,
Кабул итсәк үз кайгыбыз кебек,
КЕШЕ булып калырбыз без җирдә.

АЛТЫН ЛАЛӘНЕҢ АНА ВАТАНЫ

Борынгы сәлҗүкләрдән Госманлы чорына килеп ирешкән, алтын һәм көмеш җепләр белән күпертеп сырылган нәфис нәкыш-бизәкләр төрекчә «сим сырма» дип атала.
Соңрак, Солтан Мәхмәт II гә хатынлыкка – Госманлы падишаһ сараена – Төркиянең Каһраманмараш өлкәсе Әлбистан шәһәре сылуы Ситти Мүкримә килен булып төшә. Аның бай бирнәсе арасында килеп, Истамбул һәм румнар илендә тамыр җәйгән чигү үрнәкләре Ситтишаһ-Хатунның туган җире исеме белән «Мараш эше» дип танылу ала.

1

Төшләремдә күрдем ука җеп белән
Чигү чиккәнен, һай, Мараш кызының...
Нәфис бармаклары гүя тибрәнә
Көмеш кылларына кунып сазының.

«Түркү» моңы булып шыта ефәктә
Алтын таҗлы чәчәк – тулып-тулышып.
Ситти Мүкримәнең гүя күз яше,
Көмеш тамчылардай тама куышып.

Шәһре Әлбистанның затлы кәләше
Бирнә чиккән, диләр, төннәр утырып;
Күз нурларын сирпеп лалә гөленә,
Алтын ука җепләр белән тутырып.

«Кырык качыр[4] бирнә төяп килгән» дип,
Солтан Мәхмәт сараенда дан алыр...
Истанбулдан Госманлыга ирешеп,
Ошбу даны дастан булып таралыр.

Каһраманмарашның нәкыш-гөлләрен
Госманлы осталар чәчәк аттырыр:
Ука сырып, таҗ-бизәкләр калкытып,
Бөтен дөньяда балкышын арттырыр.

2

Уяндым мин таңда куркып-сискәнеп,
Җир тетрәде... өндә әллә төштәме?
Әлбистанда чигү чиккән кәләш кыз
Чорлар аша әллә миңа дәштеме?

«Сакла, – диеп, – зинһар, төрки кардәшем,
Зилзиләләр кичкән уртак чигешне.
Күр синең дә халкың һөнәр-кәсепле:
Болгар читегең үзеңә килешле».

Әлбистан – «Сим сырма» Ана Ватаны,
Матәм сөреме йоккан карашына, –
Мүкримә Солтан багадыр күкләрдән
Үле шәһәр Каһраманмарашына...

Язгы кояш, тәрәзәмә үрелеп,
Көлтә-көлтә алтын җепләр яудырды.
Тулган ай да, күк-гөмбәздә калкуга,
Көмеш ука сузып таңга калдырды.

Затлы төрки өммәтеннән нәселем,
Калфагымда алтын нәкыш – утчәчәк.
Кардәшлекнең мәңге сулмас тамыры,
Хәтер кичеп, Әлбистанга җитәчәк.

БАКЫРЧЫЛАР БАЗАРЫ

Искә ала дустым, гади бакыр шәмдәл кысып учларында,
Кунак булган чагын Мараш шәһәрендә – төрек дусларында.

Туган йортын күреп, әти-әнисенең сый-нигъмәтен татып,
Шәһәр гизгән алар, уйларында төрки тамырына кайтып.

– Гаҗәп бер базарга килеп чыктык беркөн, җәяү барган чакта.
Бакырчылар рәте: шунда ясый тора, шунда тауар сата...

Үзе сөйли дустым, үзе уйга чумган... күз карашы – томан...
Гүя бакыр шәмдәл кайнар учларыннан эреп тамар сыман.

– Чаң-чоң, чаң-чоң, чаң-чоң... Бакыр төя чүкеч – остаың үз эше.
Һөнәрчеләр рәт-рәт, бакыр тауар мулдан... юк алучы кеше...

Тирән җиз ләгәннәр... Су кайнатсаң ярый... кер юарга бара...
Төрле яктан: чаң-чоң... Башка тавыш каба – түзеп торып кара.

Ә остага нәрсә? Ул үз эшен белә. Ишетә тик үзен.
Җеге-җеккә килсен: бакыр гафу итми, читкә алсаң күзең.

Көтеп бер остаың туктап тын алганын, сәлам бирәм аңа:
– Эшләр кулай килсен! Табыш ягы ничек? Көнгә күпме «тама»?

Таптым бирер сорау!.. Шулчак оста, йөзен миңа таба борып,
Иске таныш кебек, җавап сәлам бирде, басты аннан торып.

– Табыш диеп түгел... Ата-баба эшен саклап калу өчен,
Шушы һөнәрчеләр, изге бурыч санап, түгә тирен-көчен.

Мин дә үз атамнан бакырчылык эшен күреп-отып алдым.
Инде кырык еллап шушы һөнәремә, әйтик, тугры калдым.

Кемгә мирас итим агач чүкечемне?! – Көч-гайрәтем китә.
Китә кулдан һөнәр... Яшьләр күңел бирми – бакырчылык бетә...

Төрек агай шулчак, уңга-сулга карап, әрле-бирле килде.
Рәтләр арасыннан бу шәмдәлне сайлап, миңа алып бирде.

Һөнәр бетә, диде... Белмәгәнбез ул чак тулы бер шәһәрнең
Җирдән язачагын. Үзгәндә булган Мараш бу мәһшәрнең...

Тынып калды дустым, бакыр шәмдәленә тагын карап алды.
– Һөнәрчеләр җире – Мараш төсе булып, шушы шәмдәл калды...

Мин дә искә алдым үткәннәрдән мирас – иске җиз ләгәнне,
Комган, бакыр чүмеч... Музейханәләрдә тагын йөзләгәне.

Асылыбыз бетсә, килер буыннардан яумас безгә миннәт[5].
Тәүбә!.. җуйсак туган телне, тарих кына булып калса милләт.

ШАГЫЙРЬЛӘР БАКЧАСЫ

1

Шигырь мәркәзе – Каһраманмараш,
Шагыйрь ядына үзгә бер караш.
Ачык китаптай, шагыйрьләр багы[6]:
Күңелнең шигырь сораган чагы...

Туктал бакчада, вакыт чапмасын,
Монда башка гамь эзләп тапмасын.
Кара шагыйрьнең син сурәтенә,
Күңелең багла шигъриятенә.

Назыйм Хикмәт тә әнә ни дигән:
«Сине хәтерләү – ни рәхәт икән!»
Ашугъ Махсуни, Нәҗип Фазыл да –
Егерме берәү алар, асылда.

Шушы төбәктә, шушы җирлектә
Туып үскәннәр, шагыйрь булганнар.
Кайсы – кай якта хикмәт эзләгән,
Нинди гамәлләр алар кылганнар...

Уйлан бакчада, уйга тал да син,
Укы, каршыңа китап ал да син.
Төрки шагыйрьләр – милләт багында,
Әле укучы кеше барында.

2

Бакча юк инде – Күкләр әмере,
Карар кылалмый ханы, әмире...
Шигырь багыннан кичте гарасат,
Гарасат – җанда, уйлап карасак.

Кай гөнаһларны аңлап кылмадык,
Аңлап алсак та, туктап калмадык?
Назым[7] әйтсәк тә, хикмәт белмәдек:
Белми еладык, белеп көлмәдек.

Шагыйрь бакчасы калкыр яңадан,
Киткәннәр тумас кабат анадан.
Шагыйрь чын булса, шигыре калыр,
Укый белгәннәр аң-гыйбрәт алыр.

«Шөгарә»[8] булсын – шагыйрь сүрәсе,
Ялган сүз өчен – җәза күрәсе.
Шигъри гөлбакча җанда түгелме?
Шигырь бакчасы итик күңелне.

---

[1] *гафләт йокысы – ваемсыз, игътибарсыз йокы халәте.*

[2] *симит – Төркиядә киң танылган клиндер, боҗра рәвешендәге вак күмәч.*

[3] *эскәнҗә – кыскыч, пресс.*

[4] *качыр – ишәк белән ат кушылганы; русча – мул.*

[5] *Миннәт – иске китап сүзе: асралуы, яшәве өчен бурычлылык.*

[6] *Каһраманмараш шәһәрендә 2012 елның май аенда ачылган «Шагыйрьләр паркы» 2023 елда җир тетрәүдә зыян күрде.*

[7] *Назым – иске китап сүзе: шигырь, шигъри төзелеш.*

[8] *Изге Коръәндәге 227 аятьтән торган 26 нчы «Шөгарә» («Шагыйрьләр») сүрәсе күз алдында тотыла.*

09.03 – 10.03. 2023.

Бөекбритания галимнәре даһи табиб, галим, философ Әбүгалисинаның якынча йөз чалымнарын барлауга ирешкәннәр. Образы галимнең баш сөяген Хамадандагы мавзолейдан күчергәндә төшерелгән фотоларга карап булдырылган һәм... ни гаҗәп, аның тышкы кыяфәте галимгә куелган барлык һәйкәлләрдәге йөзләрдән аерыла.

● Дүшәнбедә һәйкәл.



БУЙ ҖИТМӘСЛЕК ӘБҮГАЛИСИНА тавы





X-XI гасырларда, Урта Азиядә хезмәт куйган күп галим-энциклопедистлар кешелек алгарышына зур йогынты ясаучылар санала. Шундый гыйлемдарларның берсе – Әбүгалисина. Ул 980 елның августында Изге Бохара янәшәсендәге Афшана авылында туган һәм 1037 елның июнендә вафат булган. Гадәттәгечә, күп милләтләр әлегәчә аны үзенеке дип масларга тырыша.

Акыл иясе үз гомеренең беренче утыз елын автобиография формасында язып калдырган. Ул гасырларда сарай галимнәре мондый хезмәткә алынырга курыккан. Гадәттә, алар падишаһлар тормышын тасвирларга гына җөрьәт иткән...

Әбүгалисина язмышы бәхетле башланып китә, чөнки ул бай гаиләдә үсә. Әтисе Адаллаһ ибне Хәсән салым, ясак җыючы була. Ихтирамга лаек һөнәр иясе түгел, хезмәте дә авыр... Әмма шуңа да карамастан әтисе бай, укымышлы, зыялы зат буларак мәгълүм. Ул үз үлеме белән үлә. Әнисе – Ситара (бу исем «йолдыз» дип тәрҗемә ителә). Ул да Афшана җирлегендә үскән хатын-кыз. Гаилә Бохарага күченгәч, ир бала өчен тирән гыйлемгә юл ачыла. Бохарада зыялылар күп. Баланың гаять акыллы, кызыксынучан холыклы булуын, сораулар яудырып кына торуын тиз абайлыйлар. Әле беркем дә бу малайның киләчәктә хәтта Хамаданда вәзир булачагын күзалламый. Ләкин мондый вазыйфалар аның язмышына язылган инде.

Әбүгалисина 10 яшендә үк Коръәнне ятлап бетерә диярлек. Малайны мөселман кануннарына өйрәтүче мәктәпкә бирәләр, ә андагы өлкәнрәк шәкертләр шушы 12 яшьлек малайдан киңәшләр сорый башлый. Ул гарәп телен, стилистиканы, грамматиканы яхшылап өйрәнә һәм соңрак Бохарадагы галим Әбү Абдаллаһ Натил җитәкчелегендә логика, философия, геометрия, астрономиягә төшенә. 14 яшендә фәннәрне үзлегеннән өйрәнә. Барлык фәннәр, шул исәптән музыка фәне дә аңа бик җиңел бирелә. Аристотельнең «Метофизика»сына гына галим Әл-Фараби язган «Метафизика» комментарийларын укып төшенергә туры килә. Яшүсмернең хәтере феноменаль булуын искә алу да урынсыздыр.

Бер көнне 16 яшьлек зиһен иясен Бохара әмирен дәваларга чакыралар. «Медицина нигезләрен өйрәнүемне китапларга карап кына түгел, авыруларны күзәтеп тә тулыландырдым», – дип язачак әле ул автобиографиясендә. Әбүгалисина хезмәтләрен гарәп телендә яза, әлбәттә. 18 яшеннән алып үзен җитди фән юлына багышларга карар кыла. Хәтта «медицина» термины ук «Метод Сина» дигән сүздән барлыкка килгән дигән фараз яши. Өстәвенә, ул сарай китапханәсенә дә кайчан тели, шунда керә ала. Ә мондый хокук һәркемгә дә бирелми. Шул чакларда ук ул Көнчыгышның иң зур галимнәре белән хатлар алыша, алар белән физика, философия, астрономия мәсьәләләре турында бәхәсләшә һәм... үзе дә галим буларак таныла бара. Европа табибләре арасында да абруй казана башлый. Бик күп вакытын фәнни хезмәтләр язуга сарыф итә. Аның популярлыгыннан курыккан дин әһелләре Әбүгалисинаны Аллаһ Тәгаләгә ышанмауда гаепләргә омтылып карый.

Егет 997 елда Бохарадан Хәрәзмгә күчә. Һәм анда 15 ел, 1012 елга кадәр яши. Ул бәхетле, чөнки андагы хаким Хәрәзмдәге галимнәр өчен акча кызганмый, фәнни һәм мәдәни прогрессны хуплый. 997-998 елларда гаять көчле фарсы галиме, энциклопедист Әл-Бируни да Әбүгалисина белән хатлар алышып, космогония һәм физика фәненнән белем туплый. Галим 1002 елда Үргәнчтәге фән үзәгендә – хәрәзмшаһ Мамун академиясендә эшли. Анда, гомумән, галимнәр бик күп була. Әйтик, Әбүгалисина почмакларны үлчәү буенча язган үз хезмәтен галим-табиб Әбү Сәһл Масихигә багышлый.

Әл-Фараби белән исә музыка кораллары фәненә дә нигез сала (Европада әлеге фән шактый соңрак үсеш ала). Ул бар музыка коралларының диярлек аталышларын, квалификациясен язып, аларның төзелешләренә кадәр аңлата. Галим Урта Азиядә киң таралган кыллы музыка коралы – гиджакны уйлап табучы булып та санала.

Әгәр дә Газнәви солтанлыгы белән яман холыклы солтан Мәхмүд Газнәви патшалык итә башламаса, даһи табиб үз хезмәтендә булып, тыныч гомер кичерер иде, ләкин коллыктан котылып, баеп киткән гаиләдән чыгышлы Мәхмүд әшәке бәндә булып чыга. Ул Бохарада зыялылар күбәюе хакында белешкәч тә, аларны үз хезмәтенә чакырырга хыяллана башлый. Хәрәзм хакименә: «Бар галимнәрне Газнәвигә китерергә!» – дигән фәрманны җиткерәләр. Һәм бу хаким шагыйрьләргә, галимнәргә кәрван белән башка җирләргә качарга киңәш итә. Әбүгалисина да дусты Әбү Сәһл Масихи белән төнлә Хәрәзмнән чыгып китә. Мәхмүд аны бик эзли, хәтта листовкалар да тараттыра, әмма уңышка ирешми. Әбү Сәһл Масихи – «Табиблек сәнгате буенча йөз китап» дип исемләнгән фундаменталь хезмәт авторы, шагыйрь, төгәл фәннәр белән кызыксынучы галим. Ләкин, ни кызганыч, ул 40 яшендә сахрада эссе сугып, тиз арада үлеп китә. Әбүгалисина берүзе кала. Ниһаять, ул Көнбатыш Иранга барып җитә. Әмир вазыйфаларындагы Кабус Әбүгалисинаны шатланып каршы ала. Кабус үзе дә бик матур шигырьләр яза икән! Әлеге әмир янәшәсендә шул гасыр зыялылары күп була. Тыныч һәм бәхетле көннәр дә килеп җиткән төсле! Әмма галим кызыксынучанлыгын баса алмыйча, Үзәк Иранга юнәлә.

1015-1024 елларда Хамаданда яши, фәнни эшләр язудан кала, күп вакытын әмирлектәге дәүләт эшчәнлегенә дә багышлый. Әмир Шәмс әд-Дәүлне уңышлы дәвалаганы өчен, ул вәзир итеп билгеләнә һәм идарә эшен, гаскәр системасын үзгәртүгә бәйле үз тәкъдимнәрен башкаларга да җиткерә. Ләкин шушы яхшы ниятле гамәле аркасында хәрби даирәләрдәге дошманнары санын гына арттыра. Үзгәрешләр беркемгә дә кирәк булмый. Әмир хәрбиләрнең Әбүгалисинаны җәзалап үтерергә теләүләренә каршы төшә. Тик шулай да аны вәзирлектән ала һәм хәтта әмирлектән чыгарып җибәрергә карар кыла. 40 көн үтә. Әмирнең сәламәтлеге начарая, аны өянәк тота. Ул галимне кичекмәстән эзләп табырга куша. Әбүгалисинаны янә министр итеп билгели. Әмма әмир вафатыннан соң Әбүгалисинаны, Исфахан хакименә хезмәткә күчергә теләгәне өчен, дүрт айга төрмәгә ябып куялар. Ул анда да фәнни хезмәтләрен язу белән мәшгуль була. Әмирнең улы галимнең үз янәшәсендә калуын тели, чөнки табибнең даны еракларга таралган! Төрмәдән чыккан галим ир туганы һәм бер тугры укучысы белән Исфаханга китә. Кала – матур, шау-шулы, җете, биредә халык күп! Шулай итеп 1023-1037 елларда, гомеренең соңгы елларын Исфаханда

● Әбүгалисина сурәте Таҗикстан акчасына төшерелгән.

әмир Галә әд-Даулә сараенда хезмәт итеп үткәрә. Биредә хәтта обсерватория да ача. Ерак араларны билгеләү өчен үзенчәлекле метод, астролябияне алыштыра алырлык үзенчәлекле инструмент уйлап таба, аның белән санап карый. Һәм әлеге инструментта нониус принцибы дөньяда беренче тапкыр кулланыш таба. Әмир аның фәнни эшчәнлеге өчен яхшы шартлар булдыра. Әбүгалисина аның баш табибе дә, киңәшчесе дә була. Галим әмирнең хәрби походларына да ияреп чыга.

Ләкин нәкъ шушы елларда галимне тәнкыйтьләүчеләр саны арта бара һәм ул әдәбият, филология өлкәсенә күбрәк игътибар итә башлый. «Китап әл-Канун фи-т-тыйбб» хезмәтен тәмамлый (әлеге хезмәт – грек, рим, һинд, Урта Азия табибләренең карашларын, тәҗрибәләрен үз эченә алган китап. Латинча да утыз тапкырдан артык нәшер ителгән әсбап. Күп гасырлар буе Европада һәм Көнчыгышта куллану өчен мәҗбүри саналган дәреслек булып тора. Ул Европадагы бик күп телләргә тәрҗемә ителгән). Әмма Әбүгалисина кульязмаларының күбесе, шул исәптән 20 өлештән торган «Китап әл-инсаф» та янгында юкка чыга. Чөнки Мәхмүд солтаннан соң патшалык иткән Мәгъсуд Газнәви Исфаханга гаскәр җибәреп, ут төрттерә, Әбүгалисинаның йортын, китапларын яндырта.

Әмир белән бергәләп хәрби походларда йөрүче галимнең ашказаны авырта башлый. Ул үз-үзен дәвалый алмый. Табиб буларак организмының хәл-көче төкәнгәнен аңлый. Үлеме алдыннан даһи галим: «Без тулысынча аңыбызда килеш үләбез һәм бер нәрсә – үзебезнең берни белә алмаганлыгыбызны аңлауны гына үзебез белән алып китәбез»,– ди. Галим юлда вафат була. Үлеме алдыннан таныш булмаган берәүгә үз васыятьнамәсен әйтеп яздыра. Бар байлыгын ярлыларга бүлеп бирергә, ә хезмәтчеләрен бүләкләп, иреккә җибәрергә куша. Тик кешеләр аның үлеменә ышанырга теләми. Ул бит күпме инсанны үлем тырнагыннан йолып калды... Ничек инде үз-үзен дәвалап терелтә алмасын, ди. Галим: «Мин күп төеннәрне чиштем, бары тик үлем төенен генә чишә алмадым», – дип язса да, аның гомере ничек шулай тәмамлана ала?! Бу нисбәттән дөньяда бер риваять барлыкка килә: Әбүгалисина үзе үлгәннән соң тәненә җан кертү өчен киркәле 40 дару әзерләп куйган булган, имеш. Укучысына: «Мин үлгәч тә, аерым бер тәртип буенча дару бирерсең» – дигән икән. Укучысы биргән дарулар искиткеч тәэсир итә – галимнең тәне көннән-көн яхшыра, ул хәтта яшәрә бара. Менә торып утырыр да, сөйләшеп тә китәр төсле инде! Укучыны бу хәл тетрәндерә, ул 40 нчы эликсирны кертү өчен табиб янына килгәндә, бик нык дулкынлану сәбәпле, дару салынган савытны калтыраган кулларыннан төшереп җибәрә. Әбүгалисинага җан иңми кала...

Галимнең җәсәден Хамадан каласы дивары янына җирлиләр, хәзер ул шушы шәһәрдәге мавзолейда саклана.

Кешелек өчен чиксез файдалы 450 дән артык фәнни хезмәт язып калдырган, урта гасырлардагы ислам дөньясына зур йогынты ясаган шәхеснең фәнни эшләрнең нибары 274 е генә безнең гасырга кадәр килеп ирешә. Аның китаплары дөнья китапханәләрендә саклана. Әбүгалисинаның 1650 елга кадәр университетларда кулланылган ике генә мөһим хезмәте: биш томлы медицина энциклопедиясе булган «Китап әл-Канун фи-т-тыйбб» һәм фәлсәфи, фәнни «Китап әш-Шифа» энциклопедиясе генә сакланып калса да, Әбүгалисинаның исеме кешелек тарихына җуелмас кара белән язып куярга лаеклы. Мәсәлән, «Китап әл-Канун фи-т-тыйбб» хезмәтенең ике өлеше дару ясауга, аларны ничек итеп куллануга багышланган. Тасвир ителгән 2600 даруның 1400 е исә үсемлекләрдән ясалган... Европада китап басу станогы уйлап табылгач, «Китап әл-Канун фи-т-тыйбб» Библиядән соң ук нәшер ителә.

Нибары 57 ел эчендә Әбүгалисина белемнең 29 өлкәсендә уңыш казана... Химик һәм микробиолог Л.Пастер тарафыннан ачылган вирусларга кадәр әле бихисап еллар элек үк Әбүгалисина кайбер бизгәк чирләрен «кечкенә нәрсәләр» барлыкка китерә, дип әйтә. Чәчәк авыруының йогышлы булуын беренче булып искәртә, ваба белән чуманың аермалыкларын барлый, «эпилепсия» терминын кулланышка кертә, махау һәм сары чирләрен дөрес итеп тасвирлый. Менингит, колак, теш авыртуы, ашказаны җәрәхәте, йөрәк чирләренең һ.б. сәбәпләрен, дәвалау ысулларын аңлата. Авыруларның тискәре хисләр белән бәйләнеше булуын анализлый.

«Пульс хакындагы трактат» пульс, кан тамырлары тибеше буенча диагноз куюга багышланган, трактатта ул пульсның дистәләрчә төрен тасвирлый. Бу нисбәттән бер риваять тә яши. Бохара сәүдәгәренең кызы чирләп китә, имеш. Бер табиб тә дөрес диагноз куя алмагач, сәүдәгәр Әбүгалисинаны чакыра. Галим кыз пульсын тоеп, Бохара урамнарын атый. Аннары аерым бер урамнарда яшәүчеләрнең исемлеген китертә, шул кешеләрнең берсенең исемен әйткәч, кызның йөзе бик нык алсулана. Шулай итеп, Әбүгалисина кыз гашыйк булган егетнең исемен ачыклый. Кыз этисе аңа әлеге егет белән гаилә корырга рөхсәт итмәс дип уйлап, нык чирләп киткән икән. Бервакыт ул үтә ябыккан егетнең пульсын тыңлап, берникадәр сүзләр әйтә һәм аларның кайсы аңа гаять тискәре йогынты ясавын аңлый, дөрес диагноз куя.

Әбүгалисина 2 мең төрле чиргә диагноз куеп, дәвалый алган. Хәзер инде чирләр саны тагы да күбрәк. Әмма табибләр күп очракта аларның симптомнарыннан гына арындыру белән мәшгуль. Дарулар куллану иммунитетны зәгыйфьли, ә Әбүгалисина ул чакларда ук табигый баланс булдыру хакында ассызыклаган, физик күнегүләргә, физик эшкә игътибар биргән.

● Әбүгалисина мавзолее.

● Хамаданда Әбүгалисина кабере.

Ул күп кенә җитди хезмәтләрен дүрт юллык шигырьләр кулланып, поэмалар формасында да язган. Аның әдәби әсәрләре, робагыйлары гарәп, фарсы әдәбиятына һәм төрки телле халыклар әдәбиятына тирән йогынты ясаган. Әбүгалисинаның хезмәтләренә кергән җөмләләрне Леонардо да Винчи да кабатлаган... Данте «Божественная комедия»сендә аны шулай ук искә алган.

Әбүгалисинаның гаиләсе хакында мәгълүматлар юк. Сәфәрле язмышта аның гаиләсе булмагандыр дип тә фаразларга мөмкин. Әмма сәләт иясе хатын-кызларга, аларның матурлыгына, гомуми камиллеккә багышлап шигырьләр иҗат иткән.

Галимне хөрмәтләү елдан-ел арта гына барган. Мәсәлән, аның исеме 1973 елда ачылган астероид – 2755 нче кече планетага бирелгән. Айдагы бер кратер да Әбүгалисина исеме белән бәйле.

2006 елның июлендә Таҗикстан хөкүмәте карары белән Памирдагы Ленин пигы Әбүгалисина пигы дип үзгәртелде. Әлеге дәүләтнең медицина университеты, бер мәйданы аның исемен йөртә, танылган шәхескә һәйкәл дә куелган. Афшанада Әбүгалисина музее эшли. Бохарадагы медицина институты шулай ук аның исемен йөртә. Аңа багышланган һәйкәлләр күп, алар Хамадан, Душәнбе, Анкара, Гахе, Рига, Кырымда урнашкан. Әбүгалисинаның кабере мәгълүм булганга күрә, аның җәсәде сакланган мавзолейда кеше өзелми. Халык олуг галим каберен зиярәт кылып, үз авыруларыннан арынырга өмет итә.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА
әзерләде.

Атнаның сәяси мизгелләре

Шомлылык мәле

Күпләр игътибар иткәндер, сәяси атна, Украинада әзерләнә торган контрһөҗүм һ.б. шундый хәтәр хәлләр белән бергә үрелеп,ниндидер шомлылык вә киеренкелек шартларында узды. Ул хәтта үзәк ТВ каналларында даими бара торган сәяси шоу программаларында да сизелде. Сәяси даирәләрдә исә «соса дипломатиясе» дә бераз активлаша төште: кемнәрдер - Пекинга, ә икенчеләре исә Мәскәүгә һәм Истанбулга юл тотты. Аурупа Берлеге (ЕС) башлыгы Урсула фон дер Ляйен һәм Франция Президенты Эммануэль Макрон, әйтик, 5-7 апрель көннәрендә Кытайга сәфәр кылды. Сөйләшүләр барышында сүз күбрәк Украина тирәсендәге вәзгыять, шулай ук ике арадагы мөнәсәбәтләр хакында барган. Аурупа эмиссарларының төп максаты, әлбәттә, Кытай лидерында теләктәшлек табу, Украина буенча аны Мәскәүгә йогынты ясарга күндерү иде. Өлешчә, алар үз максатларына ирешкән дә кебек.

Җәмәгатьчелектә шомлылык тудырган хәтәр вакыйга 2 апрельдә Санкт-Петербургта да булды. «Стрит-бар» кафесында кылынган шартлату нәтиҗәсендә Владлен Татарский атлы (чын исеме – Максим Фомин) хәрби корреспондентның һәлак булуы хәбәр ителде. Ул анда үзенең иҗат кичәсен үткәргән. Җинаятьне кылуда шик 26 яшьлек Дарья Треповага карата белдерелде һәм ул икенче көнне тоткарланды да. Шунда ук шартлауның Украина махсус хезмәтләре тарафыннан оештырылуы да мәгълүм булды. Россия Президенты В.Путин М.Фоминны (ул ук – В.Татарский), һөнәри бурычын үтәгәндә кылган батырлыгы вә кыюлыгы өчен орден белән бүләкләде. Әлбәттә инде, игътибарны ошбу фаҗигале вакыйганың сәяси ягы да җәлеп итә: җинаятьне Украина махсус хезмәтләре оештыруы һәм җинаятьченең А.Навальный (чит ил агенты дип танылды) тарафдары булуы. Күрәсең, Киевнең «террорчы дәүләт» дигән «дан» аласы һәм бәйләнчек оешмадан арынуда Мәскәүгә ярдәм дә итәсе килгән.

Узган атнаның кайбер башка вакыйгаларын да санап үтик. Э.Макрон ЕСның АКШ белән Кытай арасында Тайвань мәсьәләсендә чыккан низагында катнашуына каршы чыкты. Халыкара җинаять суды В.Путинны кулга алуга ордер бирүенә карамастан, КАР аның БРИКС саммитына килүенә әзер булуын белдергән. Быел март аенда Россиянең халыкара резервлары 3,4 % ка арткан һәм 593,879 млрд долларга җиткән. В.Путин РФ Җәмәгатьчелек палатасының президент квотасы буенча билгеләнә торган 40 кешелек яңа составын раслаган. В.Путин Россиянең бүген барлык илләр белән дә диалог өчен ачык булуы турында белдерде. Финляндия рәсми рәвештә НАТО га әгъза итеп алынды. АКШ исә НАТОның быел июльдә Вильнюста узачак саммитында Швециянең дә альянска алынуына исәп тота.

Фоат УРАЗАЙ.

Яңгырлы кичтә

Афзал ШАМОВ

(Ахыры. Башы 11-13 нче саннарда).

...Камилә кухняга яңадан кергәндә, әле таң атмаган иде. Төн узып, таңның якынлашып килүен тәрәзәдән төшкән сүрән яшькелт шәүләдән генә төшенеп була иде.

Хатын, кухняга кергәч, тәмәке исеннән кашларын җыерды, урыныннан кузгалмыйча, берничә минут хәрәкәтсез басып торды: «Төнлә торып тарткан булса кирәк», – дип уйлады.

Дәүләт, тирән-тирән сулап, җиңелчә гырылдап, бөтен идәнне тутырып, йоклап ята иде. Хатын аны уятырга кирәк тапты. Ишек янында торган хәлдә әкрен генә эндәште:

– Дәүләт... Дәүләт, дим, торырга вакыт. Бала уянганчы китегез...

Дәүләт уянды.

Хатын сүзен кабатлады:

– Торырга вакыт. Китәргә кирәк сезгә, – һәм, ишекне ябып, чыгып китте.

Уянгач, Дәүләтне гаҗәпләндергән нәрсә шул булды: яткан вакыт салып куйган өске күлмәге, оекбашы, чолгаулары юылган, яхшы итеп өтеләнгән, аның янына урындыкка кертеп куелган иде. Бераздан ул итегенең дә пычрактан чистартылганын, хәтта плащының кайчандыр өзелгән төймәсе урынына яңа төймә тагылган икәнен дә күрде.

Камилә икенче тапкыр кухняга кергәндә, Дәүләт киенеп бетергән иде инде.

– Берәр чынаяк чәй эчмисезме? – диде хатын пышылдап кына. Бу минутта алар икесе дә баланың уянуын теләми иде.

Дәүләт, эчәсе килмәгәнлеген белдереп, башын селкеде һәм Камиләгә карап алды. Төнне йокысыз үткәргән булса кирәк, күз төпләре күгәргән, яңаклары суырылган кебек. «Әллә елаган инде», – дип уйлады Дәүләт.

– Әйдәгез, трамвайга хәтле озатып куйыйм, – диде Камилә һәм, кухнядан чыгып, киенә башлады.

Алар урамга чыкканда, яктырмаган, хәрәкәт башланмаган иде әле. Урам буш. Тик анда-санда, фонарьлар яктысында гына берәм-сәрәм кешеләр күренгәли. Озакламый шәһәрнең уяначагын, шаулый-гөрли башлаячагын белдереп, күрше урамда беренче трамвайларның дөбердәве, кайбер минутларда рельсларның кызгандырып чыелдавы ишетелә. Яңгыр туктаган. Җил дә басыла төшкән. Аяк асты төнге салкын белән, җил белән бераз кибеп, коргаксып киткән кебек.

Алар берникадәр вакыт сүзсез барды. Дәүләт чемоданын тоткан килеш, тәмәкесен тарта-тарта, теләр-теләмәс атлый, юлда очраган пычракларга, җыелып яткан суларга игътибар итми, итеге белән шабырдатып барып керә, тик буш кулы белән генә Камиләгә корырак, атлап узар өчен уңайрак урыннарны күрсәтә. Камилә исә, җылы шәленә уранып, кулларын җиңнәре эченә тыгып, аның яныннан бара, узып та китми, артка да калмый.

Бераз киткәч, алар салынып ята торган бер йорт чатында туктадылар. Кайсы туктады, кайсы туктарга теләде? Әгәр алардан моны сорасагыз, икесе дә ачык итеп әйтеп бирә алмас иде. Аларга туктарга, сөйләшергә кирәк иде, чөнки әйтелмәгән, сорашылмаган һәм ачыкланмаган сүзләр күп иде.

Дәүләт чемоданын кирпеч өеме өстенә куйды, аягы астына әллә кирпеч, әллә такта кисәге туры килде, әллә болай гына, ничек сүз башлап җибәрергә белмичә, күн итеге белән бер-ике тапкыр җирне сыдырып алды. Камилә кулларын һаман шулай җиңнәре эченә тыккан килеш, бераз җыерыла төшеп, басып тора. Туңа булса кирәк. Югарыдан төшкән фонарь яктысында аның күзләре зур булып, сагышлы булып, матур булып ялтырап китә.

– Күп тартасыз икән, – диде Камилә пышылдап кына. Нигәдер аның шулай әкрен генә, пышылдап кына сөйләшәсе һәм тын гына аерылышасы килә иде. – Өченче папирос. Чыкканга күпме генә. Нигә алай еш тартасыз? Зарарлы бит.

Дәүләт җавап бирмәде, папиросын тирән итеп суырды да төпчеген бер читкә ташлады. Эчендәге төтенен сузып, әкрен генә өреп чыгарды, гәрчә аны җил алып китеп торса да, Камиләнең борынына кермәсен дигән кебек, кулы белән бер читкә куды. Тик шуннан соң гына сүз башлады:

– Мин бит синең белән чынлап сөйләшергә кайткан идем.

Шунда ук ул Камиләнең әкрен генә әйткән сүзен ишетте:

– Бу турыда кичә әйттегез бит инде, Дәүләт.

– Әйтсәм, синең бит әле бер сүз дә әйткәнең юк.

Алар тагын тынып калдылар. Югарыда җил белән талпынып торган фонарь алар өстеннән тагын бер тапкыр яктысын селкеп алды, Камиләнең сагышлы күзләре тагын ялтырап китте.

Дәүләт Камиләгә таба бераз елышты, әмма кулын сузмады.

– Әйт әле, Камилә, яшермә, син мине һаман яратасыңмы әллә?

Хатын уйлап тормады, ачык итеп җавап бирде:

– Юк, яратмыйм.

Дәүләт бу сүзгә гаҗәпләнде булса кирәк, ничектер тавышы үзгәреп китте:

– Яратмыйм?!

Камилә бераз тынып торды. Аннары пышылдап кына әйтте.

– Ярәшәсем килми: яратмыйм, әмма кызганам, – һәм шуннан соң ул аның белән «син» дип сөйләшә башлады. – Кызганам мин сине.

– Нигә?

Хатын җавап бирмәде. Дәүләт белергә теләде:

– Нигә кызганасың?.. Әйт алайса: яратмагач, сөймәгәч, нигә төн йокыңны калдырып, күлмәгемне, чолгауларымны юып куйдың? Хәтта плащыма да төймә таккансың. Әллә кайчан өзелгән иде ул. Хатыным дип аталган кешенең дә такканы юк... Нигә җавап бирмисең?.. Туңасыңмы әллә?.. Булмаса, әйт: минем кайда икәнемне белә торып, алиментка да бирмәгәнсең. Килеп кергәч, бәйләнмәдең, тавыш куптармадың. Сыеңны куйдың, хөрмәтеңне күрсәттең. Йә, яратканга түгелме бу?

– Юк, түгел, – диде Камилә. – Түгел. Кызганганга ул. Ни генә әйтсә дә, кызымның әтисе бит син. Аңа җан өргән кеше.

– Нигә мине кызганырга? – диде Дәүләт тагын бер тапкыр. Аның бу сүзне яратмаганлыгы сизелеп тора иде. Хәтта ул тавышын да бераз күтәрә төште. – Гарип-горабамы әллә мин? Шәһәрдән шәһәргә сөрелеп йөрүчеме? Аллага шөкер, кул-аягым исән. Типсәм, тимер өзәм. – Ул, үзенең исәнлеген, тазалыгын күрсәтергә теләгәндәй мактанып, кулларын як-якка җәеп җибәрде һәм аягы белән җиргә дә тибеп алды. – Кулымнан теләсә нинди эш килә. Теләсә кая барып эшкә керә алам. Документларым ал да гөл. Бер тап әсәре юк. Тагын ни кирәк?

Камилә, аның сүзен бүлеп, тыныч кына сорады:

– Ә вөжданың?.. Тап әсәре юкмы?

Дәүләт мондый сорауны көтмәгән иде, сүзсез калды. Аннары Камиләне үчекләгән сыман:

– Вөждан! Вөждан! – дип кабатлады, чөнки бу сүзне аңа төрле җирдә әйтәләр, исенә төшерәләр иде. Аның кимчелеген күрсәтүчеләрне гаҗәп дәрәҗәдә яратмый иде ул. Чәйнәп ташларга әзер иде. Кешенең миндә ни эше бар? Мин үземә үзем хуҗа, дип уйлый иде ул. – Син әле һаман шулай икәнсең. Вөждан! Кызганам!.. Аксак-туксакмыни мин? Сукырмы әллә? Синең кызгануың нигә кирәк миңа! – Ул инде тыныч сөйли алмый, кычкырып-кычкырып җибәрә, кулларын буташтыргалый иде.

Камилә, аңа якын ук килеп, тавышын мөмкин кадәр әкренәйтеп, ялынып үтенде:

– Дәүләт, Дәүләт, дим. Зинһар, ул кадәр шаулама. Кешедән яхшы түгел. Таныш-белешләрнең күрүе мөмкин. Кычкырышалар икән диярләр. Әнә, күрмисеңмени, кешеләр узып бара.

– Кешеләр, кешеләр! Гомерең буе кешедән куркып яшәдең. Төкерәм мин кешеләргә! Кешеләрне мин үзем куркытам... Кызганам, имеш! Беләсең килсә, синең шикелле куркакларны кызганырга кирәк. Мине түгел. Нигә кызганыч булыйм мин?

– Нигәме? – диде Камилә. – Менә нигә. Аңла, җанкисәгем. Гомереңне әрәм итәсең, туздырасың...

– Туздырасың?! – дип, Дәүләт тәмам ачуланып кычкырып җибәрде. – Нинди туздыру ул! Ачуым бер килмәгәе, туздырсам, үземнекен туздырам. Миндә кемнең ни эше бар! Ә син, туздырмыйча, ни кыйраттың?

Камилә бу юлы да аңа тыныч җавап бирде:

– Кыйраттым дип, әллә ни кыйраткан эш юк югын. Шулай да гомеремне әрәм уздырмаска тырышам. Эшлим, укыйм... Бала тәрбиялим.

Дәүләт аның сүзен тыңлап бетермәде, бүлде.

– Әйткәннәр иде аны, коммунистик хезмәт бригадасында дип, дөрес икән. Әйдә эшлә, укы! Барыбер ир рәхәтен күрми кәкрәерсең. Какларга эленгән тозлы каз шикелле кибеп, картаерсың. Мин юләр синең янга кайткан булам. Торсын әле, мин әйтәм, ир рәхәтен күрсен бер. Ә син?.. Кем дип беләсең син үзеңне? Имеш, якын килергә ярамый, уала. Укамыни! Әллә хатыннарга мохтаҗмы мин? Әйт, зинһар, кемгә кирәк син? Кем карый сиңа? Хәзер хатыннарның гына түгел, кызларның да поты бер тиен.

Дәүләт, бу сүзләрне әйтеп, Камиләнең хатынлык, кешелек хисләренә тукынуын сизми дә калды.

Камилә кычкырмады, чәпчемәде, кулларын җиңнәре эченнән чыгарды, турайды, башын бераз югары күтәрде, хәтта горурланып диярлек күтәрде һәм һәр сүзен аермачык итеп ашыкмый гына әйтте:

– Дәүләт иптәш, белмәсәң, белеп кит алайса: караучылар бар. Әгәр кияүгә чыгарга телим икән, бүген үк чыга алам. Ләкин теләсә кемгә, теләсә нинди иргә бервакытта да чыгачак түгелмен. Аңла, авызым бер пеште минем. Алайса, монысын да әйтим: синең кебекләр түгел, менә дигәннәр җаннарын бирергә тора. Тик техникумны бетерәсем килә. Бетерү белән үк туйлыйбыз. Ишеттеңме?.. Аннары син минем янга кайтмагансың. Ялганлыйсың! Ә сыеныр җирең, торыр урының булмаганга кайткансың. Җае чыкканчы торыйм әле дигәнсең. Юк, Дәүләт, бу ниятең барып чыкмас! Ишетәсеңме?

Дәүләт аның һәр сүзен ачык ишетә һәм фонарь яктысында ут төсле дәһшәтле янган күзләрен дә күрә иде. Күзләре яна, ә сүзләре Дәүләтнең бәгырен өтеп ала. Соңыннан ул бу минутлар турында күп уйланды, Камиләнең хатынлык, кешелек хисләрен кимсетә торган сүзләре өчен чын күңеленнән үкенде, ачынды. Әгәр ул боларны әйтмәгән булса, үзе турында андый йөрәк әрнеткеч сүзләрне ишетмәгән булыр иде.

Камиләнең әле сүзләре бетмәгән икән. Ул бары күкрәген тутырып сулу алыр өчен генә туктаган икән.

– Дәүләт, – диде ул, һаман да тынычлыгын югалтмаска, тавышын күтәрмәскә тырышып, – син мине беләсең. Минем беркайчан да ялганлаганым юк. Алайса, ишет, дөресен әйтим: син миңа ир булып түгел, ә өтелгән әтәч булып күренәсең. Йоннары йолкынган, канатлары салынган, суга төшкән әтәч! Мескен әтәч! Менә шулай... Ярар, җитте. Кызым уяна торгандыр, – диде һәм ул, кулын бирмичә, сау бул димичә, кинәт борылып, нык-нык атлап китеп барды. Шулай да берничә адым киткәч, туктады, борылды һәм Дәүләт аның ачу белән әйтелгән соңгы сүзләрен ишетте:

– Аталык хисе түгел, гади кешелек хисе дә юк синдә! Кызың яшәп торган йортта кунып, караваты янына да барып карамадың! Вөждан дигән нәрсә менә шуннан башлана.

Шуннан соң ул борылып китеп барды, әйләнеп карамады. Тротуар буйлап салынган такта басмага менде булса кирәк, бер ара аяк тавышы шактый ачык ишетелде, аннары, ераклаша барып, бөтенләй тынды.

Нишләргә белмичә аптырап, кирпеч өеменә сөялеп калган Дәүләткә әле аның аяк тавышы һаман ишетелә сыман иде. Камилә кереп киткән караңгылыкка таба ул берничә тапкыр күзләрен текәп карады. Камилә күренмәде, әмма аяк тавышы ишетелә иде. Бу аның, аяк тавышы идеме, түгелме, Дәүләт моны аерып бетерә алмады. Кем белә, бәлки, ул чыннан да Камилә аяк тавышы булгандыр, бәлки, булмагандыр, бәлки, Дәүләтнең чигә тамырлары шулай каты типкәндер дә аңа аяк тавышы булып ишетелгәндер.

«Идегәй» – дастан үрнәге

**(Ахыры.
Башы 11, 12, 13 нче саннарда.)**

Аерым галимнәр Идегәйнең күпкырлы эшчәнлегенә бүгенге фән биеклегеннән торып та шундый ук бәя бирә: «Бурсыклы буендагы бөек җиңүеннән соң Идегәй, бөтен властьны үз кулына туплап һәм үзенә ошамаган ханнарны алмаштыра-алмаштыра, титаник тырышлык салу исәбенә Алтын Урданың таркалуын янә күпмедер вакыт тоткарлап-туктатып килде, илне нығытты, ирешелгән бердәмлекне саклады» (Измайлов И. Звёздный час Идегея // Идель. –1991. – № 8–9. – С. 70; Исхаков Д., Измайлов И. Этнополитическая история татар (II – середина XVI вв.). – Казань : Школа, 2007. – 356 с.). Бүгенге фольклор, әдәбият белемендә, янә Туктамышның унай якларына һәм казанышларына күз йомып яисә әлеге ике шәхесне капма-каршы куеп, Идегәйне генә мактаган карашлар да бар.

Без, үзебез, әлеге берьяклы карашлар белән килешмибез һәм, тарихи фактларга нигезләнеп, алар белән ярашмый торган «алтын урталык» ягында торабыз. Гаепләү юлыннан китсәң, һәр ике тарихи шәхеснең дә гаепләрен табарга була. Асылда, Туктамыш та, хөкемдар булу һәм әтисе өчен үч алу максатыннан, туган иле Алтын Урда җиренә кат-кат Аксак Тимер гаскәрләре белән керә. Дәүләт башына да, нәкъ Идегәй кебек, Аксак Тимернең хәрби көченә-ярдәменә таянып, хәтта Урданың законлы ханы Тимер Мәликне үтереп менә. Монда да, димәк, шәхси дәгъва катнаша.

Әмма ошбу шәхесләр Алтын Урданың бердәмлеген, куәтен торгызуга һәм үстерүгә иксез дә күп көч салалар. Үлемнәре дә әсәрдә генә түгел, тормышта да якынча бер үк төрле. Орышсугышларда Аксак Тимердән җиңелүе һәм, социаль заказ катнашуы аркасында, Туктамыш дастанда түбәнсетелебрәк тасвирланса да, асылда, ул, Идегәй кебек үк, героик-трагик шәхес. Ике хөкемдарның тормыш юлы, үлеме шактый охшаш булуга һич тә гаҗәпләнергә кирәкми. Урта гасырларда, бигрәк тә тынгысыз, гаугалы чорларда, властька дәгъва итүче төрле нәсел яки кланнар арасында гына түгел, әй бер үк ата балаларының яки кардәшләрнең дә, бер-берсен үтерә-үтерә, хакимият башына үрмәләве, яисә шул ук юл белән көрәш мәйданыннан китүе киң таралган гадәти күренеш булган. Бу исә үз чиратында күп кан коелуга, зур корбаннарга китергән, ил-халык өстенә иксез-чиксез кайгы-хәсрәт, бәла-каза булып төшкән.

«Идегәй» эпос-дастанында да без нәкъ шул хәлне күрәбез. Әсәрнең композицион төзелеше нигезендә ятучы күпчелек парлы яки капма-каршы буыннарның үтереш-кан коешка корылуы һәм үзенчәлекле канлы чылбыр тәшкил итүе – моның кире каккысыз дәлиле.

Алтын Урданың таркалуына да, асылда (әлбәттә, илдә башланган икътисади һәм демографик кризисны да кертеп), морза-бәкләрнең нәкъ менә дәүләт тәхетенә утыру яки, киресенчә, аерылып-бүленеп чыгу өчен, бертуктаусыз тарткалашуы, халыкны үлем-сугыш яланына кертеп, үзара кан коешуга мәҗбүр итүе сәбәп булган да инде. Чөнки бу – дәүләтне тотып торучы бердәмлекнең, ил куәтенең юкка чыгуына китергән. Дастанның мәрсия-сыктау характерындагы соңгы юллары нәкъ шуны раслап тора һәм киләчәк буыннарга гыйбрәтле кисәтү булып яңгырый:

Идел-йортны дау алды,
Яу өстенә яу килде,
Идегәй әйткән көн килде.
Чыңгызның куйган хан тагы
Кан тагы булып әверелде;
Хан сарае камалды.
Кырым, Казан, Аждаркан
Башлы-башлы ил булды,
Алтын Урда таралды.

Әгәр ике бәланең зуррагын атап күрсәтик дисәк, ошбу мәшһүр дәүләтнең таркалуына, Туктамыш белән Идегәй кебек илне берләштерергә һәм үзәкләштерергә омтылучы олуг шәхесләрдән бигрәк, мөстәкыйльлеккә яки аерылып чыгарга омтылучы ваграк көчләрнең акрынлап өстенлек алуы иң зур сәбәп булган дигән нәтиҗәгә дә килергә мөмкин. Туктамыш белән Идегәй көчле шәхес икәнлекләрен үзләре дә аңлаган. Беренчесенең киселгән башы, сөңге очында өскә күтәрелгәннән соң да, һаваланып, Норадынга «баш әле дә синнән югары» дип әйткән булса, Идегәйнең соңгы сүзләре түбәндә «Киләчәк артка чигенмәсә дә, минем хөрмәт белән телгә алыначак исемем алдагы көннәргә барачак» дигән мәгънә ята. Түбәндә китерелүче әлеге хикмәтле сүзләрне башкачарак, әмма, һичшиксез, батырларча һәлак булган Идегәйнең үзен читтә калдырмыйча аңлау вариантлары да юк түгел, әлбәттә:

Алдагы көн агырга (кадер-хөрмәткә)

Без барабыз, ул килмәс.

Үз халкы белән киләчәккә барачагына, тарихта калачагына каһарманның менә шулай өмет баглавы, әлбәттә, бик урынлы һәм табигый. Ул, үләр алдыннан, үзенең эшчәнлеге, көрәше иленә, туган җиренә, халкына багышланганлыгы турында искәртә. Шуны халкым аңласын, белсен иде дигән теләк белдерә:

Илем өчен илсенеп,
Җирем өчен җирсенеп,
Халыгым өчен яхшы уем –
Күкрәк тулып, җилсенеп,
Көрәшкәнне халыгым
Аңладымы – белалмам,
Аңламаса халыгым,
Аңлатмастан үлалмам!

Дастанның җыйнама версиясендә дә, шулай ук Ситдыйк чичән-җырау вариантында да чагылыш тапкан ошбу сүзләрдә Идегәйнең яшәү мәгънәсе ачыла. Аңа карата халыкның чын, гадел бәяләмәсе дә шуннан чыгып бирелергә тиеш дигән фикер ярылып ята.

Җыеп әйткәндә, дастанда, олуг Кыпчак дәүләтенең юкка чыгуына зур аяныч һәм әрнү белдерелү белән бергә, фаҗигале нәтиҗәгә китергән канлы сугышларга карата ризасызлык идеясе дә үткәрелә. Тынычлык һәм иминлекне белдерүче сөт символының, алда әйтелгәнчә, әсәрдә кат-кат калкып чыгуы һәм канлы кылычны сөт белән юарга чакыру менә шуны раслап тора. Әлеге образлы гыйбарәнең гаҗәеп көчле, матур яңгырашлы булуына аеруча игътибар итәргә кирәк. Татар халкы тудырган бу кинаяле образ Библиядәге «перекуем мечей на орала» («кылычларны эретеп сабан ясыйк») дигән гыйбарә белән авазадаш.

Дастанның поэтикасы һәм сәнгатьчә эшләнеше турында алда өлешчә сүз булды инде. Шуларга өстәп, янә түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин. Әсәрнең теле гаять халыкчан һәм борынгы төрки-кыпчак диалектларыннан килүче сүзләргә шактый бай. Шуның өстенә поэтик сөйләм гаҗәп дәрәҗәдә образлы да. Шигъри текст урыны-урыны белән бер-бер артлы тезелеп киткән афоризмнардан, мәкаль кебек хикмәтле һәм фәлсәфи итеп әйтелгән җор гыйбарәләрдән тора. Бер мисал:

Кол сагышын би белмәс,
Би сагышын хан белмәс;
Ярлы көнен бай белмәс,
Яуның серен яу белмәс;
Ач кадерен тук белмәс,
Сырхау кадерен сау белмәс;
Ым белмәгән тел белмәс,
Тел белмәгән ил белмәс;
Зир (зәр – алтын) кадерен зирәкләр белер,
Ир кадерен ирәннәр белер;
Күп яшәгән ни белер,
Күп кыдырган (йөргән) ул белер!

Дастанда символларның роле аеруча зур. Җөмләдән, Иделйорт – Алтын Урда яки Кыпчак дәүләтен, канлы тәхет-власть өчен барган фетнә-сугышларны, тирәк төшү – ханның тәхеттән төшүен, ил агасы Бодайби – гомумиләштерелгән халык образын, 17 саны борынгы төркиләрнең мифологик ышануларыннан ук килүче иң кулай берләшмәне яки магик бербөтенне белдерә. Әсәр текстының шигырь төзелеше нигезендә күбесенчә 7-7, 8-7, 8-8 иҗекләр арасында тирбәлүче традицион такмаза-дастан үлчәме ята. Поэтик тезмәләр яки юллар язма шигырьдәге кебек икешәр-икешәр яки дүртәр-дүртәр юллык строфаларга бүленми, чөнки алар, чичән-җырауның бер тын белән ярым көйләп, ярым такмаклап уку алымына буйсынып, төрле зурлыктагы строфаларга берләшәләр. Туктаусыз үзгәреп торучы һәм 20–25 әр юлга җитүче мондый эпик строфа төре әдәбият белемендә «тирада» (французчадан, «сузу» мәгънәсендә) яки, татарчалатып әйтсәк, «сарын» дип йөртелә. Урыны-урыны белән байтак янәшә юллар, бер үк төрле сузык яки тартык авазларга башланып, ягъни үзенчәлекле юл башы «рифмалары»на корылып, аллитерацион шигырь төре тәшкил итәләр. Кыскасы, поэтикасы, шигъри-сәнгати эшләнеше ягыннан да «Идегәй» әсәре – татар фольклорындагы эпос-дастан жанрының иң гүзәл һәм классик үрнәге.

Марсель БАКИРОВ,
филология фәннәре
докторы.

Чишелмәгән серләр сандыгы

Камышлының Үзәк китапханәсендә төбәк тарихына багышланган чара узды. Кинәшмә район хакимиятенең мәдәният, спорт, туризм һәм яшьләр сәясәте комитеты рәисе Резеда Төхбәтшина һәм Үзәк район китапханәсе мөдире Римма Галимуллина җитәкчелегендә фикер алышу рәвешендә оештырылды. Чараны Өлкә төбәкчеләр оешмасы җитәкчесе, тарихи китаплар авторы Шамил Галимов алып барды.

Очрашуда катнашучылар Ш.Галимовның «Татары Самарского края. Исторические очерки» дип аталган китабында язылган, Камышлы төбәгенең таралып юкка чыккан авылларын барлады.

Камышлы районы авылларында тарих белән кызыксынган һәвәскәр тарихчылар байтак һәм аларның өстәл тартмасында тарихи мәгълүматлар тупланы ачыкланды.

Байтуган авылыннан – Әбүзәр Бәдретдинов, Иске Ярмәктән – Гатиятулла Әхмәдуллин, Мәсгут Хәбиров, Фәрид Шириязданов, Габдулла Мөхәммәткәрим, Балыклыдан – Рәшит Билалов, Чулпаннан Әсхәт Шәрәфиев кебек тарих сөючеләр авылларында булган вакыйгаларны теркәп барганнар, ә Камышлы турындагы беренче китапны язып бастырган кеше – Әсхәт Хәйров.

Район авылларының тарихы уртак һәм охшаш булса да, аерым алганда, һәркайсының язмышы катлаулы һәм үзенчәлекле. Халкы да төрле: берише бирегә чукындырудан, изүдән качып килгән, икенчеләре – йомышлы татарлар – «Сокская охранная гряда» чиген саклаучылар, өченчеләре – башкортлар яисә чуашлар... Кайбер авылларда халыклар, дине, милләте буенча икегә бүленеп, дошманлашып яшәгән чаклар да булган. Дурасов, Неклюдов, Кротков, Исаков, Дубин атлы алпавытлар ярлыларның җирләрен тартып алу нәтиҗәсендә купкан кан коюлар, баш күтәрүләр дә билгеле. Дөрес, күп мәгълүмат югалган, ә сакланганнары әле өйрәнелмәгән. Мәсәлән, татар тарихында тирән эз калдырган Манаш тархан тормышын өйрәнәсебез бар.

Очрашу барышында Бозбаш һәм Дәүләткол авыллары турында китап язарга һәм бастырып чыгарырга карар кылынды. Аның авторы – Фәһим Нуруллин, фәнни редакторы Шамил Галимов булачак.

Фәрид ШИРИЯЗДАНОВ.
«Бердәмлек».

● Торынтаеш авыл капкасы.

● Бәләбәй педагогика көллияте.

Янә Башкортстан

Март аеның соңгы атнасында Башкортстан җиренә янә бер сәяхәт ясап кайткан идек. Бу юлы да Туймазы, Стәрлебаш, Мәләвез, Бәләбәй, Стәрлетамак, Күгәрчен һәм моңа кадәр әле аяк басмаган Әлшәй районы авылларын күрдек. Элек барган чакларда Уфадагы фән һәм технологияләр университетының Стәрлетамактагы филиалына, Бәләбәйдәге (педагогика) гуманитар-техник көллияткә, атаклы Нурмөхәммәт Хөсәенов нигезләгән татар гимназиясенә керергә өлгермичә үтеп киткән идек, хәзер инде һәммәсе белән танышып, хозурланып йөрдек.

Һич яшермим, Бәләбәйдәге педагогика көллиятенең уку бинасы гаҗәеп сокландырды. 1912 елда реаль училище булып ачылган ул, ике елдан соң бинада укытучылар семинариясе эшли башлаган. Бинаның меңнәр күзеннән яшерелгән үз сере бар. Көллият белән янәшәдә генә, 100-150 адым арада мәһабәт собор тора. Аларны бер-берсенә җир асты юллары тоташтыра, ә көллият бинасы астында хәтта өч мең кешене сыйдыра алырлык подвал да бар икән. Аны Беренче бөтендөнья сугышы барышында бомбадан саклану подвалы итеп төзегәннәрдер сыман, хәвеф дигән чир Россия җәмгыяте өчен ул чакта да чит булмаган, димәк...

1990 елларда да, чиркәү әһелләренә күк капусы ачылгандай иркенлек тугач, нәфесләре тыйгысыз кузгалгандыр, алар көллият бинасын үзләренә семинария өчен бирүне таләп итеп йөргән. Әмма бина күптән мәдәни мирас объекты булып игълан ителгән бит, өстәвенә 1914 елдан бирле, ягъни 110 ел буена ул мәгърифәт учагы – укытучылар әзерләү көллияте булып эшли, шуңа нәсара әһелләре нәфесләрен тыярга мәҗбүр. Булачак мөгаллимнәрне укыту 1941-1945 елларда, бинада көнбатыштан эвакуацияләнгән ике госпиталь эшләгән елларда гына туктатылып торган.

Бер гасырдан артык гомерле көллиятнең тарихы искиткеч бай. Биредә соңыннан Советлар Союзы Герое дәрәҗәсенә ирешәчәк К.Андреев, П.Васильев, В.Тарасенко, Дан орденнарының тулы

● Без Стәрлетамак филиалының филология кафедрасы мөдире Илсур Мансуров һәм аның урынбасары Нәсимә Мөкимова белән Башкортстанның әдәби картасы янында.

кавалеры А.Кузнецов, булачак генераллар Д.Григорьев, В.Иванов һәм Рифкать Габдрахманов укып чыккан. 1922-1923 елларда шушында ук атаклы каһарман шагыйрь Фатих Кәрим белем алган. Училищеда ничәдер ай буе Герой очучыбыз Мәгубә Сыртланова да укыган, ләкин исеме документларга гына ныклап теркәлеп калмаган. Монысына мин йөз процент ышанам, чөнки ул минем әнкәмнең апасы Зифа белән бер фатирда торган. Шуңа күрә «Тозлы яра» романына да мин аны һич икеләнмичә герой итеп керттем...

Безне көллият бинасында укыту бүлеге мөдире Ләлә Таһир кызы каршы алган иде, ул Бүздәк районындагы Богады авылы кызы булып чыкты. «Сезнекеләр үз бабаларының Актаныш җирендәге Богадыдан күчеп утыруы турында беләме соң?» – дигән соравыма авызын ерып кына җавап бирә:

– Бу тирәдә Актаныш ягыннан күчеп утырган авыллар санап бетергесез бит! Безгә укырга килгән ике укучы арасыннан берсенең нәселе Актаныштан.

Ләбиб Лерон да янәшәмдә генә бит, рәхәтләнеп көлешәбез:

– Без бу юлы да үз туганнарыбыз арасына эләктек!..

Көллиятнең уку заллары, пилястрлар белән бизәлгән диварлары, әле Беренче бөтендөнья сугышына чаклы ук металл челтәрләр белән затлыландырылган баскыч култыксалары – һәммәсе

● Әлшәй районындагы Чатыртау.

● Ташкүмерчеләр ермачлап киткән җансыз таулар.

● Әлшәй районының Кыпчак Гаскәре авылы каршындагы шихан-тау.

● Без Бәләбәй педагогика көллияте музеенда.

● Бәләбәй көллияте һәм аңа җир асты юлы белән тоташкан собор.

җирендә

● Без Торынтаешның мәктәп музеенда.

музейларныкы шикелле, сокландыргыч. Мөгаллимнәр белән бергәләп безне бию һәм музыка залларына да, бик күптән нигезләнгән, бай музейларына да алып керәләр. Анда – һәммәбезгә таныш та, газиз дә булган Фатих Кәрим рәсемнәре. Кунаклар өчен булдырылган альбомда шагыйрь кызы Ләйлә Кәримова имзасы белән янәшәдә Гариф Ахунов һәм Мөхәммәт Мәһдиевнең истәлек язмалары. Алардан соң ничә еллар буена Казаннан килүче әдипләр булмаган, без дә тартынмыйча тамгаларны салдык...

Бу яктагы авылларның яртысы – Актанышныкы, дигәнгә аркаланып, вакытны сузып тормыйча, якташларыбыз ягына юл алдык. Тарихчы, тумышы белән безнең күршедәге Бакалы районыннан чыккан Таһир Кәримов язмаларыннан укып белә идем – Әлшәй районында урнашкан Торынтаеш авылын да актанышныкылар, дөресрәге, элек Бүләр волосте составында йөргән якташларыбыз килеп нигезләгән. 1760 елның 16 мартында Уфа провинциясе канцеляриясендә төзелгән килешү нигезендә элек Ногай юлының Җаексу-Мең волосте дип йөртелгән әлеге төбәккә үз заманындагы Бүләр волостеның Әнәк, Пучы, Чәчер, Мухан (хәзер Мөслим районында), Бүләр (ул Бүләр Илеш районында калган, 1980 елларда юкка чыккан), Тузганабикә (юкка чыккан), Мәткәүш-Тамак, Бикбау, Туер (Минзәлә районында), Песәй (хәзер Менделеев районында) авылларыннан элекке ясаклы татарлар старшинасы Мәксүт Морзакаев җитәкчелегендә 100 гә якын ир-ат күчеп утыра. Аларның биредә гомер итүләренә тагын берничә айдан соң 265 ел булачак бит инде!

Алар берьялгызы гына түгел, тугыз-ун чакрым арада шул ук безнең Актаныш төбәгеннән күченгән Чуракай, ә аннан биш чакрымда элекке Йәнәй волостеннан, бүгенге Әгерҗе районыннан күчеп утырган Иске Эсләк авыллары да гомер итә икән. Каршыларында гына «Шафран» санаторие. Ә табигате, аһ, искиткеч гүзәл! Без әле Чатыртау – Азнакайның гына йөзек кашы, дип юана идек, әмма бактың исә, нәкъ шундый ук исемдәге гаҗәеп ике тау Әлшәй районы төбәген дә бизи...

Стәрлетамак каласында Уфа фән һәм технологияләр университетының филиалында укучы студентлар һәм мөгаллимнәр белән очрашу да озак еллар буе күңелдән юылмастыр. Яшьләрдән башкорт, татар, чуаш төркемнәре төзеп, мөгаллимлеккә укыталар. Татар телен һәм әдәбиятын укытачак егет һәм кызларны җыю елдан-ел кыенлаша, шулай да беренче курсларына быелтыр да 18 студент җыюга ирешкәннәр. Иң гаҗәбе – берсе дә һөнәренә хыянәт итми, университетны тәмамлаучыларның 80 проценты язмышларын мәктәп белән бәйли.

Гыйлем йорты коридорына гаҗәеп зур итеп Башкортстанның әдәби картасын төзеп куйганнар. Анда С.Юлаев исемендәге бүләк лауреаты яки халык әдибе дәрәҗәсенә ирешүгә карап бернинди дә искәрмә ясап тормаганнар, һәр әдипне тумышы буенча кайсы районнан булуына карап «беркеткәннәр». Без Татарстан Язучылар берлегендә 350 гә якын иҗатчы исәпләнүгә шактый аптырыйбыз, Башкортстан картасы да гаҗәп чуар икән...

Аннары без моңа кадәр барып ирешмәгән Күгәрчен авылына юл алдык. Моракка кадәр элек тә үткәләдек бит, әмма юл мәшәкатьләре белән игътибар итмәгәнбез. Салават шәһәрен узуга ук Күмертау, Ишембай, Җиргән янынннан Моракка таба сәфәр чыккан чакта, юлның сул ягын бер дә өзелмичә хәтәр генә биек таулар челтәре озата бара. Бу юлы туктый-туктый күз салабыз, ул таулар өстендә сыңар гына да каен, имән яки нарат агачы үсеп утырмый бит. Нилектән бу? Тарих битләрен актара башлагач, яман хәл ачыла. 1950 елларда «Илне тиз арада сугыш җәрәхәтләреннән арындырырга, сәнәгатьне аякка бастырырга кирәк», дигән сылтау белән, Башкортстанның менә шушы – Салават шәһәре турысыннан башлап Күгәрчен авылына кадәр сузылган тауларын аждаһадай куәтле экскаваторлар белән актарып чыкканнар. Җир астыннан ил өчен очсызрак бәһале кызыл ташкүмерне казып чыгарганнар да, аны металлургия заводларына, ТЭС яки ТЭЦларның питоннарныкыдай туя белмәс мичләренә озатканнар. Ә асты-өскә китерелгән табигый тау урынына янганнан калган шлак төсле бернигә яраксыз һәм агулы катлам сузылып ята. Гаҗәеп таулар тезмәсенең җанын-бәгырен актарып чыгуларына җитмеш елга якын гомер узган, ә табигать һаман үз көенә сулыш ала, тернәкләнеп, яшәп китә алмый...

Күмертау каласы янында тукталып, махсус күзәтәбез. Һич гаепләү түгел: ничәмә-ничә дистә торак йортларның, янкорма биналарның түбәләре йә ватык-мотык шифер, йә кисәк-косак калай, хәтта, әнә, толь белән ябылган көе күзне тырнап ята. Аптыраудан чәчләр үрә тора. Йә Ходаем, шушы төбәкнең астын-өскә китереп, моннан миллиардлаган тонна ташкүмер, ә уйсурак җирле районнарыннан җитмеш ел дәвамында янә миллиардлаган тонна нефтьне суыртып алып киткәннәр бит! Ә нишләп аның халкы һаман булса шифер яисә толь түбәле алачыкларда гомер итеп ята? Әнә, Гарәп Әмирлекләре җирендә нефть дигән байлыкның тәүге чишмәсен 1959 елда гына таптылар, әмма ярты гасыр вакыт узуга ук ул Җир шарының җәннәт бакчасыдай иң гүзәл почмагына әверелде, анда Рәсәйнең иң эре түгел, хәтта «уртача» караклары да аерым виллалар һәм ясалма утраулар алып бетерде. Гарәпләрдә һәр бала дөньяга туура ук банкларда шул сабыйлар өчен махсус хисаплар ачыла, җир астыннан чыгарылган майдан алынган табыш һәр гарәпкә бүленә, аларда чит ил университетларына китеп уку, өйләнү, фатир алу – һәммәсе дә бушлай, ә бездә гасыр буе изелсәң-талансаң да – шифер түбәле алачык, аннан-моннан гына салынган юллар аламасы, туган телсез, тезгә чүккән тормыш... Аптыраганнан берәр башкорт милләтчесен якасыннан алып сорашасы килә: синең дә телсез яисә хокуксыз калуыңа, гасыр буе иленне талауларына татар гаепләме?..

Бу сызлану үзенең тозагыннан гомер ахырынача җибәрәчәк түгел...

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

● Торынтаеш авылы мәчете.

● Бәләбәй көллиятенең баскыч култыксаларына кадәр затлы.

Бер әсәр укыгач...

Сәхнә әсәре турында аның үзен театрда карагач сөйләшсәк дөресрәк булыр иде. Әммә пьесаны әдәби журналдан укыгач та, фикерләшү урынлыдыр, минемчә. Сүзем Илгиз Зәйниевнең «Чия тавы» дип аталган ике пәрдәле драма әсәре турында («Казан Утлары» журналы, № 2, 2023 ел).

Мин пьесаны бирелеп укыдым, яхшы проза әсәре кебек укылышлы ул. «Чия тавы»нда Илдар атлы абзыйның драмасы сурәтләнелә. Ул газиз баласы фаҗигасеннән тәмам гаҗиз булган. Пьесада детальләр үз урынында. Әйтик, Илдарның тормыш иптәше Алсу кичен, улының өйгә кайтуын белер өчен, аның урынына ятып йоклый. Яраткан улын көтә ул... Ә менә иренең үз малае белән мөгамәләсе катлаулырак... Драманың төене исә иң соңгы күренештә чишелә. Бу урында Илдарның улы – Марсель төп рольне уйный. Һәм аның атасы белән аңлашуы, театраллар телендә әйтсәк, ышандырырлык килеп чыга.

Бар хикмәт Регина һәм Илшат арасындагы мөнәсәбәтләрдә икән. Регина – Илдар белән Алсуның кызы, Илшат – район башлыгының кияве, гаиләле ир-ат. Без алар арасындагы катлаулы хәлләрне кеше сүзеннән генә аңлап беләбез. Сеңлесенең фаҗигасен Марсель сөйләп бирә:

«...Сез бит бернәрсә белмисез, бернәрсә... Алай җиңел генә булса икән ул. Алар ике ел очрашып йөрделәр... Илшат белән Регина... Гаиләсе бар шул... Синең тәти кызың, яраткач, нишләсен... Регина аборт ясатты. Илшат ясаттырды. Үзе дә сездән куркып ризалашты. Регина... Балакаем. Әллә мин аны яратмый идем, дисеңме? Без бит гел бергә идек... Әллә мин төннәрен еламый, дисеңме?.. Ул бит ярты ел буена саташып йөрде. Ул бит... Төннәр буена бала елаганын ишетәм дия иде...»

Регина белән Илшат хәтта, персонажлар исемлегендә дә юк. Трагедия кайдадыр читтә була. Тамашачы күз алдында бармый төп вакыйга. Их, сәхнә түрендә менә шул персонажлар драмасы уйналса иде! Ике пәрдәдә бирелгән вакыйгалар исә әнә шул драмага әзерләнү генә ич. Театр трагедияне үз күрә ул. Һәрхәлдә, шәхсән үзем, мәсәлән, театр тамашачысы буларак, Регина исемле кызның трагедиясен (мәхәббәтен һәм һәлакәтен) кызыксынып карар идем.

Биредә төп вакыйганы башка кеше сүзе аша гына җиткерү бүрәнә аша бүре куган кебек килеп чыга түгелме соң?

Ильяс САЛИХҖАН

ӘСӘЙ АВЫЛЫ

● Әсәй авылы мәдәният йорты.

(Ахыры. Башы 12, 13 нче саннарда).

Икенче мәхәлләдә мөәзин булып Гәрәйша Шәрәфетдинов тора. Ул бик көчле, матур тавыш белән азан укыган. Аның укыганы хәтта Карамалыга ишетелә, дип сөйләгәннәр.

Дини эшчәнлек тыелгач, мулла-мөәзиннәрнең күбесе репрессиягә эләгәчәк. Мәсәлән, Хәмзә мулланың, Әмин һәм Заһидулла мөәзиннең мал-мөлкәте тартып алынып, гаиләләре белән авылдан куылуы мәгълүм. Соңгысы, әзәрлекләүләргә карамастан, Башкортстанның Октябрьск шәһәрендә дини эшчәнлеген дәвам итә һәм шунда вафат була. Кайбер дин әһелләре репрессияләр башланганчы ук дөнья куйган була, шунлыктан каһәрле язмыш – куылу – аларның балаларына яисә туганнарына төшә. Әлбәттә, Сталин режимы оештырган репрессияләргә мулла-мөәзиннәр генә түгел, авылның элеккеге бай һәм кайбер башка хуҗалыклары да дучар була.

Билгеле булганча, Октябрь инкыйлабы җиңгәч тә, Советларның икенче съездында «Җир турында декрет» кабул ителә. Алпавытларның җирләрен шул декрет нигезендә крестьяннарга өләшәләр. Әсәй авылы кешеләренә Чалпы һәм Туйкә тирәләрендәге алпавыт җирләре бүлеп бирелә.

Ләкин бөтен тырышлыгын куеп иген иккән крестьянның ашлыгын хөкүмәт, хәрби коммунизм игълан итеп, бушлай тартып ала барган. НЭП игълан ителгәч, крестьяннарга тагын ирек бирелә. Амбарлар тиз арада ашлык белән тула. Егерменче еллар урталарында иген уңышы җыеп алу революциягә чаклы дәрәҗәгә күтәрелә. НЭП чорында Әсәй авылы кешеләренең икмәге мул була, алар аны базарда да саталар. Күпләр яңа өйләр сала, мал-туарын ишәйтә, моңарчы күрелмәгән муллыкта яши башлый.

Әммә хәлләр тагын үзгәрә. Совет хөкүмәте илне индустрияләштерү планын игълан итә. Аны тормышка ашыру өчен гаять зур чыгымнар сорала. Промышленность товарлары бик аз чыгарылганга күрә, ул чорда акчаны бары тик чит илгә икмәк сату исәбенә генә табарга мөмкин була. Шуның өчен хөкүмәт үзенең төп игътибарын авылга юнәлтә. Большевиклар, авыл халкыннан күбрәк һәм арзан хакка икмәк алу өчен иң кулай юл – күмәк хуҗалыклар (колхоз) оештыру, дигән фикергә килә. 1929 елда колхозлар оештыру хәрәкәте башлана.

Коллективлашу башлангач, 1929 елда Әсәйдә 29 хуҗалык коммунага берләшә. Коммунага Сарсаз ягыннан иң яхшы җирләр бирелә. Колхозлашу киң колач алгач, коммунага (ул инде колхоз дип йөртелә башлый) керүчеләр күбәя. Яз көне колхозда 87 хуҗалык исәпләнә. Беренче рәис итеп Садри Насрыев сайлана. Колхоз «Кичү» дип атала. Коммунага түгә җирләр авыл белән түбән тегермән арасындагы Стәрле елгасы аша кичүлек тирәсендә бүленгәнлекне күз алдында тотып, колхозга да шундый исем бирергә булганнар, ахры. Бу исемнең искелектән ваз кичүне аңлатуы да мөмкин.

1930 елның башында колхозга калган хуҗалыклар да керә. Әммә шул елның 15 мартында ВКП(б) Үзәк Комитетының «О борьбе с искривлениями партийной линии в колхозном движении» карары чыккач, яңа кергән хуҗалыклар колхоздан чыга башлыйлар. Шулай итеп, анда 300 хуҗалыктан нибары 87 се кала. Бу хәл турында Казанга хәбәр иткәч, аннан ике уполномоченный килеп төшә. 1931 елда халык яңадан гариза яза, 300 дән артык хуҗалыктан торган колхоз оеша.

Бу елларда җирне ат белән эшкәрткәннәр. Атларны, тырма-сабаннарны күмәкләштереп, колхоз милке итәләр. Беренче елда иген колхозчылардан җыеп алынган симәнә хисабына чәчелә. Эшләгән кешегә, нормага карап, көнлек азык биргәннәр. Күчмә ашханәләр эшләгән. Ул чакта 7 кырчылык бригадасы булган. Бригадирлар кеше саен кереп эшкә әйтеп йөргән.

1931 елда Әсәй авылы аша Тымытык ягына 12 «Фордзон» тракторыннан торган колонна үтә. Халык аларны күреп бик гаҗәпләнә. Арада куркып, тегермәнгә, мунча мичләренә кереп качучылар була. Трактор турында «шайтан арбасы» дигән сүзләр тарала. Әлеге тракторлар яңа оештырылган Тымытык машина-трактор станциясенә (МТС) җибәрелгән була. Шул елдан МТС, колхозлар белән килешү төзеп, төрле кыр эшләрен башкарырга керешә.

Озакламый авылга да техника кайта башлый. Колхоз башта катлаулы сугу машинасы белән ашлык суктыручы «Фордзон» тракторы сатып ала. Аннан соң, колхозның машина-трактор паркын уру һәм көлтәне үзе бәйли торган «самовязка» машиналары тулыландыра. Боларның барысы иген уңган елларда ашлык саткан акчага алына.

Мулла-мөәзиннәрне авылдан кугач, чират шомлы тынлыкка чумган мәчетләргә җитә. 1934 елда аларның манараларын кисеп төшерәләр. Өч мәчетнең биналарыннан мәктәп салалар, ә дүртенчесеннән клуб ясыйлар. Шулай итеп, авылның дини һәм милли йөзен чагылдырган истәлекләр бер селтәнүдә юкка чыгарыла.

Колхоз оешып күп тә үтми, Әсәйдә дуңгызчылык тармагы булдыралар. Татарстан игенчелек халык комиссариатының (Татнаркомзем) 1935 елның декабрендә төзелгән авыл хуҗалыгында стахановчылар нормасын үтәүчеләр исемлегендә «Кичү» колхозы дуңгыз караучысы Г.Р. Рахманов та бар. Дуңгыз үрчетә башлауны ул чор татар җитәкчеләрнең үзләрен кыю, хәтта төрле дини чикләүләрдән дә бик тиз ваз кичкән итеп күрсәтәсе килгәннән туган гамәл дип бәяләргә кирәктер.

1934-1935 елларда колхозда игеннәр әйбәт уңа, һәр хезмәт көненә колхозчылар шактый ашлык ала. Ә менә 1936 елда, киресенчә, уңыш түбән була, бик күп мал-туар үлә.

1937 елда колхоз алдагы елларга караганда да күбрәк уңыш җыя. Колхозчыларның һәр хезмәт көненә икмәк белән мулдан түлиләр. Хәтта хуҗалык саен кереп, олау-олау икмәк аударып йөриләр. Аннан соңгы елларда да тотрыклы уңыш алына. Әммә тыныч еллар санаулы гына калган була.

1941 елда Германия сугыш башлагач, Әсәйдән бик күп ир-ат (200 дән артык) фронтка китә. Аларның шактые (134 кеше) сугыш кырларында ятып кала. Сугышта һәлак булучылар исемлегендә элеккеге колхоз рәисе Садри Насриев та күрсәтелә. Аның кызы –Тәнзилә Хәбибуллина (1936 елгы) – күптомлык «Хәтер» китабын төзүчеләрнең берсе (ул берүзе аның барлык томнарын татарчага тәрҗемә итә, шул вакытта редакцияли дә), баш редактор урынбасары була.

1941-1945 елларда һәм аннан соңгы чорда колхоз рәисләре булып Асия Сабирова, Гали Шәймөхәммәтов эшли. Авыл советы рәисе вазыйфасын – Сабирҗан Гыйззәтуллин, Камәр Вәлиева, Галим Рахманов, Миннаял Садриев, Шакир Шәрипов, ә сәркатип вазыйфасын Банат Шәйхетдинова, Мәгъсум Хәкимовлар башкара.

1953-1979 елларда колхоз белән Сабах Гәрәй улы Хәсәншин җитәкчелек итә. Илленче еллардагы кебек, алтмышынчы елларның икенче яртысында колхозларны эреләндерү башлана. «Кичү» колхозын 1968 елда күршедәге Чапаев исемендәге колхозга кушалар. Берләштерелгән колхозга Чапаев исеме бирелә. Колхоз рәисе итеп С.Г. Хәсәншин сайлана.

1979 елдан колхозга Әсәй авылында туып-үскән Илсөяр Закиров җитәкчелек итә. Озакламый (1981 ел) «Чапаев» колхозы «Әсәй» совхозына үзгәртелә. Дистәдән артык ел җитәкче булып эшләү чорында И.Закиров авылның социаль-икътисади базасын ныгытуга зур көч куя. Авыл юлларына асфальт түшәлә, йортларга газ керә.

1994 елның чалт аяз 23 сентябре көне исә бик күпләрнең хәтерендә гомерлеккә сакланыр. Алты дистә ел элек дүрт мәчетен югалткан авыл, ниһаять, берсен кайтарды. Һәм, бу кайтару-кайту озакка, мәңгелеккә булсын, дигән уй-теләк күпләрнең күңелендә булгандыр ул көнне.

Таһир КӘРИМОВ,
Ш.Мәрҗани ис.тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре.

Талауның тагын бер ысулы

Хәзерге вакытта, мошенникларның хиндиләре генә юк. Башкаладан килгәннәрә бигрәк комсызлар икән. Урындыкка утырган көйгә массаж ясый торган кресло-накидка белән сату итүчеләрнең белдерүләре буенча, әйберләрен сатып алмасалар да, кан басымын, ничә чакрым җәяү йөргәнне үлчи торган сәгать бүләк итеп бирелүе гарантияләнә дигән сүзләргә алданып, без дә барып карадык. 1-2 ел элегрәк тә андый алдашу уенында катнашкан бар иде. Шулхәтле көчле кыстауларына бирешмичә, массажерларын сатып алмасак та, кечкенә генә булса да, бүләкләрен биргәннәр иде.

Болары да шул элеккеләре кебек, килеп керүгә якты чырай белән каршы алып, теркәлү үткәреп, һәрбер кешенең күкрәгенә исеме язылган кәгазь ябыштырып чыктылар. Сатуга куелган әйберләрнең сәламәтлеккә файдасы турында чыгышны аркага массаж ясый торган урындыкка утырып тыңладык. Шул массажерның ярдәме белән авыруларыннан котылуы турында бер ир кеше экраннан сөйләп торды.

Язылган номерлар буенча бүләкләрне уйната башладылар. Безнең алда утырган ир белән хатын (болары үз кешеләре кебек күренде) иң беренче «бәхетлеләр» булып, көчле алкышлар белән аларны «бүләкләү» өстәлгә чакырдылар. Инде чират безгә дә (хатыным белән мине улыбыз алып барган иде) килеп җитте. Безне дә бүләкләү өстәленә чакырып утырттылар. Безгә биреләсе 5-6 төрле бүләкне алып килеп куйдылар. «Менә бу бүләкләр барысы сезнеке», – ди. Массажер-кресло, аякка, кулларга массаж ясый торган җайланма, үзенчәлекле мендәр, одеяло буласы. Шул әйберләрнең массаж-креслосына гына 169 мең түлисе, калганнары «бүләк» дип санала икән. Акчасын 3 елга рассрочка белән әз-әзләп түләргә дә мөмкин. Безнең өйдә массаж ясый торган карават бар, йоклар алдыннан һәр көнне мин массаж сеансы алам. Безне юмалый башладылар. «Нәрсә инде сез, әйдә бир паспортыңны, хәзер рәсмиләштереп куябыз» – ди. Хатыным да «әйдә алабызмы әллә?» дия башлады. Хәзер инде чынлап та, әйберләрен алмасаң уңайсызланып, үзеңне гаепле кеше кебек сизә башлыйсың. Массажерның бәясен төшерә башлады, 150 меңгә, аннары 130 меңгә калдырды. Әйберләрен алырга безне күндерә алмагач, үпкәләгән кебек калды. Бездән соң чакырылган ир белән хатын, кыстауларга түзә алмыйчадыр, ни бәягәдер сатып алырга ризалык бирде.

Алар үзләренең белдерүләрендә килгән кешеләргә бүләк итеп сәгать бирелү гарантияләп әйтелгән иде. Бер ир-ат белән ике хатын, вәгъдә иткән бүләгегез кайда, нишләп бирмисез дип боларга бәйләнә башладылар. Полиция чакырырга кирәк дигән сүзләр дә ишетелде.

Интернет-кибеттә болардыкы кебек массажерларның ниндие генә юк. Бәяләре 2 меңнән башланып 20 меңгә кадәр. Шул сәбәпле бу әйберләрне алган кешеләрне кызганып утырам әле.

Рәфкать ИБРАҺИМ,
Казан

«Моң» төшенчәсен, аның теориясен аңлаткан махсус хезмәтләр белән танышлыгым юк. Ә менә моң яралу чыганакларын сәнгатьчә бәяләгән әсәр укыганым бар. Айдар Хәлимнең «Казан утлары» журналының 2022 ел беренче санында басылган «Моң кайтты» повесте да безне милли моң турында уйланырга мәҗбүр иткән иде.

Татар моңы

(Айдар Хәлимнең «Моң кайтты» повесте турында)



Әсәрнең сюжеты катлаулы түгел. Үзбәкстан якларыннан Татарстан җирендәге бер авылга Сабирҗан исемле ир кайтып төшә. Ул – ата-бабасы чыккан бу авылдан читтә үскән өченче буын. Туган якларын бик сагынып кайткан сыман булса да, тора-бара ул үзендә моңдый хиснең юкка чыгуын тоя. Киредән янә үзбәк якларына китү нияте дә кабынып ала. Шушы авыл буламы инде аның Ватаны? Ата-бабалары сагынып сөйләгән, аларның буынын ныгыткан елгалар, сулар, чишмәләр корып беткән. Тәмам тешсез әбине хәтерләткән урамнарда аксак-туксак карт-коры гына. Байтаклары лычма исерек. Бәлки, шушы күренешләр геройның күңелен кайтаргандыр?

Юк, барыбер тарта туган авыл, нәрсәсе беләндер җибәрмичә тота. Герой әнә шундый каршылыклы уйлар халәтендә кала. Аның бер генә михнәт кичерәсе – күзен йомасы һәм газиз моңнарны тыңлыйсы килә башлый. Гүя шушы моңнарда серле нокта, мәңге үлемсез тормыш ноктасы яшеренгән. Ир-егет Зөһрә Сәхәбиева һәм Хәйдәр Бигичевның җырларына кереп чума. Сабирҗан аларның җырларын әле Үзбәкстанда ук ишетеп, тыңлап яшәгән була. Тыңлый торгач, Сабирҗан бер нәрсәгә инана: татар өчен, бары тик татар өчен генә билгеле булган аһәң-моңнар, татарның моң тарихы ул – башта теләмичә, карыша-карыша изелү, аннан каешланып изелергә өйрәнү тарихы икән ләбаса. Менә шуңа моңлы икән ул татар. Сабирҗан да авыр хезмәтләрдә изелгән шушы татарның бер баласы бит. Татардагы моңны бар итү өчен ничәмә-ничә буын Сабирҗаннар рудникларда агулы уран бушаткан, комлыклардан сары арыклар сузган, зәмһәрир салкыннарда лашман тарткан, бозлы яңгырларда сабан сөргән!

«Татар вакыты» әсәрендәге Мотаһар сыман, бу образ да әнә шулай изелгән, әмма рухы сынып, иманы тәмам җуелып бетмәгән халык символы буларак бирелә. Дөрес, Сабирҗанны, әдәби герой буларак, «татар халкының типик вәкиле» дип гомумиләштерү дөрес булмас. Авылны ныклап белмәгән, аның «кичке вичырлары»нда биеп тә үсмәгән, Сабантуйларында бәйге дә чапмаган, ике югары белемле, әмма бер генә сыйныфны да татарча укымаган, ә шулай да татар моңын нык үз иткән, җырчылары белән кызыксынган, Сократка тиң фәлсәфи тирән фикер йөртә алган «чит» татарлар хәзер бик сирәктер ул. Геройлар, табигый ки, язучы уйланмасына буйсынып хәрәкәт итә. Кытай җирендә туып үскән, шунда шәхес булып формалашкан, соңрак Америкага барып төпләнгән, аннан бабалары нигезен сагынып Татарстанга килгән Иркен Сәлахинең дә («Хунвейбин» романының үзәк герое), үзбәк якларында тәрбияләнгән Сабирҗанның да язмышлары, эш-гамәлләре, уй-фикерләре – ул авторның аң чагылышы, аңының төпкелләреннән чыккан фәлсәфәсе. Автор бүгенге татарны менә шулай белемле, фикерле, милли җанлы итеп күрергә тели.

Сабирҗанның Зөһрә һәм Хәйдәр башкарган җырлардан алган тәэсиренә бәйләнештә әсәрдә берочтан әлеге җырчыларның язмышы сурәтләнә. Автор сәнгатьчә ниятенә ярашлы күләмдә бу ике легендар шәхескә кагылышлы материал, фактлар туплаган. Аларның иң әһәмиятлеләре ипләп кенә сюжетка кертелгән. Автор кыска, тыйнак, әмма тыгыз мәгънәле итеп ике җырчының бәхетле дә, фаҗигале дә гаилә тормышын бәян итә. Мәгълүматлар, фактлар Сабирҗанның уй-тәэсирләре, кичерешләре, фәлсәфәсе белән сугарылган. «Әлеге җырчыларны тыңлаганда Сабирҗанга Җир һәм тереклек яңадан тетрәнгәндәй һәм яңадан яратылгандай» була. Бер үк вакытта геройныкы да, авторның лирик чигенешләре дә булып яңгыраган илаһи-галәми фәлсәфә бик тирән. Әсәрдәге һәр элемент – заман проблемалары булсынмы, яисә татар кичергән тарихи юл, геройларың язмышы булсынмы, шулар рәтендә фәлсәфилек тә бер фокуска килеп тоташа. Ул да булса – уран төше. Булачак ике даһи җырчы ураннан яратылган җирдә икесе ике төбәктә дөньяга аваз сала. «Икесе дә турпагы да моңнан әвәләнгән авылларда, моң эчендә үзләнеп, калебләренә иман сеңдереп үсә». Төз буйлы, гладиатор кебек такта күкрәкле, беләк-балтырлары тимер кебек нык Хәйдәр күкрәгендәге уран атомын «шартлатырга» урын эзли. Уран көче белән егет комбайн штурвалына күтәрелә, иген игә. Штанга һәм гер күтәрү буенча ярышларда катнаша. Германиядә танкист булып хезмәт итә. Бер-берсен белмәгән, күрмәгән ике талантны Аллаһ Тәгалә үзе кавыштыра. Ике бөек җырчы бер гаилә була. Алар киң диапазонлы татар халык җырларыннан үлемсез яңа гөлбакча барлыкка китерә. Хәйдәр Бигичев татарның милли җыр сәнгатендә тоташ бер буын җырчылар башкара алмаган бурычны үти. Ул Рәсәй опера сәнгатенең алтын хәзинәсенә зур өлеш кертә. Автор аның талантының хакимият тарафыннан тиешенчә бәяләнмәвен, соңгы елларда башына бик күп сынаулар төшүен, «уран»ының атомсыз калуын әрнү, ачыну, сагыш хисләре белән тасвирлый. Сагышларның, үкенечләрнең иң әрнүлесе – Татарстан халык артистының «яшь капитализм котырып чәчкә аткан үрнәк Татарстанның дәүләт хастаханәләрендә» биш сәгать буе ярдәм көтеп, аны алалмыйча газапланып җан бирүе. Җырларын тыңлап, шушы вакыйгаларны йөрәгеннән үткәреп, уйланып яткан Сабирҗанга кинәттән моңарчы үзе җырлый алмыйча интеккән моң кайта.

Автор фикерләрен киң дөньяви масштабта яңгырата. Әйе, «Җир йөзендә һәркемнең үз урамы, үз матдәсе, үз ураны, үз молекуласындагы атомы, атомның җимергеч һәм яшәрткеч көче бар. Изгелеге һәм явызлыгы. Кайсын куллану синең эшең. Изгелеген куллансаң, тормыш изгелеккә, явызлыгын куллансаң, явызлыкка тартыр. Аларның барысының да үзәген ятктыртып, чалкан туган ай – иман үзе ятадыр». «Дөньяның йөзләгән кавемнәреннән бары тик биш-алты кавемгә генә атом хуҗасы хокукын бирү – уранны урлау, моңны урлауга тиң җинаять. Моны халыкара хөкемнәр хәл итәргә бурычлы. Табигатьтән тигез, ирекле булган атом төше белән ирексезләрне, түбәнсетелгәннәрне куркытып яшәү тигезлек арбасының күчәрен сындыра». Бик тә мөһим яңгырашлы фикерләр.

Безнең карашка, «Моң кайтты» повесте Айдар Хәлим иҗатына хас тема-проблематик һәм идея эстетик эзләнүләренең киңлеген, милли фәлсәфәсенең тирәнлеген тагын бер кат раслаучы иҗат җимеше булып тора.

Лилия ГАЛИТЗУЛЛИНА.

ОСТАЗ ГАЛИМ

Әдәбият галиме Ибраһим ага Нуруллин 1923 елның 18 апрелендә Мөләкәс районының Парау авылында укытучы гаиләсендә туа. Ул 1938 елда Казанга килә һәм мех техникумында укый башлый. Бөек Ватан сугышы башлангач, 1941 елның октябрь аенда үз теләге белән ил азатлыгын якларга китә. Фронтта каты яралана һәм туган авылына кайтып мәктәптә балалар укыта, соңрак Казан университетының татар филологиясе кафедрасында эшли башлый. Ибраһим ага 1953 елны Тукайның идея-эстетик карашларын тикшерүгә багышланган гыйльми хезмәте нигезендә кандидатлык диссертациясен яклый. Шул вакыттан алып, И.Нуруллин гади ассистенттан профессор дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә.

● Кызылармеец И.Нуруллин. 1942 ел.

И.Нуруллин әдәбиятка хикәяче-прозаик буларак килеп керә. Аның «Ана тойгылары», «Рәхмәтулла абзый», «Кунакта» кебек беренче иҗат җимешләре һ.б. әсәрләре укучылар тарафыннан яратып кабул ителә. Соңрак аны Г.Тукай иҗаты кызыксындыра, шулай ук ул Ф.Әмирхан, Ш.Камал иҗатларына багышланган мәкаләләре белән дә язучы-публицист буларак таныла башлый.

Галим татар әдәбиятында иҗат алымнары һәм әдәби юнәлешләр, әдәбият тарихы турында монографияләр яза. Шул ук вакытта журналист эшчәнлеген дә онытмый: газета-журналларда, көндәлек матбугатта күренекле язучыларның иҗатына караган тәнкыйди мәкаләләре, рецензияләре даими басылып тора. Шушы эшчәнлегенең нәтиҗәсе буларак, аның 1983 елда әдәби тәнкыйть мәкаләләре тупланган «Тормыш һәм сәнгать чынлыгы» исемле яңа җыентыгы чыга. Ибраһим ага балалар өчен әдәби әсәрләр язуны да читкә куймый. Киңкырлы эшчәнлеге өчен күренекле әдип 1992 елда Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге әдәби бүләгенә, ә 1982 елда «Габдулла Тукай» исемле китабы өчен Татарстан АССРның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясенә лаек була.

Ибраһим ага, берьюлы әдәби иҗатка һәм фәнгә бирелгән кеше буларак, үзенең эшчәнлегендә иң отышлы юл таба – ул фәнни-популяр әсәрләр иҗат итә башлый. Аның публицистик эшчәнлеген зур өч төркемгә бүлеп була: беренчесе – әдәбият өлкәсенә караган мәкаләләр, икенчесе – татар әдәбиятында күренекле язучыларның иҗатын өйрәнүгә багышланган хезмәтләр һәм өченчесе – бүгенге көн өчен актуаль проблемаларны яктыртуга багышланган күпсанлы язмалар.

Әдәби мәкаләләренә тукталсак, И.Нуруллин, сүз сәнгатен өйрәнүдә зур белгеч буларак, укучы игътибарына лаеклы мәкаләләр яза. Аның беренчесе «Тормыш һәм сәнгать чынлыгы» исемле китабында һәм «Казан утлары» журналында 1965 елда басыла. Ибраһим ага «Иҗат методыбыз турында уйланулар» исемле мәкаләсен «Бу өлкә әле җитди планда өйрәнелмәде», дигән фикер белән башлап җибәрә. Язмасында ул социалистик реализмны «уйлап чыгарылган» диючеләргә каршы чыга, совет әдәбияты белеменең социалистик реализм теориясен үстерүдәге әһәмиятен таный.

«Киләчәккә карап» мәкаләсендә автор әдәби тәнкыйть белән әдәбият тарихы арасындагы чик бозылды, ди. Тәнкыйтьне әдәбият теориясе белән тәңгәл кую очраклары да булып торуы өчен борчыла. «Бүгенге тәнкыйтебез җитди генә кимчелекләрдән дә азат түгел. Шулардан иң зурысы — әсәрне язучы иҗатын яисә әдәби процессны әдәбиятның үз кабыгы эчендә генә тикшерү булса кирәк. Рецензия икән, күпчелек очракта әсәрнең сюжетын сөйлибез, кайбер персонажларына характеристика биргәндәй итәбез, композиция һәм тел-стиль кимчелекләрен өстән-өстән генә саныйбыз да, бетте-китте», – дип яза. Ә тәнкыйть әдәби хәрәкәттә үзенең лаеклы урынын алсын, тормыш куйган таләпләргә җавап бирсен өчен, тәнкыйть арбасының сөйрәлебрәк баруына китергән объектив һәм субъектив сәбәпләрне бетерү турында уйланырга кирәклегенә дә басым ясый. «Атны камчылау белән генә, белмим, эш чыгар микән. Солы белән ку, ди бит халык», – дип төгәлли публицист үзенең фикерен.

Язучылар иҗатын яктырткан мәкаләләргә тукталсак, тәнкыйтьче И.Нуруллин Ш.Камал иҗатына зур күзәтүләр ясый. Публицистның 1963 елда басылып чыккан «Ш.Камал иҗаты: мәкаләләр» җыентыгы язучының тормыш юлын, аның әсәрләрен, аларда күтәрелгән проблемаларны яктыртуга багышланган. Хикәяләренең уңай һәм тискәре якларын күрсәтү белән, ул алардан укучыга уйланырга урын калдырган билгеле бер нәтиҗәләр дә чыгара.

«Шәриф Камалның совет чоры драматургиясе» исемле мәкаләсен галим Ш.Камалның «Ут» драмасы белән башлап җибәрә. Әлеге әсәргә карата күп кенә уңай фикерләргә, критикларның тирән эчтәлекле мәкаләләренә карамыйча, аны Ш.Камалның искергән әсәрләре исәбенә кертеп карый башлыйлар һәм ул сәхнәдә куелудан туктый. «Янәсе, пьесада дошман элементлар, корткычлар һәм шулар тозагына эләккән җаваплы работник алгы планга куеп сурәтләнгән». И.Нуруллин исә, драмада куелган һәм хәл ителгән үзәк проблеманы тотып ала алмау аркасында чыга торган аңлашылмаучанлыктан башка берни дә юк, дип билгели һәм әсәрнең шушы ягын тикшерүгә алына һәм әсәрдә бүгенге көн проблемалары күтәрелгән өчен генә дә, һичшиксез, сәхнәгә кире кайтарылырга тиешлеген искәртә.

Галим Тукай иҗатын төрле яклап ача. И.Нуруллинның язучы буларак эшчәнлеге Тукайдан башлана, дисәк тә ялгыш булмас, безнеңчә. «Тукай – минем бөтен тормышым», – дип яза ул.

И.Нуруллин Тукайга багышланган күпсанлы мәкаләләрендә автор «Тукай матурлыкны нидә күргән?» дигән сорауга җавап эзли. Нуруллин 1948 елда «Тукайның әдәби пародияләре» дигән беренче мәкаләсен яза. Ул Тукайның пародик әсәрләрен мисал итеп китерә, аларның, үзенчәлеген ачыклап, эчтәлекләре һәм формалары ягыннан төрле булуын ассызыклый.

Публицист Тукайның халык мәнфәгатьләре белән яшәвен иң югары ноктага күтәрә. «Тукай әдәбиятта халыкчанлык турында» исемле мәкаләсендә нәкъ шушы сорауга туктала һәм бөек шагыйребез – Г.Тукайның халык турындагы идеяләре бүгенге көндә дә үзләренең әһәмиятләрен югалтмаганнар, дигән зур нәтиҗә чыгара һәм һәрбер язучының халык фикерен күз уңында тотып яшәргә тиешлеген дә искәртә.

Гомеренең соңгы ун елында И.Нуруллин Г.Исхакый иҗатын кайтаруга зур өлеш кертә. Вакытлы матбугатта, газета-журнал битләрендә аның Исхакый мирасын татар халкына кайтаруга багышланган күп кенә мәкаләләре басыла. 1988 елны исә И.Нуруллинның «Вечерняя Казань» газетасында «Возвращение Гаяза Исхаки» язмасы дөнья күрә, 1989 елны «Дружба народов» журналында аның «Во имя научной объективности» мәкаләсе басыла. Монда ул Г.Исхакыйның тәнкыйди реализмга нигез салучы булуына да басым ясый һәм укучы алдына түбәндәге сорауны куя: «XX гасыр башы татар әдәбиятын нигез салучысыз өйрәнү һәм укыту нәрсәне аңлата?!» «Исхакый мирасын югалту – халык тарихыннан, аның яшәү рәвешеннән, гореф-гадәтләреннән, гасырлар буе камилләшкән әхлакый кыйммәтләрдән мәхрүм булып яшәү», дип белдерә.

Әдәбият өлкәсендә кайнаганнар 1991 елда «Зиндан» исемле зур китап басылып чыкканы хакында хәбәрдар. Г.Исхакыйның әсәрләре тупланган әлеге китапка да Нуруллин кереш мәкалә яза: «Г.Исхакый иҗаты, бигрәк тә аның эмиграциядәге елларына караган өлеше, әле җитди өйрәнүне таләп итә. Әмма бу юнәлештә моңарчы башкарылган эшләр дә Гаяз Исхакый XX йөз башы татар мәдәниятендә үзәк фигура һәм бу чор татар әдәбиятына нигез салучыларның иң күренеклесе иде, дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә».

И.Нуруллин «Кайту» мәкаләсендә дә алдагы мәкаләләрендәге кебек үк Г.Исхакыйның чын татар язучысы исемен йөртергә хаклы икәнлеге турында яза һәм үз фикерен мондый сүзләр белән дәлилли: «Г.Исхакыйның чит илдә ничек яшәве, ниләр эшләве зур әһәмияткә ия түгел. Аңа карап кына әдәби мирасының идея-художество дәрәҗәсе төшми дә, күтәрелми дә. Ә бу мирастан тыш XX йөз башы татар әдәбиятының язма тарихы, беренче бүлеге умырып алынган китапны хәтерләтеп, чын мәгънәсендә фән була алмый», – ди. Актив, үзенең эше белән янып торган публицист буларак, И.Нуруллин хәтта Г.Исхакыйның Максим Горький белән язышкан хатларын табып алып, аларны «Татарстан» журналында бастырып чыгара.

Фатих Әмирханны өйрәнүебез әлегә җитәрлек түгел, дип искәрткән галимнең 1988 елда «Фатих Әмирхан» исемле китабы дөнья күрә. Тулы бер хезмәт буларак бәяләнергә лаек булган әлеге китап 8 бүлектән тора. Журналист күзлегеннән караганда, аны очерк, дип атасак дөресрәк булыр, чөнки монда әдипнең тормыш этаплары публицистик характерда бәян ителә. Төрлечә гаҗәеп матур исемләнгән әлеге бүлекләрдә язучының әсәрләренә тукталганда, И.Нуруллин персонажларда Ф.Әмирхан һәрвакыт үзен тасвирлаган, дип яза.

И.Нуруллин «Әдипнең ике пьесасы» исемле мәкаләсендә аның драматургия эшчәнлегенә анализ ясый. «Яшьләр» һәм «Тигезсезләр» драмаларына бәя бирә, геройларына туктала, автор күтәргән проблемаларны анализлый. Галим Ф.Әмирхан әсәрләрен атап кына китми, аларга карата бәяләмәләр дә язып үтә, әсәрләрдә күтәрелгән проблемаларның бүген дә актуаль икәнлеген исбатларга тырыша: мәсәлән, «Яшьләр»дә «аталар һәм балалар» проблемасы, хатын-кыз хокуксызлыгы темаларының асылын ача. «Тигезсезләр» пьесасында исә, кеше бәхете, кеше язмышы мәсьәләсе куелганлыгын әйтә. «Әгәр бу мәсьәлә мораль-психологик планда гына хәл ителгән булса да, әсәрне себереп түгәргә безнең хакыбыз юк. Кеше

күңеле, кеше йөрәге һәм кеше җаны сәнгатьтә үзенең чагылышын табарга хаклы», дигән фикерен бастыра һәм һәрбер кешенең бәхетле булырга хакы бар, дип бу турыда укучының исенә төшерә.

И.Нуруллинның чор проблемаларына кагылышлы мәкаләләрен игътибар үзәгеннән төшермәскә кирәк. Аларда көн сорауларын хәл итәрлек фикерләр тирән һәм кискен җиткерелә. «Тормышчан сюжетны яклап» дип аталган мәкаләсендә галим, тәнкыйтьче күп кенә пьесаларда вакыйгаһың ничек бетәсе алдан ук билгеле булуын искә төшереп, моның яхшымы, начармы икәнлегә хакында уйлана. Ул мисалга «Отелло», «Галиябану»ларны китереп, ничә еллар буе уйналса да, тамашачының барыбер аларны бик теләп карауларын билгеләп уза. «Әнә шул килеш бер үк пьесаны яки фильмны ике, өч, хәтта унар тапкыр караган кешеләр турында нәрсә әйтәбез инде? Ни өчен алар кат-кат йөриләр?»

И.Нуруллин үзенең уйларын, фикерләрен гаҗәеп матур чагыштырулар, метафоралар ярдәмендә җиткерә белүе белән дә үзенчәлекле. Спектакль карарга килүне кояш чыгуын кызыксынып күзәтү белән чагыштыра. Нинди талан остасы булырга кирәк бит шушындый урынлы мисаллар китереп эш итәр өчен! «Кояшның чыгасын һәм кайсы яктан чыгасын белеп торсак та, таң атуны мавыгып күзәтәбез, чөнки ул – бик гүзәл күренеш, аның күп бизәге, төсмере бар, күңелдә матур хисләр кузгата», – ди. «Сәнгать әсәре белән дә шул ук хәл. Ул бер рәвештә генә булмый. Аның хисапсыз күп бизәге, төсмере бар. Караган саен яңа якларын, яңа төсмерләрен табасың».

● Әдипкә Г.Тукай премиясен тапшырган мизгел. 1982 ел.

Күп кенә мәкаләләрдә автор теле шундый үткен, аның чагыштырулары хәтергә сеңеп кала. Мәсәлән, «Аяк белән йөрүгә ни җитә» мәкаләсендә ул тышкы охшашлыкка нигезләнгән хикәяләү төре турында сүз кузгата һәм әсәр инде искерде, дип аңа новаторларча карауга каршы чыга һәм моның белән килешмәвен белдерә. «Адәм баласы, турайганнан бирле, аяк белән йөри. Инде килеп, берәү: «Алай йөрү инде искерде һәм туйдыры, кул белән йөрергә вакыт», дип чыкса, белмим, кем генә моңа җитди карар һәм бу кешене чын новатор итеп санар икән. Дөрес, кул белән йөрү дә кайвакыт үзен аклый. Әйтик, циркта яисә спорт залында...».

Үзеңнең фикерләреңне укучы аңларлык итеп төгәл һәм гади генә мисал ярдәмендә җиткерә белү, безнеңчә, оста публицист ия булырга тиешле сыйфатларның берсе дер ул, чөнки бүгенге көндә газета-журнал укучыларын гади генә теория белән җәлеп итүе авыррак шул: тиз, мәгълүмат күп булган заманда яшибез. Әйтергә теләгән фикереңне укучы шундук тотып алырлык гади, аңлаешлы «публицист теле»нә ия булырга кирәк.

Заман таләбенә туры килгән проблема «Тамчыкай» исемле мәкаләсендә яктыртыла. Оста телле публицист – Нуруллин, һәр әсәр, һәр китап дөрес язылган булырга тиеш, чөнки бары тик китап кына тормыш фактларын бирә ала, ди. Китапның мавыктыргыч булырга тиешлегенә басым ясый, эч пошырса, укучы аны укымаячак, ди. Автор фән эшлекләрен дә китап язуга җигәргә кирәк, ди: «Безнең китаплар балаларда белемгә зәвык һәм кызыксыну үстерергә, мәктәптәге фәннәрне үзләштерергә җиңеләйтергә, совет кешеләренең, хезмәт батырлыкларының, совет иле галимнәренең бөек казанышлары белән таныштырырга тиеш». Кызганыч, әмма бу фикер белән килешми мөмкин түгел. Уйлап карасак, балалар өчен язылган китапларның күбесе И.Нуруллин санап киткән таләпләргә җавап бирми, дип әйтерлек. Укучылар китап укымый диләр, ә бәлки, әлеге китапларны укучыны кызыксындырырлык итеп язарга кирәктер?!

Сәнгать өлкәсенә караган иҗат җимеше дә бар. «Уйналмаган скрипка моңы», дип атала. Укучыны зур контраст ярдәмендә уйландырырга мәҗбүр итә: «Бер якта – скрипканың ни икәнен дә белмәгән, яисә бу назлы уен коралына тап булып та аңа орынырга да хакы булмаган авыл малайлары. Икенче якта – шундый ук яшьләр һәм алар үзләре үк скрипка өчен махсус пьесалар язачаклар, симфонияләр иҗат итәчәкләр», дигән ике зур төркемне аерып чыгара. Мәкаләдә җиткерелгән фикернең төбенә төшенсәк, кечкенә хикәядә зур фикер әйтелгәнлеген, һәм ул фикернең сәнгать өлкәсендә бүген дә аеруча актуаль яңгыраганлыгын тоябыз.

Авторны борчыган тагын бер мәсьәлә: әдәбият тарихын өйрәнүнең эше канәгатьләндерерлек түгеллеге. «Фәнни эшнең торышын монографияләр билгели, ә алар бездә бармак белән генә санарлык бит», – дип яза Ибраһим ага. Ул боларның барасын да фәнни-тикшеренү эшләренең йомшаклыгы белән аңлата. Чыннан да, без дә игътибар үзегенә алсак иде әлеге мәсьәләне. Әдәбиятның киләчәге безнең кулыбызда.

И.Нуруллинның киңкырлы эшчәнлеген күзәткәннән соң, чыннан да, аның зур талант иясе икәнлегенә инанабыз. Ибраһим аганың эшчәнлеге бәяләп бетергесез: язучы, тәнкыйтьчедән алып җор телле, оста публицист та икән бит ул!

Мәкаләләрендә теге яки бу язучы тормышын анализлап кына калмый, аларның әдәбиятка килү юлларын да яза, шулай ук әдәби әсәрләрне дә анализлап кына калмый, ә аларда күтәрелгән проблемаларны бүгенге заман ноктасыннан чыгып карый, аларга бүгенге көн таләбеннән якын килә.

Ибраһим аганың киң белемле, төрле өлкәдә чын белгеч булуы сизелеп тора. Ул мәкаләләрендә укучыны ялыктыра торган теория, дәлилләүләр белән генә мавыкмый, ә, киресенчә, укучы хәтеренә сеңеп, аның хәтерендә уелып кала торган мисаллар, чагыштырулар, метафоралар кулланып язуны хуп күрә. Үткен, бай телле публицист, әдәбият галиме Ибраһим Нуруллинга, безгә актуальлеген югалтмый торган һәм, әлбәттә, беркайчан да искерми торган фикерләр әйтеп калдыра алганлыгы өчен рәхмәтлебез.

Айназ ҖИҺАНШИНА,
КФУның Г.Тукай исемендәге милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе студенты.

Айга карама
кырын

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

15 апрель (шимбә). ***Рамазан аеның 24 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында,4.39 сәгатьтә калка,12.53 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 14.07 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Кан басымын төшерү

1 аш кашыгы кипкән гөлҗимеш җимешен 2 стакан кайнар суга салып, сүрән утта 10 минут пешерәләр, суытып, сөзәләр, 1 аш кашыгы бал өстиләр. Суыткычта саклыйлар. Көненә 2-3 тапкыр чирек-яртышар стакан эчәләр. Яисә 4-5 бәрәңге кабыгын, яхшылап юып, ярты литр кайнар суга салалар да, капкачын томалап, сүрән утта 15 минут пешерәләр, суытып, сөзәләр, көн дәвамында 1-2 стакан эчәләр.

16 апрель (якшәмбе). ***Рамазан аеның 25 нче көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында,4.53 сәгатьтә калка, 14.30 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 14.12 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

Ютәлдән дәва

50 г йөзем өстенә 200 мл кайнар су салып, 30 минут төнәтәләр. 1 баш суганның согын сыгалар. Йөзем суына 3 аш кашыгы суган согы кушып, йокларга ятар алдыннан ваквак йотып эчәләр. Яисә ачы торманы юка телемнәргә турап, һәркайсы өстенә шикәр сибәләр дә, 6 сәгать төнәтәләр, бүленеп чыккан ширбәтне һәр сәгать саен 1 әр аш кашыгы эчәләр.

17 апрель (дүшәмбе). ***Рамазан аеның 26 нчы көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 5.03 сәгатьтә калка,16.03 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 14.16 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

Сихәтле төнәтмә

Тигез микъдарда канлы үлән, чабыр үләне, сары мәтрүшкә, кычытканны ваклап кушып, шуның 2 аш кашыгын 2 стакан кайнар суга салалар, 20 минут төнәтәләр, сөзәләр, суыткычта саклыйлар. Көн дәвамында әз-әзләп эчеп, 2 көндә бетерәләр. Дәва курсы – 2 атна. Болай дәвалану миомадан котылу мөмкинлеген бирә.

18 апрель (сишәмбе). ***Рамазан аеның 27 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 5.12 сәгатьтә калка, 17.33 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 14.21 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

Суган чәе

Аякны көзән җыерганда, суган чәе эчү булыша. 1 уч суган кабыгын 1 стакан кайнар суга салып куялар, 1-1,5 сәгатьтән соң, сөзеп, эчәләр. Тамыр тартышу туктаганчы шулай дәваланалар.

19 апрель (чәршәмбе). ***Рамазан аеның 28 нче көне. 29 нчы Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 5.20 сәгатьтә калка, 19.01 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 14.25 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Берминди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Бизләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур.

Тын кысканда

Өлкән яшьтәгеләр тын кысудан интегә. Халык медицинасында мондый чара кулланыла, һәм ул шактый кешегә тиз арада булыша. 10 баш сарымсак, 10 лимонны иттарткычтан чыгарып, 1 литр бал кушалар, 1 атна төнәтәләр. Көненә 1 тапкыр бер-бер артлы 4 чәй кашыгы эчәләр. Ясалган дару 1 ай буена дәваланырга җитә (баштa ярты дозадан гына ясап карарга да була).

20 апрель (пәнҗешәмбе). ***Рамазан аеның 29 нчы көне. 30 нчы, 1 нче Ай тәүлекләре. Ай Кучкар йолдызлыгында, 5.29 сәгатьтә калка, 20.30 сәгатьтә бата. 7 сәгать 13 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 14.30 сәгать.***

Тәүбә итү, гармониягә ирешү көне. Иҗат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Өйләнә-тирәнә дә, үз хисләреңне дә кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек, интуиция арта. Баш һәм йөрәк зәгыйфь. Арып-талганчы эшләргә, артык кайнар ризык ашарга ярамый.

Тары шифасы

1 аш кашыгы тары ярмасын яхшылап юып, 1 стакан суга салалар, 10-15 минут пешерәләр. 2 сәгать төнәтеп, сөзәләр. Конъюнктивит булганда, бәләкәй балаларның күзен йоклар алдыннан да, йоклап торгач та шуның белән юалар.

21 апрель (җомга). ***Шәүвәл аеның 1нче көне. 2 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 5.39 сәгатьтә калка, 21.58 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 14.34 сәгать.***

Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

Эремчекле катлама

250 г эремчек, 1 йомырка, ярты чәй кашыгы сода, 1 стакан оннан камыр басалар. Ярты сәгатьтән соң түгәрәкләп җәеп, өстенә фарш сылыйлар да, рулет итеп төрәләр. 2 шәр сантиметрлы кисәкләргә бүлеп, тирән табада майда кыздыралар.

Без – моңга бай халык

Без җыр-моңга бай халык. Һәр авылда, һәр төбәктә берсеннән-берсе мәгънәле, матур яңгырашы үзенчәлекле җырулар яши. Алар буыннан-буынга тапшырылып халык күңеленә күчә. Халкыбызның шул рухи байлыгын бөртекләп җыеп, башкаларга җиткерүче фидакарь җанлы кешеләр бар. Менә шундый күркәм, асыл затларның берсе – карендәшебез, сәнгать фәннәре кандидаты, Россия Композиторлар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Геннадий Михайлович Макаров.



Инде ничә еллар ул, илебезнең авыл-калаларын иңләп, төрле төбәкләргә сибелгән керәшеннәрнең мәдәни мирасын өйрәнә, аларны киң катлам укучыларга, тамашачыга җиткерү өчен күп хезмәт куя. Бу тынгысыз шәхеснең узган юлларын санасаң, кул бармаклары да җитмәс: Кострома, Әстерхан, Удмуртия, Башкорстан, Чувашия, Мордовия, Оренбург, Самара, Ульяновск, Пенза, Чиләбе, Екатеринбург, Пермь... Геннадий Макаров халкыбызның зур кыйммәткә ия әдәби-мәдәни мирасын югалтудан саклап калучыларның берсе. Борынгы уен коралларын да барлый, өйрәнә ул. Халыктан яздырып алган җырларны эшкәртеп, ноталарга сала, аларны туплап, күпсанлы китаплар бастырып чыгара. Күпме көч, күпме хезмәт таләп итә ул җыентыклар, никадәр мәшәкатьле, җаваплы эш бу!

2005 елны, Казан педагогика университетының музыка факультетын тәмамлаганда, диплом эшемнең темасы итеп мин керәшен җырларын мәктәп балаларына өйрәтүне сайлап алган идем. Геннадий Михайлович туган авылымның халык авыз иҗатына игътибар бирергә, керәшен җыруларын оста башкаручылардан яздырып алып, диплом эшенә кертергә киңәш итте. Мин ул чакта нибары бер ападан гына җырлар яздыра алсам да, бу эшнең никадәр вак, җитди һәм җаваплы икәненә төшендем. Ә Геннадий Михайлович йөзләгән кеше белән очрашып, энҗе-мәрҗәннәрдәй төрле тарафка сибелгән күпме җырны туплый алган! Ул чакта бүгенге кебек уңайлы шартлар да булмаган, кассета белән уйнатыла торган зур магнитофоннар, шнурлы микрофоннар күтәреп йөргән заман булган.

Җырулар, бию-уеннарны берәмтекләп өйрәнү белән беррәттән Геннадий Макаров керәшеннәрнең төрле төбәкләрдәге сөйләм үрнәкләрен үзенчәлекләрен дә язып ала, милли киемнәргә зур игътибар бирә. Думбыра, гөслә, сызгычлы кубыз, нугай курай кебек уен коралларын үз куллары белән ясый.

Керәшеннәрнең «Бәрмәнчек» Дәүләт фольклор ансамбле шушы җырларны, әсәрләрне үз репертуарына ала. Аларны Казан дәүләт консерваториясе студентлары да башкара, төрле-төрле ансамбльләр Макаров туплаган материалны куллана. Мин үзем дә 2016 елда ТНВ каналы белән берлектә керәшен җырларыннан торган концерт яздырдым. Алар нигездә Геннадий Михайловичтан өйрәнгән җырлар иде. Ул концертны әзерләргә үзе дә ярдәм итте, җырларны яздыруда булышты, тәпле киңәшләрен бирде.

Ә хәзер керәшеннәрнең горурлыгы булган «Бәрмәнчек» ансамбле тарихына күз салыйк. 2002 елда Г.Макаров бер төркем керәшен яшьләрен җыеп, ансамбль оештырып җибәрә. Бу ансамбльдә Казан педагогика университеты, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институты һәм Казан консерваториясе студентлары җырлый. Өр-яңа, моңарчы беркайда да

ишетелмәгән җырлар өйрәтә иде безгә Геннадий Михайлович. Берсеннән-берсе матур яңгырашлы, үзенчәлекле җырлар. Репертуарыбыз шактый тулылангач, Олы көнгә, Раштуа һәм башка бәйрәмнәргә багышланган концертлар белән чыгыш ясый идек. Геннадий Макаров оештырган шушы кечкенә генә «Бәрмәнчек» студентлар ансамбле 2008 елда Дәүләт ансамбле статусына ирешә.

Г.Макаров озак еллар Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшли. Ул – сигез китап, йөздән артык фәнни мәкалә авторы. Мәсәлән, 2014 елда чыккан «Керәшен мәдәнияте» китабында этнографик экспедицияләрдә язып алынган дини фольклор җыру-көй үрнәкләренең текстлары, ноталары тәкъдим ителә. Бу җыентык гомуми белем бирү уку йортларында, атнакөн мәктәпләре сыйныфларында төрле бәйрәмнәр, тематик кичәләр, концертлар әзерләү эшендә ярдәмлек булып тора. «Нагайбәк халык җырлары», «Милли моңнар», «Татарстанның көньяк-көнчыгыш җирлегендә яшәгән халык музыкантлары» һ.б. китаплары – Г.Макаровның күп еллык фидакарь хезмәте нәтиҗәсе.

Хәзер Г.Макаров Казан консерваториясенең татар музыкасы һәм этномузыка белеме кафедрасы доценты вазыйфасында. Я.Емельянов исемендәге мәдәни үзәк белән хезмәттәшлек итә. Рухи байлыгыбызның бөеклеген танытуда, халыкчан җыр-моңнарыбызны студентларга җиткерүдә зур эшләр башкара. Геннадий Михайловичның шәкертләре уку йортын уңышлы тәмамлап, фольклор, этномузыка буенча республикабызда һәм башка төбәкләрдә дә остазларының эшен дәвам итә.

Геннадий Макаров – керәшеннәр газетасы – «Туганайлар»ның якын дусты, үзенең акыллы киңәшләрен бирүче остаз, газета битләрен саллы мәкаләләр, фәнни язмалар белән баетучы галим. Бар гомерен халыкка хезмәт итүгә багышлаган күпкырлы талант иясе ул. Сәнгать, мәдәният өлкәсендә республикада гына түгел, Россия күләмендә танылу алган, хөрмәт казанган шәхес. Нинди зур дәрәҗәләргә ирешсә дә, без аны олы йөрәкле, ярдәмчел, ихлас кеше буларак беләбез.

2023 елда Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясенә кандидатлар исемлегендә күренекле шәхесебез Г.Макаров исемен дә күрү минем өчен шатлык һәм горурлык булды. Быел, Татарстанда милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы дип игълан ителгәндә, бу олы бүләккә ул һичшиксез лаек.

Людмила АЛАНЛЫ,
шагыйрә.

АСЫЛТАШ

Элек-электән җырлы-моңлы татар халкында көй-моңнарга әвәс моңсарлар бихисап булган, ә менә музыкаль әсәрнең чын асылын аңлатып бирә белүче сәнгать белгечләре бармак белән генә санарлык. Дөрес, алар бар һәм бер-берсенә охшамаган да: кемдер үз фикерен кайнарланып яклый, көрәш юлын сайлый, ә кайберсе барчасына ярарга тырышып әйләнеч юллардан атлый. Күптөрле, чуар, кызыклы галим-голәма арасында Земфира СӘЙДӘШЕВАның үз юлы, үз урыны бар. Туры сүзле, тыныч-тигез холыклы, һәркемгә ярдәмчел остаз-педагог үз һөнәрен бик тә белеп сайлаган дип уйлыйм мин.

Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясендә ул халык иҗаты фәнен укыта. Татарстанның һәм Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе, сәнгать фәннәре докторы, профессор Земфира Нурмөхәммәт кызының шәкерте булмавыма үкенеп куйган чакларым бар. Консерваториядә укыганда безгә рус халык җырларының борынгы үрнәкләрен генә ятлаталар иде, әгәр аһәңне тотып, җырны отып ала алсаң, бу фәнне үзләштергән булып исәпләнәсең. Шул чакта ук татар халык иҗатын өйрәнгән булсакмы?! Халкыбызның авыз иҗатына мәхәббәт безгә дә яшьли йоккан булыр иде. Музыка дөньясына шактый соңарып аяк бастым шул мин. Урта мәктәпне тәмамлагач кына музыка теориясен ашыгычлык белән үзләштерергә тотындым.

Ә Земфира Сәйдәшева көй-моңнарга коенып үскән: абыйлары, апасы һәм үзе дә балачактан музыка мәктәбендә укыганнар, җырларга, уен коралларында уйнарга һәркайсы әвәс булган. Музыка дөньясында үз кеше булачагы алдан ук билгеләнеп куелган, дияргә дә ярар иде. Әгәр адәм юрый, Аллаһ юллый дигәннәре булмаса... Хәер, һәркемнең юлында очрый торган киртәләргә, тормыш бусагаларына кемдер абынып егыла, ә кемнедер алар чыныктыра. Земфира соңгы төркемгә керәдер дип уйлыйм. Кыенлыкларга бирешмичә, максатына ирешү юлында, күптөрле киртәләрне җиңә-җиңә, алга ашкынуы аны белә-белгәннән бирле мине гаҗәпкә калдыра. Югыйсә, язмышның аны кат-кат сынавы хак... Махсус музыкаль белем алган, консерватория тәмамлаган, җыр-моңнарга гашыйк Земфира Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында лаборант булып эшли башлый.

Борынгы җыруларыбызны тыңлау, рухи тормышыбызның мирасы исәпләнгән татар халык авыз иҗаты белән якыннан һәм тирәнтен танышу аның дөньяга карашын үзгәртә, хәтта башка юлга борып, фәнгә кертеп җибәрә. Атаклы фольклорчы Хәмит ага Ярми магнитофон тасмасына яздырып алган халык көйләрен нотага салу, төрләргә аеру, авыз иҗатын системалаштыру өстәмә белем, туган халкы, аның яшәү рәвеше хакында мәгълүматларны киңәйтүне таләп итә. Бәхетенә, тиздән Институтта музыка белеме буенча аспирантурасы да булган сәнгать секторы ачыла. Земфира Сәйдәшева беренчеләрдән булып аспирантура тәмамлый. «Татар композиторлары җырларында фольклор традицияләре» дигән темага яклаган кандидатлык диссертациясен бу фәндә казанышка тиңлиләр. Татар халык иҗатын фәнни нигезгә салып, яратып өйрәнүе аның киләчәк язмышында хәлиткеч роль уйный; республика музыка белгечләре арасында беренче булып 1998 елда Мәскәүдә докторлык диссертациясе яклый ул. Идел-Кама буе татарларының җыр мәдәнияте үсеше тарихына багышланган фәнни эше – тикшеренүләре музыка белеме өлкәсендәге эзләнүләре ачышка тиң. Татар музыка тарихын укытучылар һәм студентлар Земфира Сәйдәшева китапларыннан өйрәнәләр икән, бу да гаять күпне сөйли. Саллы-саллы китаплар авторы ул, чит республикаларда, мәсәлән, Азәрбайҗан консерваториясендә дә музыка этнографиясе буенча лекцияләр укый, конференцияләрдә, симпозиумнарда чыгышлар ясый. Шундый шәхес белән якыннан таныш, хәтта дус булуым горурлык хисләре уята.

«Халкым моңнары», «Из коллекции фольклориста: татарско-мишарские песни» «В мире татарской музыки», «Ярулиннарның туган җир җырлары», «Татарская музыка: история и современность», «Нурлат районының татар җырлары», «Очерки по татарской музыке» хезмәтләре өчен Земфира Сәйдәшева Татарстан Рәисе каршындагы комиссия тарафыннан 2023 елда Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә кандидат итеп теркәлде. Музыка белгече кебек сирәк һөнәр вәкиле булган З.Сәйдәшева бүләккә һичшиксез лаек.

Клара ТАҖИЕВА,
сәнгать белгече.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

14 апрель – «Рәшә» (Ә.Еники).
15 апрель – зур залда – «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин). Кече залда – «Хуш, авылым. Хыял» (А.Җаббаров).
16 апрель – «Өйләнәм. tat» (И.Зәйниев).
18 апрель – «Килмешәк» (С.Гаффарова).
19 апрель – С.Сәйдәшев исемендәге дәүләт зур концерт залы бинасында театр оркестрының «Алар беренчеләр иде» дип исемләнгән концерты. Кече залда – «Исәнме, улым!» (Б.Абдураззоков).
21 апрель – Премьера. «Көзге кайтаваз» (Р.Галиуллин).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

15, 16 апрель – «Лебединое озеро» (П.Чайковский).
17, 18 апрель – «Кострома» рус милли балетының «Улица мира» программасы.
20 апрель – «Риготлетто» (Дж.Верди).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

14 апрель – Премьера. «Яратам! Бетте-китте!».
15 апрель – «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов).
16 апрель – «Назлы кияү» (К.Тинчурин).
18 апрель – «Чулпан» (Ш.Хөсәенов).
19 апрель – «Хыялый» (С.Әбүзәров).
20 апрель – «Төш» (Т.Миңнуллин).
21 апрель – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

14 апрель – «Сөннәтче бабай» (Г.Исхакый).
15 апрель – 13.00 – «Минем бәхетле көнем» (Е.Гороховская). 18.00 – «Артист» (Р.Зәйдулла).
16 апрель – 13.00 – «Кәҗүл читек» (Г.Исхакый). 18.00 – «Ак чәчәкләр кебек...» (Р.Мухина).
18 апрель – «Озын-озак балачак» (М.Кәрим).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

14 апрель – Саратов курчак театрының «Бременские музыканты» спектакле.
15 апрель – фойеда – «Не хочу, не буду» (П.Геннадьева). Зур залда – Саратов курчак театрының «Тайна волшебной шляпы» спектакле.
16 апрель – зур залда – Саратов курчак театрының «Клочки по закоулочкам» спектакле. Кече залда – «Су анасы» (Г.Тукай).
18 апрель – «Ночь перед Рождеством» (Н.Гоголь).
20, 21 апрель – «Волшебник изумрудного города» (А.Волков).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

14 апрель – Татарстан Республикасы халык музыка уен кораллары дәүләт оркестрына Ф.Кузнецов һәм Р.Галимова кушылып җырлый.
16 апрель – 11.00 – Балалар өчен яз концерты. 18.30 – Ирле-хатынлы җырчыларның солянка-концерты. Катнашалар – Зөлфия һәм Җәвит Шакировлар, Люция Мусина һәм Рөстәм Закиров, Илназ Бах һәм Гүзәл Идрисова, Гөлназ һәм Илсур Шәрипҗановлар, Гөлназ Асаева һәм Вилли, Рәфинә Ганиуллина һәм Рәзил Камалов, Рафил Җәләлиев һәм Эльмира Гыйльфанова, Динә һәм Рафаэль Латыйповлар, Алинә һәм Азат Кәримовлар, Марат Галимов һәм Линара Батталова, Азат Абитов һәм Гөлсирин Абдуллина, Рамилә һм Рамил Хәйретдиновлар.
17 апрель – «Подыскиваю жену, недорого!» спектакле.
18 апрель – Елена Воробей һәм Сергей Дроботенко концерты.
19 апрель – Композитор Александр Даргомыжскийның 210 еллыгына багышланган концерт. Җырлый Владимир Васильев.
20 апрель – «Кояш турында хәтер» исемле әдәби-музыкаль кичә.
21 апрель – Татарстан Республикасы филармония джаз оркестры һәм Денис Мажуковның атаклы Элвис Преслига багышланган концерты.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

15 апрель – «Рахлин сезоннары» XII халыкара фестивале кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт академия симфоник оркестры концерты. Дирижер – Конрад ван Альфен. Солист – Бенедикт Клекнер (виолончель).
16 апрель – 12.00, 14.30 – балалар өчен орган концерты.
21 апрель – Татарстан Республикасының Миләүшә Тәминдарова җитәкчелегендәге камера хоры концерты.

Асыл кычыткан

Асылташ белән кычыткан арасында нинди уртаклык бар? Кычыткан энәләренең дә, асылташның да химик составы бер үк – кремний двуокисе. Агат, аметист, тау бәллүре, оникс кебек үк, кычыткан энәсе дә кремний двуокисеннән тора һәм эче куыш цилиндрны хәтерләтә. Кремний двуокисе – бик уалучан, шунлыктан кычыткан энәсе тиеп китүгә үк сына һәм очлы кырые белән тирегә батып керә, 4 төрле химик матдә сиптерә, шуңа пешереп алгандай була. Әгәр кычыткан яфрагын өзеп алып, бөгәрләсәң һәм үзе үк өтеп алган урынга сөртсәң, авырту тиз басыла. Тимор утравында исә дөньяда иң зәһәр кычыткан үсә. Аңа ялгыш тиеп китсәң, шул урын бик тиз шешеп чыга һәм атналар буена төзәлми.

(“The Mirror”).

Киңәшкә колак сал!

Бөекбритания галим-диетологлары, дүрт атна эчендә корсактагы май катламыннан котылып була, дип раслый. Сонал Шах әйтүенчә, беренче чиратта иртәнге аш рационын үзгәртү зарур: углеводлар урынына аксым һәм майларны күбрәк кулланырга кирәк. Мондый иртәнге аш кандагы шикәр микъдарын тотрыкландыра һәм инсулин тәэсирен киметә. Висцераль (эчке әгъзаларны урап алган) майдан котылу өчен, көн дәвамында углеводлар куллануны киметү таләп ителә. Ябыгу буенча китаплар авторы Зана Моррис та шикәрдән баш тартырга өнди. Бу очракта организм үзендәге май запасын эшкәртә башлый икән, тормыш өчен мөһим витамин һәм минералларны исә эшкәртелмәгән бөртеклеләрдән һәм табигый углеводлар – җиләк-җимеш, бал, бәрәңгедән ала. Моннан тыш, сылуланырга теләгән кеше кулланганнан күбрәк калорияне яндырырга тиеш, әмма физик күнегүләр ясау гына җитми, диета тоту да таләп ителә. Вашингтон университеты галимнәре симез кеше организмында фирмикутлар (ризыктан күбрәк калория үзләштереп калырга “котыртучы” бактерияләр) күп дип саный, моны үзгәртү өчен, эчәклектәге микроорганизмнар составын көйләү җитә – рационда төрле ашамлык, шул исәптән яшелчәләр, әчегән сөт ризыклары, тозлы кәбестә, бөртеклеләр булырга тиеш. Диетолог Хейзел Уоллис исә сәламәт һәм зифа-сылу тәнле булу өчен туйганчы йокларга һәм стресстан сакланырга киңәш итә.

(“The Sun”).

Банан, йомырка, авокадо...

Майларны тиз арада яндыру һәм мускул массасын үстерү өчен интенсив күнегүләр ясаганда, йомырка, банан, авокадо кебек ризык ашау файдалы. Испаниядә әлеге проблеманы өйрәнүче табиб-диетологлар Гильермо Гомес Вера белән Нурия Монфульеда әйтүенчә, йомыркадагы аксым һәм лейцин мускулларга тизрәк үсү мөмкинлеге бирә. Аксымга тавык ите дә бай, ул сыер итен алыштыра ала. Вегетарианнарга исә тавыкны аксымга бай тофу белән алыштырырга киңәш ителә. Тофу, гомумән, спортчылар өчен менә дигән ризык санала. Банан исә, углеводка бай булганга, тиз арада туклану хисе тудыра һәм көн дәвамында азрак ашау мөмкинлеге бирә. Интенсив физик күнегүләр ясар алдыннан – банан, аннан соң исә шикәрсез йогурт ашарга киңәш ителә. Мускул үстерергә теләүчеләргә туендырылган майлар, аксым, углеводка бай кузаклылар һәм авокадо ашау да файдалы.

(“La Vanguardia”).

Хөрмә дәвасы

Йокларга ятар алдыннан 5 хөрмә ашауны гарәп им-томчылары йокысызлыктан коткара торган иң шәп чара дип саный. Фән исә әлеге дәваның чыннан да нәтиҗәле булуын дәлилли. Хөрмәдә триптофан бик күп, ә бу аминокислота татлы йокы өчен җаваплы серотонин һәм мелатонин җитештерүдә алыштыргысыз. Шуның өстенә, хөрмә бик туклыклы да, аның 100 граммы организмның С витаминына булган тәүлеклек ихтыяҗын канәгатьләндерергә җитә.

(“Лента.ру”).

Җитездән җитез

Җирдәге иң җитез җан иясе – лачын. Аның очыш тизлеге секундына 90 метрга (сәгатенә 320 километрга) җитәргә мөмкин. 2005 елда сапсан лачыны дөнья рекорды куйган – аның сәгатенә 389 километр тизлек белән очуы теркәлгән. Кош корбаны өстенә күктән таш кебек атылып төшә һәм очлы тырнаклы тәпиләре белән бәреп ега. Шулкадәр көч белән бәрә ки, еш кына корбанының башы өзелә яки гәүдәсе шартлап ярыла.

(“Вокруг света”).

Дөньяда игелек күбрәк!

Садио Мане 1992 елның 10 апрелендә Сенегалның Седиу шәһәрендә туган. Бераздан Бамбали авылына күченгәннәр, тыгыз кешелек гаилә кечкенә генә бер йортта яшәгән. Малай еш кына ач булган, уку урынына кырда эшләгән, әмма бөтен буш вакытында туп типкән. Садиога 11 яшь тулгач, әтисе үлгән, хәлләр тагын да мөшкелләнгән. Малай бу вакытта инде чын-чынлап футбол белән җенләнгән, бары шул уенның гына гаиләне хәерчелектән котылдыра аласына саф күңеле белән инанган. Әнисе дә, туганнары да аның бу мавыгуына каршы булган, әмма үсмер ничек тә осталыгын чарларга тырышкан, төрле командаларда уйнаган. Ниһаять, аны Франциягә чакырганнар. “Метц” командасы белән контракт төзегәнче, аңа өйдәгеләрнең берсе дә ышанмаган. Шуннан әкренләп күтәрелгән. 2016 елда исә инде “Ливерпуль” белән 34 миллион фунт стерлинглык контракт төзегән һәм тарихта иң кыйбатлы Африка уенчысына әйләнгән. 2019 елда Месси, ван Дейк һәм Роналду белән беррәттән иң дәрәҗәле “Алтын туп” бүләген дәгъвалаган. 2022 елда “Бавария” командасына күчкән, трансфер суммасы 32 миллион евро тәшкил иткән. Хәзер аның бер атналык хезмәт хакы, әле реклама контрактларын санамыйча, 170 мең еврога тәңгәл. Тик никадәр баеса да, Садио чын кеше булып калган. Имам малае булганга, ул дини булып үскән, биш вакыт намазын калдырмый. Кыйммәтле сәгатьләре дә, машиналары да юк, экраны чатнаган телефон белән йөри. Әмма ул башкаларга булыша: Бамбали авылындагы йөздән артык ярлы гаиләгә ай саен 70 әр евро акча бирел бара. Яхшы укучы үсмерләргә 350 шәр евро стипендия билгеләгән һәм ноутбуклар бүләк иткән. 2019 елда авылында 285 мең еврога мәктәп, 2021 елда 562 мең еврога хастаханә төзеткән. Почта, мәчет, ягулык салу станциясе, стадион салдырган, 4G-интернет каланчасы урнаштырган. 19 яшеннән бирле Сенегал җыелма командасында уйный, имгәнгәнгә күрә, быелтыр Катардагы дөнья чемпионатында катнаша алмаган – бу илкүләм фаҗигагә әйләнгән.

(“Интересно.сс”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

17 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2». 16+
10.00, 23.00 «ТАИНСТВЕННАЯ СТРАСТЬ». 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30, 16.30 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «ӨЧ ДУС». 16+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Акыл батл».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00, 0.25 «Таяну ноктасы». 16+
19.30 Хоккей. Кубок Гагарина.
22.00 «Вызов 112». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.35, 16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 0.40 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». 16+
15.25, 20.30 «Заман көзгесе». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.15 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы». 6+
19.30 «Калеб». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ОСКОЛКИ». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВОСТОК - ЗАПАД». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.55 «КАК ВЫЙТИ ЗАМУЖ ЗА МИЛЛИОНЕРА 2». 12+
14.35 «Человек на своем месте». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Война за воду. Цикл новый взгляд». 12+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗА ПОЛЧАСА ДО ВЕСНЫ». 12+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 Подкаст.лаб «Антропология». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛЮБОВЬ ПРЕОДОЛЕЕТ ВСЁ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Елена Мрозовская.
7.35 «Кто написал Библию? Разгадка одной из величайших тайн истории».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50 «СЫН».
10.15 «Наблюдатель».
11.15 XX век. «Галина Писаренко».
12.10 Цвет времени. Караваджо.
12.45 Новости. Подробно. АРТ.
13.00 «Михаил Абрамов. Русское наследие».
13.50 «СЕРДЦЕ НЕ КАМЕНЬ».
16.05 Линия жизни. Николай Дроздов.
17.15 «Гардемарины, вперёд!» Невидимые слёзы».
18.00 Цвет времени. Ван Дейк.
18.10 Пианисты XX века. Николай Петров.
19.00 «Почерк эпохи».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Хранители жизни. Чумаков».
21.30 «Сати. Нескучная классика...»
22.15 «ОБИТЕЛЬ».
23.15 «Рэгтайм, или Разорванное время». «Энтомолог Танасийчук и спелеолог Пантюхин».
23.45 «Магистр игры». «Личины грядущего хама».

«НТВ»

4.45 «ПЛЯЖ. ЖАРКИЙ СЕЗОН». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.10, 0.00 «МЕТОД МИХАЙЛОВА». 16+

Сишәмбе

18 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2». 16+
10.00, 23.30 «ТАИНСТВЕННАЯ СТРАСТЬ». 12+
11.00 «Азбука долголетия». 16+
11.15 «Память сердца». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.40 «ӨЧ ДУС». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Төймә».
16.00 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
21.00, 22.10 «Трибуна «Нового Века». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Нәсыйхәт». 16+
12.05, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». 16+
15.25, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.15 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ОСКОЛКИ». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВОСТОК - ЗАПАД». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.55 «КАК ВЫЙТИ ЗАМУЖ ЗА МИЛЛИОНЕРА 2». 12+
14.35 «Человек на своем месте». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Война за воду. Цикл новый взгляд». 12+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗА ПОЛЧАСА ДО ВЕСНЫ». 12+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 Подкаст.лаб «Жизнь замечательных». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛЮБОВЬ ПРЕОДОЛЕЕТ ВСЁ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Математика и подъем цивилизации».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50 «СЫН».
10.15 «Наблюдатель».
11.15, 23.40 «Лев Яшин». «Александр Мальцев. Последний сезон».
12.15 Цвет времени. Уильям Тёрнер.
12.45 Новости. Подробно. Книги.
13.00, 19.00 «Почерк эпохи».
13.30 «Игра в бисер» «А.Н. Островский. «Бесприданница».
14.10 «Кто написал Библию? Разгадка одной из величайших тайн истории».
15.05 «Сати. Нескучная классика...»
15.50 «Подземные дворцы для вождя и синицы».
16.30 «Рэгтайм, или Разорванное время». «Энтомолог Танасийчук и спелеолог Пантюхин».
17.15 «Передвижники. Марк Антокольский».
17.40 «Забытое ремесло».
18.00 Пианисты XX века. Артур Рубинштейн.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Искусственный отбор.
21.30 «Белая студия».
22.15 «ОБИТЕЛЬ».
23.15 «Рэгтайм, или Разорванное время». «Счастливый случай по имени Тихонов».

«НТВ»

4.45 «ПЛЯЖ. ЖАРКИЙ СЕЗОН». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.10, 0.00 «МЕТОД МИХАЙЛОВА». 16+

Чәршәмбе

19 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

Телевизор караучылар игътибарына! Чәршәмбе, 19 апрель «ТНВ» һәм «ТНВ-Планета» телеканалларында профилактика чаралары үткәрү сәбәпле, 2.00 сәгатьтән 9.00 сәгатькә кадәр тапшырулар трансляцияләнми.
9.00, 17.00 «БИЧАРАКАЙ». 16+
10.00, 23.00 «ТАИНСТВЕННАЯ СТРАСТЬ». 12+
11.00, 0.25 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ӨЧ ДУС». 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.30, 19.00 Новости Татарстана. 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00, 0.50 «Таяну ноктасы». 16+
18.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
19.30 Хоккей. Кубок Гагарина.
22.00 «Вызов 112». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

9.00 «Хәдичә Гыйниятова җырлый». 6+
9.40 «Йөрәктән - йөрәккә». Ибраһим Нуруллин турында телеочерк. 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «АЛМАШ». 16+
13.05 «Палитра». Бакый Урманче. 16+
13.50, 21.25 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Ишеттем мин кичә бераү җырлый». 16+
15.25, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.15 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.20 «Йөрәктән-йөрәккә». Ибраһим Нуруллин турында телеочерк. 16+
20.30, 0.15 «Яшьләр тукталышы». 6+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ОСКОЛКИ». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВОСТОК - ЗАПАД». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.55 «КАК ВЫЙТИ ЗАМУЖ ЗА МИЛЛИОНЕРА 2». 12+
14.35 «Человек на своем месте». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Кремль. Страницы истории». 12+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗА ПОЛЧАСА ДО ВЕСНЫ». 12+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 Подкаст.лаб «Психика». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДОРОГА К СЧАСТЬЮ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.15, 23.40 XX век. «Волшебник XX века. Кио 100». Гала-концерт иллюзионистов в Цирке на Цветном.
12.45 Новости. Подробно. Кино.
13.00, 19.00 «Почерк эпохи».
13.30 Искусственный отбор.
14.10 «Математика и подъем цивилизации».
15.05 «Белая студия».
15.50 «Путешествие из Дома на набережной».
16.30 «Рэгтайм, или Разорванное время». «Счастливый случай по имени Тихонов».
17.15 «Библейский сюжет».
17.45 «Забытое ремесло».
18.00 Пианисты XX века. Артуро Бенедетти Микеланджели.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Абсолютный слух.
21.30 Власть факта. «Золотой век Византии».
22.15 «ОБИТЕЛЬ».
23.15 «Рэгтайм, или Разорванное время». «Писатель Орлов и альтист Данилов. Мессерер - король богемы. Ямщиков и компания».

«НТВ»

4.50 «ПЛЯЖ. ЖАРКИЙ СЕЗОН». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.10, 0.00 «МЕТОД МИХАЙЛОВА». 16+

Пәнҗешәмбе

20 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «БИЧАРАКАЙ». 16+
10.00, 0.00 «ТАИНСТВЕННАЯ СТРАСТЬ». 12+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «ӨЧ ДУС». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Рыцари вечности». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.10 «Сөенеч».
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Юлчы». 16+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Погружение на 100». 12+
21.10 «Соотечественники». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Безнең Республика - безнең гамәл». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20 «Ася, Асечка, Асия». Асия Галиева турында телеочерк. 16+
15.25 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.15 «Музыкаль мәйдан». 16+
20.00 «Әнием нең җылы кочагы». 16+
21.25 «Еллар һәм чорлар». 16+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «ОСКОЛКИ». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВОСТОК - ЗАПАД». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «КАК ВЫЙТИ ЗАМУЖ ЗА МИЛЛИОНЕРА 2». 12+
14.35 «Человек на своем месте». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Убить гауляйтера. Приказ для троих». 12+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+

16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗА ПОЛЧАСА ДО ВЕСНЫ». 12+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДОРОГА К СЧАСТЬЮ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино. Сергей Бондарчук.
7.35, 14.10 «Математика и подъем цивилизации».
8.20 Дороги старых мастеров. «Лоскутный театр».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50 «ИРКУТСКАЯ ИСТОРИЯ».
10.15 «Наблюдатель».
11.15, 23.40 «Павел Луспекаев».
12.45 Новости. Подробно. Театр.
13.00, 19.00 «Почерк эпохи».
13.30 Абсолютный слух.
15.00 «2 Верник 2».
15.50 «Твербуль, или Пушкинская верста».
16.30 «Рэгтайм, или Разорванное время». «Писатель Орлов и альтист Данилов. Мессерер - король богемы. Ямщиков и компания».
17.15 Пряничный домик. «Портреты растений».
17.45 Пианисты XX века. Клаудио Аррау.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Юрий Буйда. «Прусская невеста».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Сталкер». Кого же мне водить туда?»
21.30 «Энигма. Дмитрий Ульянов».
22.15 «ОБИТЕЛЬ».
23.15 «Рэгтайм, или Разорванное время». «Жизнь со звоном». Иван Андреевич Духин».

«НТВ»
4.50 «ПЛЯЖ. ЖАРКИЙ СЕЗОН». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.10, 0.00 «МЕТОД МИХАЙЛОВА». 16+

Җомга

21 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Бу - мөбәрәк җомга көн». 12+
6.00 «Манзара». 16+
6.50, 17.00 «Ураза гаете мөбәрак булсын!»
7.45, 14.45 «Изге Рамазан». 12+
8.10 «Мөнәҗәт әйтәм». 12+
9.00, 15.15 «БИЧАРАКАЙ». 16+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.30, 19.00 Новости Татарстана. 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Родная земля». 12+
18.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
19.30 Хоккей. Кубок Гагарина.
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «КВН РТ-2023». 16+
23.10 «ТЫ У МЕНЯ ОДНА». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Манзара». 16+
6.50, 15.25 «Ураза гаете мөбарәк булсын!» 6+
7.45 Концерт «Мөнәҗәт әйтәм». 6+
8.50, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.50, 17.00, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.25, 21.25 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Ишеттем мин кичә бәрәү җырлый». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 Спектакль «Мулла». 16+
14.20 «Кунакчык бәяны». Мөнәҗәтләр. 6+
15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.00 «Яңалыклар». 12+
18.20 «Таян Аллага». Зөһрә Сәхәбиева концерты. 6+
20.00 «Родная земля». 12+
20.30 «Заман көзгесе». 6+
22.15 «Мөнәҗәт әйтәм». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВОСТОК - ЗАПАД». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «АФРИКАНЕЦ». 12+
14.35 «Человек на своем месте». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Эдмонд Кеосаян. Не только «Неуловимые». 12+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «Ураза-Байрам».
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 15.15, 16.50 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «ГОЛОС». 12+
23.55 «Вызов. Первые в космосе». 12+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России».
9.00 Праздник Ураза-Байрам.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.30, 21.05 Вести. Местное время.
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.20 «ДОРОГА К СЧАСТЬЮ». 12+
23.25 «Улыбка на ночь». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 14.10 «Математика и подъем цивилизации».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50 «ИРКУТСКАЯ ИСТОРИЯ».
10.15 «ГОБСЕК».
11.45 «Первые в мире».
12.00 Открытая книга. Юрий Буйда. «Прусская невеста».
12.45, 17.40 «Забытое ремесло».
13.00 «Почерк эпохи».
13.30 Власть факта. «Золотой век Византии».
15.00 «Энигма. Дмитрий Ульянов».
15.45 «Человек эры Кольца. Иван Ефремов».
16.30 «Рэгтайм, или Разорванное время». «Жизнь со звоном». Иван Андреевич Духин».
17.15 Письма из провинции.
17.55 Пианисты XX века. Владимир Ашкенази.
18.45 «Билет в Большой».
19.45 «Смехоностальгия».
20.15 К 80-летию Анатолия Кролла. Линия жизни.
21.10 Искатели. «Пропавшие шедевры Фаберже».
21.55 «МОЙ ЛЮБИМЫЙ КЛОУН».
23.20 «2 Верник 2».

«НТВ»
4.45 «ПЛЯЖ. ЖАРКИЙ СЕЗОН». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.10 «МЕТОД МИХАЙЛОВА». 16+

Шимбә

22 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.20 «Риваять» төрки-татар этникасы ансамбле концерты. 12+
12.00, 0.40 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 «Созвездие - Йолдызлык-2023». 6+
15.00 «Яңа татар җыры-3» конкурсының гала-концерты. 12+
16.00 «Безнең Республика - безнең гамәл». 16+
17.00 «Татар халык җырлары».
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Tatarstan today». 16+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит шоу». 16+
23.00 «КОМАНДА МЕЧТЫ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Марат Әмирханов турында телеочерк. 16+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Йөрәктән-йөрәккә». Харис Нигъмәтҗанов турында телеочерк. 16+
13.50 «Казан» бию ансамбле концерты. 6+
17.15 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Мирас» YII татар музыкасы фестивале. 6+
22.30 «АЛМАШ». 16+

«ЭФИР»
5.00, 14.35 «Человек на своем месте». 12+
5.30 «Дело №». 12+
6.30 «Тайны нашего кино». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Магия вкуса». 12+
8.30 «Вместе в космос». 12+
8.55 «В ПЛЕНУ У ЛЖИ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ТАРИФ «СЧАСТЛИВАЯ СЕМЬЯ». 12+
15.00 «Идущие в огонь». 12+
15.55 «Я РЯДОМ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «РЕЖИМ ГЕРОЯ». 12+
22.30 «ТАНЦЫ НА ГРАНИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Поехали!» 12+
11.10 «ПроУют».
12.15 «Видели видео?»
13.50 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ 4». 12+
18.20 «Сегодня вечером». 16+
21.00 «Время».
21.35 «КВН». 16+
23.50 «ВИДИМОСТЬ». 16+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.40 «Доктор Мясников». 12+
12.45 «ДЕВЯТЬ ЖИЗНЕЙ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «СТАРОЕ ПИАНИНО». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.00 Мультфильмы.
7.50 «МОЙ ЛЮБИМЫЙ КЛОУН».
9.15 «Мы - грамотеи!»
10.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «НЕПОДСУДЕН».
11.45 «Спасительница. Тайна буддийской иконы».
12.30 «Передвижники. Марк Антокольский».
13.00 «Страх в саванне».
14.00 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.25 «Феликс Вишневский. Меценат советского периода».
16.00 «ПРИВАЛОВСКИЕ МИЛЛИОНЫ».
18.40 «Анна Тимирёва. Возлюбленная Колчака».
19.50 «ГОРОДСКОЙ КОВБОЙ».
22.00 «Агора».
23.00 Клуб «Шаболовка, 37».

«НТВ»
4.50 «Жди меня». 12+
5.40 «ЧУЖОЙ ДЕД». 16+
7.25 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!» 16+
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Модный vs Народный». 12+
14.20 «Своя игра».
15.20 «Игры разумов».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Страна талантов». 12+

Якшәмбе

23 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
6.00 «Болгар радиосы» бәйрәм концерты. 12+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 «Полосатая зебра».
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Ачыктан - ачык». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.30 «Тархан». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.55 «Сөенеч».
14.00 «Созвездие - Йолдызлык-2023». 6+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00, 0.45 «Ком сәгате». 16+
17.00 Хоккей. Кубок Гагарина.
19.30, 22.00 «Семь дней». 16+
20.30 «Заман көзгесе». 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «ТЫ ЕСТЬ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 Дания Нуруллинаның юбилей кичәсе. 16+
9.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Хәким Сәлимҗанов турында телеочерк. 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.50 «Мәңгелек юлында». Мөхәммәт Мирзаның 70 яшьлек юбилей кичәсе. 12+
15.35 «Йөрәктән-йөрәккә». Мирхәйдәр Фәйзи. 6+
16.20, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
21.50 «Мөселман дөньясының заманча музыкасы». 6+

«ЭФИР»
5.00 «Человек на своем месте». 12+
5.30 «Дело №». 12+
6.30 «Тайны нашего кино». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Магия вкуса». 12+
8.30 «Вместе в космос». 12+
8.55 «Я РЯДОМ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ПЯТЬ ЗВЕЗД». 16+
14.45 «Первые в мире». 12+
15.00 «Блин. Ком». 16+
15.55 «В ПЛЕНУ У ЛЖИ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ПОЧТИ ЗНАМЕНИТЫ». 16+
22.50 «ЧЕГО ХОЧЕТ ДЖУЛЬЕТТА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Космические истории». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Жизнь своих». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
14.00 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ 4». 12+
19.00 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
21.00 «Время».
22.35 «Жанна». 16+

«РОССИЯ»
6.05 «ПРИМЕТА НА СЧАСТЬЕ». 16+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.40 «Большие перемены».
12.45 «ДЕВЯТЬ ЖИЗНЕЙ». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.35 «ВОСТОЧНЫЙ ДАНТИСТ».
9.45 Диалоги о животных.
10.30 Острова. Иван Лапиков.
11.10 «НАША ДАЧА».
12.35 Письма из провинции.
13.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Ольга Фирсова.
13.35 «Игра в бисер» «Поэзия Беллы Ахмадулиной».
14.15 «Коллекция».
14.50 «400 УДАРОВ».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Пешком...»
17.40 «Неистовый Александр Дюма».
18.35 «Романтика романса».
19.30, 19.45 Новости культуры.
20.25 К 90-летию Валерия Ускова. Линия жизни.
21.15 «НЕПОДСУДЕН».
22.40 Angelina. Friends. Гала-концерт звёзд балета в Михайловском театре.

«НТВ»
4.50 «ДЕНЬ ОТЧАЯНИЯ». 16+
6.30 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Маска». 12+
23.20 «Звезды сошлись». 16+

Агымсуда мәет бар

Шомлы хәбәр Бөгелмә полициясенә узган елның 14 апрелендә иртәнге сәгать 5 тә килә. Шәһәр читендәге үз йортында яшәүче Р.Ишмаков таң белән хуҗалыгына чыга, инеш ярына җиткәч тә, суда агач кәүсәсенә эләгеп торган кеше гәүдәсен күрә. Бу хәлгә аптырап калган Ренат абзыйда манекен түгелме дигән уй да була, әмма хәләл җефете белән бергәләп табылдыкны төрле яклардан карап чыккач та, йөзтүбән судагы кеше ир-ат дигән фикергә киләләр. Ләкин полиция килеп, мәетне ярга чыгаргач, аның хатын-кыз икәне ачыклана.

Моның бәхетсезлек очрагы булу, ягъни мәрхүмәнең саксызлыгы аркасында батып үлү мөмкинлеге юк дәрәҗәсендә була. Чөнки елга күп сулы түгел. Мәет тәнендәге күгәргән-шешкән урыннар да кешенең җинаять корбаны булуына ишарәли. Ошбу фикерне тиздән суд-медицина эксперты да куәтли. Тән җәрәхәтләре булуын әйтә, хатын-кыз суга тончыгудан үлгән дигән беренче фаразны җиткерә.

Соңрак үткәрелгән тикшеренү өч кабырга сыну, алар уң як үпкә һәм башка әгъзаларга зарар китереп эчкә кан саву кебек күп кенә авыр һәм җиңел дәрәҗәдәге җәрәхәтләр булуын ачыклый. Шул ук вакытта алар үлемгә китермәгән, хатын-кыз суга батып түгел, ә туңып җан биргән дип белдерелә. Химик экспертиза аның исерек булуын да күрсәтә.

Күренеп торган дәлилләр, мәгълүматлар булмаса да, җинаять гаҗәеп тиз ачыла. Шул ук көнне төш вакытында әтисе фатирында 31 яшьлек Александр Дюков тоткарлана. Аннан соң 1991 елгы Александр Майоров һәм ул чакта 17 яшендә булган Денис Капин аңлатмалар бирә башлый. Ике көннән шәһәр суды аларның өчесен дә сак астына ябарга карар чыгара.

Һәлак булучының шул калада яшәгән 1975 елгы Лилия Нурмөхәмәтова булуы ачыклангач, зарар күрүче итеп аның туганнан туган энесе Данис Талипов билгеләнә. Данисның әйтүенчә, Лилия – әнисенең бердәнбер кызы, балалары, рәсми гаиләсе булмаган. 2007 елда әнисе вафат булгач, Бөгелмәдәге шәхси йортлары шактый гына буш торган, чөнки хатын-кыз ун ел буе үзеннән өлкәнрәк Илдар Әхмәткәримов белән аның фатирында яшәгән. Илдар исә, 2016 елда йортны бер бүлмәле фатирга алмаштыргач, аны тәртипкә китереп кирәкле җиһазлар урнаштыргач, Лилия үзе генә яшисе килүен әйтте, ди.

Аерым яшәсәләр дә, араны өзми алар. Илдар Лилиягә хуҗалык эшләрендә ярдәм итүен, еш кына очрашуларын әйтә һәм әлеге җинаять эшенә кагылышлы булган мәгълүматлар да бирә. Аның әйтүенчә, ике-өч ел элек хатынның үзеннән күпкә яшьрәк ир-егет белән якыннан аралашуын белә. Бу хакта Лилия аңа үзе дә сөйли. Ләкин тора-бара аның фатирындагы ишекләрдә яньчелгән урыннар, үзендә дә шешкән-күгәргән җәрәхәтләр булуы күренә башлый. Боларның теге егет эше икәнен дә яшерми ул. Әмма абзыйга явыз бәндә белән очрашмаска, үзләренең мөнәсәбәтләренә тыкшынмаска куша. Илдар интернеттан бу кешенең безгә мәгълүм Александр Дюков икәнен белешә.

А.Дюков ике югары белемгә ия зат. Ике баласы һәм беренче хатыны белән аерылышкач, бер баласы булган татар кызына өйләнгән. 2022 елда аларның уртак сабыйлары туган. Гаиләле ир-ат 17 яшькә өлкәнрәк мәрхүмә белән якыннан аралашуын кире кага. Эш яшь аермасында гына түгел монда. Хикмәт шунда: Лилия элегрәк Дюковның әнисе белән аерылышкан әтисенең сөяркәсе булган, берара бергә дә яшәп алганнар. Моны абзый үзе дә, таныш-белешләр дә раслый. Бу җәһәттән, яңа ханымның әлеге җинаять эшендәге тагын бер фигурант – Александр Майоровның әнисе икәнен дә искәртик. Лилия шуннан соң да әлеге гаилә белән араны өзмәгән, аны начар бәяләми алар. Александрга карата аналарча мөнәсәбәттә булды диләр, астыртын очрашып йөрүләренә ышанмыйлар. Шулай да Лилиянең артыгын эчүен, исерек чакта сүзләрне үлчәп тормавын искәртәләр. Ләкин мәрхүмә эштән чыккан сәрхушкә охшамаган, соңгы вакытта «Эссен» кибетендә эшләгән.

Инде берсенең әтисе белән икенчесенең әнисе тыгыз элемтәдә булгач, аларның уллары, әйтүләренчә, бер-берсенә «брат» дип эндәшкәннәр, А.Дюковның автосервисында машиналарга тавыш изоляциясе кую белән шөгыльләнгән. Вакыйгага биш көн кала, анда автомеханик белгечлеге буенча техникумда укучы Денис Капин эшли башлый.

Өчесе дә исерек иде дип әйтүчеләр булса да, Денисның исерткеч эчемлекләр эчмим дип әйтүе күбрәк ышандыра. Кызганыч ки, эчәргә хирыс ике өлкәнрәк кеше даирәсенә эләгә ул. Инде Лилия Нурмөхәммәтованың да бу яктан кимен куймавын искәртсәк, фаҗигагә этәргән төп сәбәп тә ачыкланыр.

Тикшерү барышында, хәвефле хәлләрнең 13 апрельгә каршы төндә булуы, ягъни мәетнең агымсуда нәкъ бер тәүлек ятуы беленә. 12 апрельдә Лилия элеккеге ире Илдар Әхмәткәримов белән була. Илдарның әйтүенчә, шкаф киштәсен төзәтергә, идәндәге келәмне рәтләргә дип чакыра ул аны. Кунак үзе белән литр ярым сыра алып килә, алдан да салмыш булган хуҗабикә белән сыйланып утыра алар. Ир-ат өй эшләрен дә караштыра. Соңрак ханым абзыйга мең сум акча биреп, шундый ук биш шешә сыра, тәмәке алып кайттыра.

Кичкә таба ханымга А.Дюков шалтыратырга керешә. Аның монда киләчәге мәгълүм була. Әлбәттә, 58 яшьлек агай яшь кеше белән аралашырга һәм танышырга атлыгып тормый. Шул рәвешле, кичке сәгать 8 дә И. Әхмәткәримов чыгып киткәч, Лилия үзе генә кала. 14 апрельдә иртәнге сәгать 9 да Илдарга полиция хезмәткәре шалтыратып, хатынның мәете табылуын хәбәр итә.

А.Дюков алданрак Лилиядән үзен, гаиләсен кимсетеп әйтелгән аудиохәбәр килүен әйтә. Әлеге дәлил җинаять эшенә теркәлмәгән, чөнки Александрның телефоны юкка чыга. Хәләл җефете «аны идәнгә төшереп ваттым, төзәтер өчен 18 мең сорадылар, шуңа күрә чүплеккә ташладым», – дип сөйли.

А.Дюков алдан такси белән үз сервисында эшләүче Д.Капинны барып ала да, икәүләп Л.Нурмөхәммәтова фатирына китәләр. Ишекне шактый исерек хәлдәге хуҗабикә ача, кунак кызыксына башлагач, Илдар белән эчеп утыруын таный һәм дорфа сөйләшеп болай да ярсулы ир-егетнең котырынып китүенә сәбәп чыгара. Кыйнау гына түгел, законда аеруча кансызлык күрсәтү дип бәяләнә торган гамәлләр дә кылырга тотына ул, ягъни исерек хатынны айнытырга керешә. Аны ваннага йөзтүбән каплап башына салкын су агыза, күтәрелмәсен өчен, муенына аягы белән басып тора. Капинның әйтүенчә, хатын-кыз елый, ялвара, ник алай эшлисең, мин сине яратам бит дип әйтә ала. Әмма Дюков туктамый, аягы туңа башлагач, Дениска да шундый ук явызлыкны кыларга куша.

Шактый җәзалаганнан соң, монда А. Майоровны да чакырып китерә ул. Аның белән кухняда эчеп утырганнан соң, ваннадагы газаплау дәвам иттерелә. Бер мәлне Дюков бөкене ябып куя, ваннага су тула башлый, тегеләр чиратлап бичара хатынны батыралар, өскә күтәрелгән күбек-куыкларны да күрәләр. Ахыр чиктә тәмам хәлсезләнгән Лилияне караватына алып чыгып салалар.

Яңадан кухняда сыйланган чакта, Дюков белән Майоров алга таба нишләү турында сөйләшә. Хатын-кызны юк итәргә кем тәкъдим итте, дигән сорауга икесе ике төрле җавап бирә алар, ягъни гаепне бер-берсенә аударалар. Тикшерү барышында монысы да Дюков эше, ә Майоров фатирдан чыгып качарга гына теләгән дип табыла. Аның кушуы буенча яшүсмер такси чакырта, аның шоферы А.Дюковның танышы булып чыга. Артыгын эчте, исерек дип, ханымны багажникка салырга дигән тәкъдимне кире кага таксист. Юеш киемле, авыр хәлдәге Лилияне юрганга төреп алып чыгып, «Рено Дастер»ның арткы утыргычына урнаштырып кузгалып киткәч тә, елга буена барудан баш тарта таксист. Шуннан соң такси аларны автосервис янына илтеп куя. Анда исә А. Дюковның «Лада Приора»сы тора. Суга тончыктыру гына түгел, ерткычларча тукмау нәтиҗәсендә дә бик авыр хәлдәге хатын багажникка салына. Машина шәһәр читендәге чишмә, инеш янына барып туктый. А.Дюков руль артында килеш хатыны белән телефоннан сөйләшеп утырган арада, Капин белән Майоров бичара хатынны күтәреп яр буена илтәләр дә, суга ташлыйлар. Юрганның бер кырыен ычкындыргач Лилия егылып төште, гәүдәсе суда, башы ләмдә калды, юрганның агып киткәнен дә күрдем, дип сөйли Д.Капин.

А.Дюков бар гаебен кире кага. «Очная ставка» вакытында яшүсмер егетнең үзен фаш итеп сөйләвен тыңлагач, моны кулга алганчыга кадәр Майоровның яшь кешегә басым ясап өлгерүе нәтиҗәсе дип белдерә. Гомумән, күбрәк «брат»ын гаепли ул, Лилияне кыйнады дип бара. Иң ахырда, Лилия суга ыргыту нәтиҗәсендә катып үлгән, мин аны анда ташламадым, димәк, үтерүдә дә катнашым юк дип, әлбәттә, адвокат ярдәмендә бик эзлекле фикер йөртә.

А.Майоров аңлатмалары, кем әйтмешли, керделе-чыкылы, чөнки барысын да буташтыра ул. Әйтик, Лилияне өеннән Дюков машинасы багажнигында алып киттек ди, ягъни такси турында бөтенләй хәтерләми. Кара-каршы сорау алганда исерек идем, Д.Капин сөйләгәннәрне тыңлагач, исемә төшә башлады дип, чынлыкта, фашиткеч күрсәтмәләрне раславын да белдерә. Ләкин иң ахырда уйлап чыгарып, гаепсез кешеләр һәм үземне гаепләп сөйләдем дип барысын да кире кага.

Д. Капин башлангыч чорда Л. Нурмөхәмәтованы суга Дюков белән Майоров ташлады, мин машинадан соң гына чыктым дип алдый. Тикшерү чаралары вакытында алар алдында да кабатлый. Ләкин соңрак сорау алуларда әнием дә катнашты, аның алдында мондый явызлыгымны әйтәсем килмәде дип белдерә. Ул да гаебен танымый. Дюков белән Лилия янына баруыбызны белмәдем, барып кереп мәхшәр башлангач, ишек бикле, тәрәзәләр тимер рәшәткәле булганга, качып китә алмадым, барысын да кикбоксинг белән шөгыльләнгән А. Дюковтан куркып эшләдем, автосервистан Лилияне сырхауханәгә алып барабыз дип белдем, су буенда чакта ул инде үлгән диеп уйладым дип белдереп үзен аклап маташа. Әлбәттә, ошбу малайның өлкәнрәк явызлар йогынтысына бирелүе бәхәссез, алардан куркуына да ышанырга була.

Тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Р.Әхмәтханов аларның өчесенә дә каршылык күрсәтә алмаган затны, аеруча аяусызлык күрсәтеп төркем белән алдан сүз куешып (сговор) үтерү дигән бик җитди гаепләү белдерә. Гаепләнүчеләр барысы да бернинди дә алдан сүз куешу булмады, үзеннән-үзе килеп чыкты дип белдерәләр. Хатын-кызны ваннада газаплауларын исерек булганга аңына китерергә омтылу дип атыйлар һәм башка сәбәпләр табып үзләрен гаепсез итеп күрсәтәләр.

Аеруча авырлар рәтендәге мондый җинаять өчен закон 8 дән 20 елга чаклы иректән мәхрүм итү каралган. Бу көннәрдә Татарстан Югары судында хөкем утырышлары бара. Анда барысы да бизмәнгә салыначак, билгеле. Таякның юан башы Александр Дюковка төшәчәге шикләндерми. Ул әлеге явызлыкны башлап җибәрүче санала, өстәвенә, балигъ булмаган затны коточкыч җинаятькә тартуда да гаепләнә. Ул чакта 17 яшендә генә булган Д.Капинга ташлама ясалачак, әлбәттә. Кырыс хөкем әле чыгарылмаган.

Наил ВАХИТОВ.

Картаюны белмәс аксакал

● Актёр Әзһәр Шакиров.

● Рәссамнар Рифкать Вахитов (уңда) һәм Закир Батраев.

Рәсем сәнгатебезнең аксакалы Рифкать Вахитовнең 85 яшьлеге уңаеннан «Хәзинә» милли сәнгать галереясында картиналарыннан күргәзмә ачылды. Сурәтләрен тамаша кылу гына түгел, аксакал кылкаләм осталарын бергә күрү сөенечле иде.

Юбилярны котларга шәмаилләр остасы, танылган каллиграф һәм текстолог галимебез Нәҗип Нәккаш, бөтен дөньяны йөреп чыккан, һәр җирдән дистәләгән этюд, пейзажлар язып кайткан рәссам Закир Батраев, республикабыз буенча өч дистәдән артык пленэр оештырган милли җанлы Мөдәррис Минһаҗев, Россия Рәссамнар берлегенең Татарстан бүлеген җитәкләүче Анатолий Крылов, алардан яшьрәк булса да, тарихны сурәтләүдә азу теше ярган Фәрит Вәлиуллин, гаҗәеп тыйнак, әмма зур иҗатлы, үтә нечкә хисле тарихчы рәссам Равил Заһидуллин килгән. Юбилярга исә аксакал дияргә тел әйләнми. Ак сакалы да юк. Үзе аксакалларча салмак хәрәкәтле, уйчан кыйфәтле дә түгел, киресенчә, терекөмеш сыман җитез, хәрәкәтчән. Иҗатына карaганда исә аксакалның да аксакалы ул Рифкать Вахитов.

Андый киң кырлы рәссамнар бик сирәк. Р.Вахитов рус, Европа сәнгате традицияләрендә оста иҗат итә. Моңа ул Казан сәнгать училищесында өйрәнә. Рифкать аганың пейзаж, натюрмортлары гаҗәеп тере, бай колоритлы, кояшлы. Портретлары искитмәле. Каллиграф Нәҗип Нәккаш сүзләре белән әйтсәк, XIX гасырдан башлап дин эшлеклеләре, сәясәтчеләр, язучы, рәссам, галимнәр галереясында автор һәркайсының характерын чагылдырып кына калмаган, әйләнә-тирәдәге атрибутлар аша бер караудa танырлык итеп чорны тасвирлый белгән. Портретлар – яшь буын өчен зур мәктәп, бәһасез мирас. Даһи шәхесләребезнең сурәтләрендә рәссам татар халкының көчен, батырлыгын, матурлыгын күрсәтүгә ирешкән. Татар халкын чит милләткә танытасың килсә, һичшиксез, Вахитовның Каюм Насыйри, Дәрдемәнд, Исмәгыйль Гаспралы, Шиһабетдин Мәрҗани һ.б. портретларын күрсәтү кирәк.

Рәссам Р.Вахитов монументаль сәнгатьтә дә тарихта калырлык зур эшләр башкарды. Ташкентта аэропорт, стадионнарда, уку йортлары биналарында мозаик паннолар иҗат итте. Аннары Чаллыга кайтып, яшь каланың йөз сурәтен матурлау өчен кулдан килгәнчә тырышты. «Татарстан» кунакханәсендәге «Сабан туе» панносы белән дә тарихка керде. Реалистик сурәтләр заманында Вахитовның стилизациягә кереп китеп, шартлы алымнар белән иҗат итүе кайберәүләрнең тешенә тиде. Әмма Рифкать аганы танылган сәнгать белгече Светлана Червонная яклап чыкты. Бүген «Татарстан» кунакханәсендәге «Сабан туе» панносын вәхшиләрчә кеше күзеннән томалап куйсалар да, бу иҗат әсәренең даны барыбер яши! Талантны җиде кат дивар белән капласаң да, яшереп булмый. Р.Вахитовның монументаль әсәрләрен, мәсәлән, бүген республикабыз халкы һәм җөмһүриятебез кунаклары Казан метросында күрә ала.

1990 елларда Рифкать Вахитов азатлык өчен көрәшүчеләрнең беренче сафларында булды. Татарстан Рәссамнар берлеген оештырды. Беренчеләрдән булып Казанда шәхси галерея ачты. Аңа хатыны Румия ханымның исемен бирде. Ул галереяда Татарстаннан гына түгел, Башкортстаннан, төрки дөньядан рәссам, җырчы, композитор, галим-голәма катнашында гаҗәеп җылы, күтәренке рухлы иҗат кичәләре узды.

Бөек татар ханнарын сурәтләү дә шул елларда башлана. Борынгы бабаларыбызның көнкүреше, тарихтагы сәяси әһәмияткә ия вакыйгаларның сурәтләре, мәһабәт портретларга шулай ук монументальлек һәм гамәли-бизәү сәнгате чалымнары хас булуы рәссамның борынгы сәнгатебездән көч алып иҗат итүен күрсәтә.

Быел остазлык һәм мөгаллимнәр елында кылкаләм остасы Рифкать ага эшчәнлегенең тагын бер тарафын – педагоглыкны әйтеп үтмичә һич мөмкин түгел. Туган ягы Удмуртиядә, Казанда, Ташкентта булсын, Р.Вахитов илебезнең төрле абруйлы сәнгать уку йортларында шәкертләр тәрбияләде.

Җыеп әйткәндә, Р.Вахитовның бөтен гомере иҗтиһадта үтте, бүген дә ул кылкаләмен кулыннан төшергәне юк. Шуңа күрә аксакалга тиң хезмәтләр башкарса да, һаман яшь ул!..

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.


● Шагыйрь Роберт Миңнуллин.

● «Батырша».

● Галим, дин эшлеклесе Ризаэтдин Фәхретдин.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:
222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;
222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;
222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;
222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:
ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ
420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга.
Бу санның чыгу көне 14.04.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2613

16+